Бакый Зыятдинов

Мәгърифәтле Таузар иле

Азат **ЗЫЯТДИНОВ**

Татар мин!

Нәселең кем? — дип сорыйлар миннән. —
Нинди милләт, кайсы яклардан?"
Һәрчак горурланып җавап бирәм:
"Татармын! — дим, — Казан артыннан!"

Без Татарлар. Нәсел тамырыбыз
Кыпчаклардан килә, болгардан.
Азияне, Европаны гизгән
Төркиләрдән килә, һуннардан.

Бөек болгар иле, Алтын Урда —
Шанлы дәверләре халкымның.
Хаҗи Тархан, Себер, Кырым иле...
Казан иде данлы ханлыгың.

Казан ханлыгының варислары —
Шуңа да без Казан татары.
Үз дәүләтен, мал-мөлкәтен җуеп,
Рухын саклап калган татары.

Мин дә шул татарның бер баласы,
Казан арты дигән төбәктән.
Халкым өчен рухи бишек булып,
Әдәби тел биргән төбәктән.

Шул яклардан уза Себер юлы,
Казансуы ага тын гына;
Тезелешкән татар авыллары
Ашыт яры, Шушма буена.

Шул якларда Әтнә, Арча, Балтач,
Кенәр, Мәңгәр, Дөбъяз, Кушлавыч...
Шул якларда халкым горурлыгы —
Бөек Тукаебыз туган ич!

*Мәрҗәннәре биргән Мәрҗанине,
Курсаларда туган Курсави.
Һәр авылда шәхесләре калка,
Эзлисе дә түгел әллә ни.*

*Шәхесләре үскән мәдрәсәдә —
Ташкичүдә, Түнтәр, Кышкарда...
Гади, мәгърифәтле авылларда
Иң караңгы, авыр елларда.*

*Сәйдәш токымнары шул яклардан,
Габәшиләр шуннан, Садрилар...
Иске Казан чишмәләре изге —
Суларында, ахры, нидер бар.*

*Мәгърифәтлек бардыр һәм дә инде,
Бардыр матурлыкка мәхәббәт.
Шул булмаса, туар иде мени
Гомәр, Сибгат, Гариф, Мөхәммәт?!*

*Игенчеләр, һөнәрчеләр ягы —
Иҗат тәмен анда беләләр.
Йортлар балкый иман нуры белән,
Челтәрләрдән чәчкә үреләр.*

*Нәкъ шул якта, Шушма буйларында
Нәсел башым — авылым Таузар да.
Ун бабам да шунда гомер сөргән,
Мәгърифәтле булган алар да.*

*"Нәселең кем? — дип сорыйлар миннән. —
Нинди милләт, кайсы яклардан?"
Һәрчак горурланып җавап бирәм:
"Татармын! — дим, — Казан артыннан!"*

Бакый Зыятдинов

Мәгърифәтле
Таузар иле

Идел-Пресс
2004

ББК 84—(2Р-Тат-)—4
З-82

Бакый Шәймулла улы ЗЫЯТДИНОВ

МӘГЪРИФӘТЛЕ ТАУЗАР ИЛЕ

Тарих ул — кешеләр. Татарстанның Балтач районындагы кечкенә генә борынгы авыл — Таузар иле турындагы бу китап та авылның әллә ничә гасырлар әүвәл яшәп киткән һәм бүгенге көндә туган туфракларында яки чит җирләрдә яшәп ятучы кешеләре турында. Тирә-якта күркәм тәрбия, тотнаклы тел белән танылу алган авылның тарихы "Мәгърифәтле Таузар иле" дигән исем белән тамгаланган икән, бу да инде, әлбәттә, юкка түгел...

ISBN 5-85247-032-5

© Б. Зыятдинов, 2004.

Бакый Зыятдинов

Мәгърифәтле Таузар иле

Идел-Пресс
2004



Авылдашларымның киләчәктә дә
укымышлы һәм һөнәрле булача-
гына ышанып, Тәүдарга
бәхетле язмыш теләп

[signature]

Туган авылым Таузар иленә мәхәббәт, аның кешеләренә хөрмәт, алар белән горурлану хисе мине гомерем буе озатып йөрде. Язмышымны музей эше белән бәйләвем авылым тарихын тирәнтенрәк өйрәнергә мөмкинлек тудырды, ул тарихның соңгы 70 еллык дәвере минем күз алдымда: үзем күп вакыйгаларның шаһиты һәм шуңа, йөрәкләнеп, авылым тарихын язарга алындым да.

Бу тарихны кулга тотарлык китап итүгә бик күпләрнең хезмәте керде, күңел җылысы салынды.

Рәхмәтемнең иң зурысы китапның чыгуы белән якыннан кызыксынып, безне рухландырып торган һәм китап чыгаруның матди ягын тулысы белән үз өстенә алган Азат энемә.

Китапның фәнни редакторы, татарның күренекле галиме, тарих фәннәре докторы якташыбыз, дустым Равил Фәхретдиновка ихлас ярдәме өчен шулай ук рәхмәтемне җиткерәм.

Бу китапны хәзерләгәндә Республика милли архивы директоры Людмила ханым Горохова, шул ук архивның уку залы мөдире Ләлә ханым Хәсәншина, Казан дәүләт университеты китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге фәнни хезмәткәре Диләрә ханым Абдуллина, тарихчы галим Рәшит Галләмовларның ярдәме зур булды. Һәммәсенә — чиксез рәхмәтләрем.

Китапка “Себер тракты тарихы” музеендагы хезмәттәшләрем Лилия Җәләлиева, Зөлфия Габдуллиналарның көндәлек бөртекле хезмәте керде, Түнтәр мәктәбе укытучысы, туган як тарихын өйрәнүче дустым Рәфгать Зариповның тырышлыгы салынды. Зур рәхмәт үзләренә.

Безнең кульязмаларны китап итеп бастырырлык хәлгә китереп җиткергән туганыбыз, “Сөембикә” журналының баш мөхәррире Фирая Бәдретдинова һәм аның хезмәттәшләренә шулай ук зур рәхмәтемне белдерәм.

Автор.

ТАУЗАР ИЛЕ — БОРЫНГЫ АВЫЛЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Таузар авылы Татарстан республикасының Балтач районына керә, район үзәгеннән көнбатышка таба ун чакрым ераклыкта, авыл Советы үзәге булган Карадуган авылыннан шул ук юнәлештә өч чакрымда, Шушма елгасының уң ягында урнашкан. XVI йөзнең икенче яртысы һәм XVII гасырда Таузар авылы административ бүленеш буенча Арча даруханына кергән (элек Казан ханлыгында "даруха" дип, аерым өлкә һәм өязләрне атаганнар; русча документларга "дорога" дип кереп китә). Соңыннан, XVIII гасыр башында, Россиядә губерналар, шул исәптән Казан губернасы да төзелгәч, Таузар авылы губернаның Казан өязе составында була. 1834 елгы ревизия буенча ул Казан өязе Апаз волостенда, ә 1858 елгы ревизия материаллары күрсәткәнчә, Малые Лызи (Мало-Лызи) волостенда була. Соңга табарак үзәк шул Кече Лызида калдырылса да, волость үзе Балтач волосте дип атала башлый. Революциядән соң, кантоннар төзелгәч, авылыбыз — Арча кантонының Балтач волостенда. 1930 елда Таузар яңа төзелгән Түнтәр районына кертелә, ә 1932 елдан, район үзәге Балтачка күчкәч, бүгенге көнгәчә Балтач районы авылы (берара, районнар эреләндерелгән 1963—1965 елларда, Таузар авылы Арча районында да булып ала).

Патша ревизиясе үткәрелгән елларда Таузар авылы кешеләре, шактый гына татар авылларының халкы кебек үк, ясаклы крестьяннар (ясаклы татарлар) булган, ягъни алар патшага (дәүләткә) натуралата да (ашлык, тире һ. б.), акчалата да ясак түләп торганнар. Алардан үзгә буларак, кайбер авылларның, мәсәлән, Балтач, Хәсәншәех, Яңгул һәм башкаларның крестьян-

нары йомышлы (служилые) татарлар булган, алар төрле дәүләт эшләренә, шул исәптән Казан верфендә корабльләр төзү өчен урман кисү, урман ташу кебек авыр эшләргә дә тартылганнар.

Таузарның исеме, аңлашылса кирәк, "тау" атамасы белән бәйле, гәрчә анда әллә ниткән чын таулар булмаса да. Хәер, авыл янындагы Кирәмәт, Шушма суы буендагы Дүче таулары бу исемнең дөреслегенә нигез була ала. Бу уңайдан Казан юлы өстендәге Биектау авылының исеменә генә игътибар итик: аның тавы әлләни биек тә түгел, әмма зур бер авылга исем биргән.

Авылыбызның исеме элек "Тау зары" дип аталган дигән сүз шактый киң таралган, хәтта ул аерым басма-китапларга да шул исем белән кергән, мәсәлән, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1966 елда Мәскәүнең "Советская энциклопедия" нәшриятында бастырып чыгарылган "Татарча-русча сүзлек"кә һәм Казанда нәшер ителгән "Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше" дигән белешмә китапларына. Әмма соңга табарак бу хакта икенче төрле фикерләр дә туды. Якташ галимнәребезнең берсе, Казан артында, Кенәр якларында туып-үскән, хәзер филология фәннәре докторы, тел, әдәбият һәм тарих, шәҗәрәләр, борынгы кульъязмалар һәм эпитафияләр (кабер ташларындагы язулар) буенча зур белгеч Марсель Әхмәтҗанов "зар" сүзенә башка төрле аңлатма бирә. Аныңча, бу атамада угыз теленә хас фонетик күренеш ята; ул бүгенге казакъ һәм нугай телләрендә дә сакланып калган, ә нугайлар (урта гасырда — нугай татарлары) Казан артының этник тарихында зур эз калдырганнар. Менә шул халыкларда борынгыдан күчү (эволюция) буенча "лар" белән "зар" тәңгәллеге килеп чыга: -лар -дар (-тар) -зар. Ягъни, "Таузар" — "Таулар" булып чыга. Галимнең бу фикере игътибарга лаек. Җитмәсә, бүгенге Татарстанда "Таулар" исемле яки тау белән бәйле авыллар бар: Таулар (Балык Бистәсе һәм Минзәлә районнарында), Тау Иле (Яшел Үзән районында), бая атап киткән Биектау (Биектау районында). Ревизия материалларында Таузарның икенче, параллель исеме итеп "Тохтаров тожъ" ("тоже" — шулай ук) дигән исем дә йөри; бәлки, ул шушы авылга нигез салучы Туктарны белдерәдер. Гомумән, шул еллардагы ревизия документларында шактый гына авыллар берничә исем белән искә алыналар; бу, күрәсең, төрле тарихи сәбәпләр белән бәйле. Таузар авылының 1678 елгы халык санын алу документларында Таузаров дигән фамилия дә бар.

1678 елгы халык саны алу материалларында Таузар янәшә ике урында күренә. Шуның берсендәге кешеләр 1716 елгы I ревизиягә барып тоташа, шул исәптән безнең бабайлар — Айбулат, Еникәйләр дә. Икенче Таузардагыларның дәвамы 1716 елгы ревизиядә хәзерге Таузарда күренми. Күрәсең, алар икенче урынга күчкәннәрдер. Безнең авылның көньягында Түбән Кенәнең фермасы янынннан агучы көчле чишмәләрдән торган елга башында Таузарның иске зираты булган. Бәлки алар Кенә авылын төзүдә катнашканнардыр — шунда күчкәннәрдер. Борынгы картада (XVIII гасыр) бу чишмәле елгада тегермәннәр дә бар икәне күренә.

Таузар авылы безнең якларның иң борынгы авылларыннан санала. Бу хакта аның элегрәк "Таузар иле" исеме белән йөртелүе дә сөйлидер (кайбер рус чыганакларына да шул исем белән кергән). Ә тарихчылар "иле" сүзенең нәкъ менә борынгы авылларга хас булуын әйтәләр — безнең якларда, мәсәлән, Яңгул иле, Борнак иле, Кариле авыллары да бар. Таузар авылы җирендә, Таузар белән Карадуган арасындагы тау башында, "әүлия кабере" дигән ялгыз кабер булып, аның кабер ташы сакланган. Күренекле археолог-эпиграфист мәрхүм Һарун ага Йосыпов тикшеренүләре буенча, ул таш 1541 елда, әле Казан яулап алынганчы куелган һәм, әлбәттә, безнең якларда мөселманнар, татарлар яшәгәнлеге хакында сөйли. Риваятьләргә караганда, ул кабердә Гарәбстаннан килгән изге хаҗи Әсьәндәр (Искәндәр) күмелгән. 1854 елда төзелгән тарихи бер картага шул җирдәге мөселман зираты төшерелгән. "Песцовый кенәгәләр" ("Песцовые книги") дип аталган тарихи язмаларда (ә алар Казан Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алынгач, руслар тарафыннан төзелгәннәр) һәм шуларны җентекләп тикшергән мәгълүм тарихчы Е. И. Чернышев хезмәтендә Таузар авылының ханлык чорыннан килүе әйтелә.

Безнең яклардагы татар авылларының борынгылыгы Казан ханлыгы чоры белән генә чикләнми; аларның кайберләре Алтын Урда яшәешенең соңгы дәверенә барып тоташа. Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре Рамил Хәйретдинов һәм Радик Салиховлар Таузар авылы да Алтын Урда чорында ук булган булырга тиеш дигән фикерне әйтәләр. Бу хакта шулай ук якташыбыз, Балтач җирендә туып үскән, бүген тарих фәннәре докторы, археология һәм урта гасырлар тарихы буенча зур белгеч Равил Фәхретдинов та язып чыкты. Аның әйтүенчә, әле 1395 елда ук рәхимсез җиһангир Аксак Тимер яуларыннан качып киткән кайбер шәехләр үзләренең ырулары белән безнең

Шушма буена килеп төпләнәләр, шунда Хәсәншәех, Балтач, Салавыч, Смәил авыллары барлыкка килә.

Минем туган авылым Таузарның борынгылыгы хакында Хәсәншәех авылында озак еллар фельдшер булып эшләгән Гали ага Мәҗитов, ул әле Яңгулда яшәгәндә, шул авылның Сабир мулладан калган бер тарихи язмага таянып сөйли иде. Ә анда Таузарның күптәнге авыл булуы хакында язылган булган. Шунысын да әйтеп үтим: Сабир мулла (тулы исеме — Мөхәммәтсабир Әхмәтша улы Шәфиев) 1881 елда Яңгул авылындагы өч мәчетнең икенчесенә имам-хатиб һәм мөдәррис булырга указ алган. Әлеге тарих китабын да уку өчен Гали абзыйга аның карчыгы биреп кенә торган. Әмма, ни кызганыч, ул тарих эзсез югалган.

Елгалар, авыллар тарихын өйрәнүче галимә, филология фәннәре докторы Фирдәүс Гарипова Карадуган авылы кешеләрен Таузардан күчеп утырганнар дип яза; шундый ук фикерне югарыда телгә алынган галимнәр Р. Салихов һәм Р. Хәйретдинов та әйтәләр. Таузар авылының картлары күрше Арбаш авылы да Таузардан Бәшир атлы кеше күчеп утырудан барлыкка килгән, дип сөйлиләр. Арбашның бер өлеше әле революциягә кадәрге документларда "Арбаш-Бәшир" ("Арбаш-Пашир") дип йөртелгән.

Төрле гасырның төрле елларында Таузар илендә ничә йорт — хуҗалык булганы, күпме кеше яшәгәнлеге турында да бераз мәгълүмат биреп үтик — ул саннар укучыларга кызыксыз булмас дип уйлыйм. 1678 елдагы исәпкә алу вакытында Таузарда 19 хуҗалык булып, 56 ир-ат яшәгәнлеге күренә, ә 1716 елгы беренче ревизия материалларында язылганча, әле 1710 елда хуҗалык саны 27 гә җиткән; ревизия үткәрелгән 1716 елда шул хуҗалыкларның унөче Таузарда теркәлгән, калган ундүртенең хуҗалары авылдан качып киткәннәр, дип язылган. Ул исемлектә безнең бабай Токай Айбулатов та бар. Ә 1745 елгы ревизия кәгазьләрендә аларның шактые кире кайткан итеп күрсәтелгән, шул исәптән безнең бабайлар да. Бу вакытта Таузарда 58 ир-ат яшәгән. Качып китүләрнең сәбәбе түли алмаслык ясак нәтиҗәсендә булырга мөмкин — ясакның гомум күләме ревизия документларында язылган: "Ясашного тягла двенадцать ясаков с полутретью, четь ясака, полторачети ясака, тягла пол ясака"*.

** Мөхәррир (редактор) аңлатмасы: "Ясашное тягло" дигән сүз, әлбәттә, ясак (налог, салым) түләп торуны, крестьян (бу очракта татар кешесе) җилкәсенә төшкән кабаланы, авыр йөкне аңлата. Ясакның үзенең төгәл күләме хакында белешмә юк — патша фәрманнарында "брать в казну сколько можно" диелә, ягъни авыл кешесеннән күпме каерырга, аны күпме таларга була, каер, тала! Гадәттә,*

1762 елгы сан алу вакытында авылда 71 ир-ат яшәгәнлеге теркәлгән, 1834 елдагысында — 129 ир-ат, ә 1858 елдагы унынчы ревизия буенча 34 хуҗалыкта 178 ир-ат күрсәтелгән. Казан өязенең авыллары хакында 1878 елда Казанда басылып чыккан китапта Таузарда 56 йорт булып, 204 ир-ат, 191 хатын-кыз яшәгәнлеге, шулай ук авылның мәчете һәм тегермәне булуы хакында әйтелгән. 1897 елгы халык санын алу материаллары буенча Таузарда 472 кеше яшәгән, ә 1914 елда 95 йортта 260 ир-ат, 266 хатын-кыз, барысы 526 кеше яшәгән. Мәгълүматлар китерүне дәвам итсәк, авылда кеше санының арта барганлыгын күрербез.

И. А. Износков үзенең "Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием" (Казан, 1885) исемле мәгълүм китабында Таузар авылында 63 йорт булып, 208 ир-ат, 204 хатын-кыз яшәгәнлеге, аларның 656 дисәтинә җирләре булуы, уртача хәлдә яшәүләре, 11 кешенең дәвамлы вакытка читкә эшкә китүе, 10 кешенең фабрикаларда эшләве, 20 кешенең читкә уракка йөрүе әйтелә (бу мәсьәләгә өстәмә ачыклык рәвешендә үз әниемнең Мари ягындагы рус авылларына уракка барып, шунда эшләгән өчен күпмедер ашлык алып кайтуы турында сөйләгәнен әйтеп китү урынлы булыр). Ә фабрикалар исә байларның сабын ясау, тукыма буяу һәм мех эшкәртү цехларыннан гыйбарәт булган. Авылда 17 баш умарта, тегермән булганлыгы да мәгълүм. Таузар картларының сөйләвенә караганда да, язма чыганаклардан күренгәнчә дә, анда йортлар саны 105 тән беркайчан да артмаган. Авылның артык үсеп китмәвенең төп сәбәбе — аның җире аз булуында. Таузарны һәр яктан башка авыллар чорнап алган: көньяктан Кенә, көнбатыштан Хәсәншәех, төньяктан Шубан, көнчыгыштан Арбаш авыллары. Җитмәсә, Таузарның җирләре бер яктан да урманнарга барып тоташмый, димәк, урман кисеп-яндырып сөрү җирләрен арттыру мөмкинлеге булмый. Бу яктан Балтач волостендагы зур авыллар, мәсәлән, Хәсәншәех, Кенә, Арбаш, Балтач үзе Таузардан шактый аерылып торганнар, аларның басулары зур булып, ерак урманнарга барып тоташкан. Бая гына телгә алган Износков китабында язылганча, безнең авылда җан башына 1,6 дисәтинә җир туры килсә, Арбашта ул 3,1 дисәтинә, Кенәдә 2, Шубанда 2,9, Балтачта 2,3 дисәтинә булган.

---

*кеше өйләнеп алтмыш яшькә җиткәнче патшага ясак түләгән, алтмыштан соң аннан ясакның йә яртысын, йә чиреген генә алганнар, кайбер очракларда ясак түләүдән бөтенләй азат та иткәннәр. Югарыда китерелгән юлларда сүз "12 ясактан бераз артыграк", ягъни тулы ясак түләү, шулай ук картлардан ясакның яртысын, өчтән берен, чиреген түләтү турында бара. — **Р. Ф.***

Таузарда зур байлар булмаган. Мин таза тормышлы, ике катлы йортлары булган берничә кешене генә беләм, болар: Галим йорты (хәзерге Йосыповлар), Сафа Гыйззәтулласы, Гыйззәтулла Галимулласы һәм Сәгыйтнекеләр. Байларның аз булуы да (хәер, аларны чын байлар дип атап та булмый) әлеге шул җир азлыгы белән бәйләнгән. Ниндидер промысел оештыру яки кибет ачып җибәрү өчен башлангыч капитал кирәк, ә авыл кешесе аны җирдән генә ала ала. Шуңа күрә, зур җирле авылларда таза тормышлы кешеләр җирләрен яхшы эшкәртеп, әйбәт уңыш алганнар, ә җирләрен эшкәртә алмаган кешеләр үзләренең чәчүлек җирләрен әлеге эшлекле кешеләргә бирергә мәҗбүр булганнар һәм, шулай итеп, бу хуҗалык башлангыч байлык туплаган, акчасын кибет ачу яки берәр фабрика төзү өчен тота алган. Без моны зур җир мәйданнарына ия булган Балтач, Сосна авыллары мисалларында күрә алабыз. Безнең районлагы элекке иң зур байлар — Балтачтан атаклы Мортаза бай, Кәләми, Мөхәммәтҗан байлар, Соснадан Гомәр бай, Нормадан чыккан мәшһүр Габдрахман Ишморатов... Безнең авылның югарыда исемнәре санап үтелгән баерак кешеләре Арбаштагы Якуб байдан мех алып эшкәрттергәннәр, читкә йөк йөртүдә катнашканнар яки көндәлек куллану әйберләре сатканнар.

Таузарда мәчетнең кайчан төзелүе тәгаен генә билгеле түгел. Россиянең Дәүләт борынгы актлар архивында 1742—1743 елларда патша указы нигезендә Арча дарухасына кергән Салавыч, Түнтәр, Сосна, Таузар һ. б. авылларның мәчетләре җимертелү хакында документлар саклана (Фонд 248, эш берәмлеге 803, 133—142 битләр). 1888 елда Таузарда мулла сайлаганда мәчетнең җәмигъ мәчет булуы әйтелә. Өлкәннәрнең сөйләвенчә, элеккеге мәчет зурайтылып, аңа яңадан манара куйганнар, аны авылның иң яхшы балта остасы Муса бабай куйган. Муса бабай — минем әнинең әтисе. Ул 1850 елда туган, димәк, манара кую 1880 еллардан да алда булмагандыр.

1828 елда патша мөселман мәхәлләләрендә метрика алып баруны авылның муллаларына йөкләү турында указ чыгара һәм бер елдан бу фәрман тормышка ашырыла башлый. Республиканың Милли архивыннан алынган материалларга караганда, 1829 елда Таузарда Куныр кешесе Гали улы Нигъмәтулла мулла була. 1831 елда ул үлгәннән соң, ике ел Габделгалим Мәсхүд улы мулла булып тора һәм 1835 елдан башлап мәрхүм Нигъмәтулла мулланың улы Муллаәхмәт имамлык итә башлый. Күрәсең, алдагы ике ел Муллаәхмәтнең укып бетерүе белән бәйле булгандыр, чөнки шул чордан башлап Нигъмәтулла мулланың токымы

гына имамлык итә. Югарыда әйтелгән Муллаәхмәттән соң, 1888 елдан башлап, аның улы Мөхәммәтгариф мулла була; 1914 елда аңа ярдәмгә улы Муллахаҗи икенче мулла итеп сайлана һәм совет чорында муллалар куылганчы авылда имам-хатиб һәм мөгаллим була, ә 1921 елда тутырылган беренче совет мәктәбе анкетасыннан күренгәнчә, ул әле — укытучы. Мәктәпләрдә анкетаны, гадәттә, русча белгән чит кеше тутырса, Муллахаҗи аны дөрес итеп үзе тутырган, чөнки ул мәдрәсә бетергәннән соң, Арчада рус-татар училищесын уңышлы тәмамлаган булган. (Шундый ук русча анкетаны Сосна мәктәбендә укытучы Мазһар мулла да үзе тутыра.) Аның әтисе Мөхәммәтгариф та заманында Түнтәрдә, атаклы Ишми ишан (Ишмөхәммәт) мәдрәсәсендә дин белеме алганнан соң, Малмыжда училище тәмамлаган. Мөхәммәтгариф мулладан дәрес алган Газиз абый (1904 елда туган) миңа әлеге мулланың Истанбулда да укыганлыгын әйтте. 1913 елда Габдулла Тукай үлгәч, ул шәкертләргә бөек шагыйрь Тукай үлде, дип белдергән, кара тактага аның исемен язып куйган, шагыйрьнең шигырьләрен белүләрен сораган. Үзенең укытучысы Ишми ишаннан үзгә буларак, Мәхәммәтгариф хәзрәт җәдидче мулла булган булса кирәк.

Билгеле, авылда бер нәселдән генә булган муллаларның муллалык итүе, имам-хатиб вә мөгаллим булуы авыл халкының тәртибенә, дин тотуына һәм укымышлылыгына уңай тәэсир ясаган. Әлбәттә, аларның дөньяви белемнәрдән дә мәгълүматлы булуын әйтеп үтәргә кирәк. Таузарның соңгы муллалары җимеш бакчасы тотканнар, һәртөрле яшелчә үстергәннәр, гомумән, авыл кешеләренә һәрьяктан үрнәк булганнар (минем әти, мәсәлән, мулланың иртән һәм кичен бакча буендагы инештән яшелчәләренә үзе су сибеп йөргәнлеге хакында яратып сөйли иде). Шуңа күрә дә андый муллаларны халык үз иткән, репрессия еллары башлангач та, аларны коткарып калырга тырышкан, Урта Азиягә, Ташкентка күчеп китүләренә ярдәм иткән.

Бер уңайдан муллаларны сайлап кую тәртибе турында да бераз мәгълүмат бирәсе килә. Мулла һәм мөгаллим буласы кешенең мәдрәсә һәм училище тәмамлаганнан соң хәрби бурычын үтәгән булуы, өяз полиция идарәсе тарафыннан хөкемгә тартылмавы турында уңай бәяләмә (характеристика) алуы шарт итеп куела. Шуннан соң әле ул Уфада, Мөселман Диния нәзарәтендә имтихан тотып, мөфти һәм өч казый кул куйган таныклык ала. Әмма эш әле аның белән генә дә бетми. Булачак мулла кайсы авылда туып үскән, шундагы мәхәллә халкы җыелыш җыеп, аның мулла булырга яраклы икәнен танып, рөхсәтен

бирә, ә җыелышта мәхәллә йорт башы кешеләренең кимендә өчтән икесе катнашырга тиеш була. Мулла булырга теләгән авылында да аны имам-хатиб һәм мөгаллим итеп мәхәллә җыены җыеп сайлап куялар. Мулланы, аның гаиләсен, мәчет һәм мәдрәсәне үз хисапларына тотарга килешеп, карар кабул итәләр. Монда да мәхәллә йорт хуҗаларының өчтән икесе катнашу мәҗбүри була. Бу җыеннарда авыл старостасы, волость старшинасы һәм писер (писарь) катнаша, үз имзаларын куя, мөһерләрен суга. Шуннан соң гына мулла буласы кеше Аллаһ юлындагы хезмәткә басуын раслап һәм императорга тугрылыклы булырга ант итеп, кулын куя. Шуларның барысы да эшләнгәннән соң, губерна идарәсеннән (управление) ул мулла булып расланувы турында указ ала.

Инде хәзер яңадан авылыбызның гомум тарихына кайтыйк. 1882—1884 елларда авылларда хуҗалыкларның җир мәйданын һәм терлекләре санын белү максатыннан исәп алу үткәргәннәр. Шул мәгълүматлардан күренгәнчә, 1884 елда Таузарның 73 хуҗалыгында 412 кеше яшәгән, барлык җир мәйданы 653,2 дисәтинә булып, 12,5 е — каралты-кура җире, 447 се — чәчүлек җир, 63 е — болынлык, 4,6 сы — көтүлек, 102 се — куаклык, 22,9 дисәтинә файдалануга яраксыз җир була, урманы булмый. Югарыда әйтелгәнчә, башка авылларның урманнары да бар, мәсәлән, Балтачныкы — 371 дисәтинә, Хәсәншәехныкы — 250, Арбашныкы — 150, Югары Шубанныкы — 122, Карадуганныкы — 113 дисәтинә.

Түбәндәге кечкенә генә статистика да укучыга кызыклы булыр дип уйлыйм. Җир турындагы материаллардан күренгәнчә, Таузар авылы җан башына туры килгән җир буенча аз җирле авыллар рәтенә кергән. Таузарда җан башына 1,5 дисәтинә җир туры килсә, Арбашта ул — 2,8, Карадуганда — 1,8, Югары Шубанда — 2,9, Хәсәншәехта — 1,9, Кече Лызида — 3,3, Ярак Чирмәдә 3 дисәтинә булган. Безнең авылда бөтенләй үк җирсез хуҗалыклар булмаган, ә менә Арбашта 6 хуҗалык, Түбән Шубанда 2 се җирсез була. 1882 елгы терлек санын алу вакытында Таузарда 65 хуҗалыкның 21 е бөтенләй атсыз була, 6 хуҗалык икешәр атлы, бер хуҗалык өч атлы дип теркәлә. Арбашта 117 хуҗалык булып, шуның 39 ы атсыз; Хәсәншәехта шундый ук чагыштыру — 210:81, Югары Шубанда — 81:39, Карадуганда — 79:24, Ярак Чирмәдә — 19:3, Гондырда — 29:3 нисбәтендә. (Хөрмәтле укучы гыйбрәтле бер әйбергә игътибар итсен иде: Ярак Чирмә (Чурма), Кече Лызи, Гондыр кебек удмурт һәм рус авылларында күрсәткечләр, татар авылларыныкы белән чагыш-

тырганда, шактый югары. Бу патша Россиясенең татарга булган милли сәясәтенең бер чагылышы булып тора. — ***Р. Ф.***).

Игенчелектән башка шөгыль-һөнәр турындагы мәгълүматлар И. А. Износковның югарыда телгә алган 1885 елда чыккан китабында һәм 1895 елда Балтач волостенда вак һөнәрче, ярдәмче кәсеп турындагы отчетларда язылган. Алардан күренгәнчә, Таузарда 10 ир-ат һәм бер хатын-кыз озак вакытка читкә китеп эшләгәннәр. Җирле фабрикаларда 10 кеше эшләгән, читкә уракка 20 кеше йөргән, 5 кеше мех эшкәртү белән шөгыльләнгән, бер кеше мич чыгарып йөргән, бер агай аяк киеме тегүче булган, 10 кеше чыпта суккан (югарыда язган идек: авылда су тегермәне булган; бер кеше 17 баш умарта тоткан).

Кешеләр үзләре җитештергән товарларны дип әйтик — чыпта, чабата, бау, көрәк, кием-салым әйберләрен, ашлык, йорт терлекләрен һәм башка кирәк-яракны базарларда сата һәм алалар иде. Безнең авылга иң якын базар Апаз авылында булып, ул шимбә көнне эшләгән һәм аны шимбә базары дип тә йөрткәннәр. Безнең авылдан шулай ук Балтач базарына да йөриләр иде, ә ул чәршәмбе көнне эшләде. Хайван, мал-туар базарының иң зурысы Чепьяда иде, ул якшәмбе көнне булган. Соңыннан алар барысы да якшәмбе көнне генә эшләүгә күчтеләр. Базарлар кешеләрнең аралашу, очрашу урыны да булып торды. Ватан сугышына кадәр бабай белән Апаз базарына барганым хәтердә калган. Анда татарлардан тыш марилар, удмуртлар һәм руслар да җыела иде, аларның аралашу теле татар теле иде. Узган гасырның 60 нчы елларында мондый базарлар бетерелде.

Авыл кешеләренең солдат хезмәте үтәүләре турында документаль материаллар бик аз. Метрика кенәгәләрен актарганда, туучыларның әтиләре солдат хезмәте үтәүчеләр булуы бик еш күренә. Авылда андый кешеләрне "солдат" сүзе кушып исемләгәннәр. Мәсәлән, Әхмәт солдат, Галимулла солдат һ. б. 1904 елда солдат гаиләләренең земство белән пособие сорап язышкан материалларыннан кайбер кызыклы мәгълүматлар билгеле булды. Мәсәлән, Сафа Фазылының (Фазылҗан Мөхәммәтсафин) — 13 ел, Габделгани Мөхәммәтгалиевнең — 13 ел, Низаметдин Мөхәммәтшакировның — 10 ел, Хәбибулла Хәйруллинның 14 ел хезмәт иткәнлекләре күренә. Аларга, гаилә хәленә карап, төрле суммада пособие бирелгән.

Бу кешеләр арасындагы Низаметдин — минем бабам Зыятдинның энесе. Низаметдин үлгәндә Зыятдин бабайның: "Их, телен генә булса да алып калырга иде", — дип елаганын сөйлиләр,

чөнки энесе русча бик әйбәт белгән һәм яза да алган. Шушы документларда Низаметдинның 102 нче Вятка пехота полкында рота барабанчысы булып хезмәт иткәнлеге күренә. Мин 1890—1905 еллар арасында солдат хезмәте үткәннәрне генә санап үттем.

Беренче бөтендөнья сугышында катнашучыларның төгәл исәбе юк, ләкин аларның шактый күп булуы билгеле. Берсе — минем әнинең абыйсы — Муса улы Мостафа. Аның 1916 елда атлы гаскәрдә (кавалерия) хезмәт иткәндә төшкән фотосы бүгенге көнгәчә саклана. Тагын безгә билгеле булганнары: Галиев Хәйрулла (Маһикамал апаның беренче ире), Галимҗанов Хәбибулла (Гарифәбану апаның беренче ире), Исмәгыйлев Ибраһим, Сөләйманов Әхмәтнәби, Сәгыйтов Хәсбиулла, Әүхәдиев Габделбәр (Зарифа апаның беренче ире), Мәрданов Габдулла, Хөсәенов Хәбибрахман, Вәлиуллин Усман, Исхаков Галимулла. Шулардан Галиев Хәйрулла, Галимҗанов Хәбибулла, Әүхәдиев Габделбәр сугышта үлеп калалар. Аларның тол калган хатыннарына исән кайткан фронтовиклар өйләнә — йортка керә. Хәйрулланың хатыны Маһикамал апага — Усман абый, Хәбибулланың хатыны Гарифәбануга — Галимулла абый, Габделбәрнең хатыны Зарифа апага — Ибраһим абый. Тол хатынга өйләнеп, аның йортына барып торган кешене йортка кергән дип әйтәләр иде. Бу саналган кешеләрнең күпчелеге Гражданнар сугышында да катнашалар, шуларга яңалары да өстәлә: мәсәлән, минем әти — Зыятдинов Шәймулла, Исхаков Заһидулла, Сәгыйтов Фатыйх. Әти Колчакка каршы сугышта, Тубыл шәһәре янында яралана, озак кына госпитальдә ятып, тазаргач, Урта Азиягә басмачыларга каршы җибәрелә. Исмәгыйлев Ибраһим сугышта венгрларга пленга төшә һәм Гражданнар сугышы беткәч кенә илгә кайта. Ул анда эре җир биләүчедә эшли. Венгрларны маҗарлар дип сөйли иде Ибраһим абый. Сөйләгәннәреннән, Венгриядә ул чорда ук авыл хуҗалыгының, безгә караганда күпкә алга киткәне аңлашыла иде. Моңа бәйләп, инде Бөек Ватан сугышыннан соңгы — 1946—1950 елларда булган бер вакыйганы телгә алыйм. Бервакыт авылдан бәрәңге һәм ашлык ташырга солдатлар килде, аларның күпчелеге венгрлар булган. Ибраһим абый шулар белән иркенләп үз телләрендә сөйләшеп, безне дә, венгрларны да шаккатырган иде. Себердә яшәүче туганыбыз Газиз абый үзенең Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан Әхмәтнәби абыйсы өчен пособие алганнарын һәм аның хәйран суммада (өч ат алырлык) булуын сөйләгән иде.

Авылда Октябрь революциясен хәтерләгән кешене белмим, чөнки аны патша алмашыну дип кенә кабул иткәннәр. Аның чыннан да переворот кына (түнтәрелеш) булуын тарихчылар да таный. Ә шул түнтәрелеш нәтиҗәсендә килеп чыккан Гражданнар сугышы, сәнәкчеләр сугышы һәм 1921 елгы ачлык зур афәтләр китергән һәм бу халык күңелендә җуелмаслык тирән эз калдырган. 1921 елгы ачлык, кешеләрнең ачтан шешенүе, күпләп үлүе турында әти-әнидән еш ишеттем. Ләкин күпме кешенең ачтан үлгәнлеге турында метрика материалларын табып булмады. Күпләп кырылу нәтиҗәсендә халыкның табигый артымы да кими. Моңа өстәп, кешеләрнең ачлыктан качып, эш эзләп читкә күчеп китүен дә әйтергә кирәк. Шундыйларның берсе — Галиев Газиз абыйлар — гаиләләре белән Кемерово өлкәсенә күчеп китәләр һәм гомерләрен шунда яшәп үткәрәләр. Бу вакыйгаларның нәтиҗәсе халык саны алу материалларында да бар. Мәсәлән, 1926 елда Таузарда 455 кеше яшәгәнлеге күренә, бу хәтта 1897 елдагы — халык санын беренче мәртәбә алудагы нәтиҗәдән дә кимрәк килеп чыга. Ул чакта 472 кеше яшәгән. Безнең тирәдәге башка авылларда да халык санының артмавы, ә бәлки кимегәнлеге күренә. 1937 елдагы халык саны алу нәтиҗәләре дә Сталин көткәнне күрсәтми. Монысына төп сәбәп 1933 елдагы ачлык һәм аның нәтиҗәсендә кешеләрнең күпләп кырылуы, 30 нчы еллардагы репрессияләр була, бу чорда бик күп кешеләр үтерелә, бигрәк тә ир-атлар саны нык кими.

Шулай да Сталин бу хәлдән нәтиҗә ясый һәм 1939 елда күп балалы аналарга пособие бирү турында закон чыга. Мәсәлән, җиде яки аннан күбрәк бала тәрбияләп үстерүчеләргә берьюлы 2000 сум күләмендә пособие бирелә. Бу — шул чор өчен зур сумма. Бу акчага күп гаиләләр өй салып чыкты. Безнең Таузар илендә андый гаиләләр дүртәү иде.

1. Маһикамал апа белән Усман абыйлар гаиләсендә сигез бала. Менә алар: Зәйтүнә апа белән Оркыя апа (болар Маһикамал апаның элекеге ире Хәйрулла кызлары); Усман абый белән Маһикамал апаның уртак балалары алтау: Мәйсәрә, Фәсхетдин, Кәүсәрия, Гыйльфан, Гыйльван һәм Фәргать.

2. Гарифәбану апа белән Галимулла абыйлар гаиләсендә җиде бала: Габделбарый, Габделхак (болар Гәрифәбану апаның беренче ире Хәбибулла уллары); уртак балалары: Гөлфарый, Өммеһани, Габделхәй, Әминә һәм Мөнәвәрә.

3. Ләмига апа белән Җиһангәрәй абыйларда җиде бала: Исрафил, Манзума, Әдһәм, Нурия, Мансура, Оркыя, Мәгъдүдә.

4. Өммегөлсем апа белән Зәки абыйларда җиде бала: Зәкәрия, Рәҗәп, Рәйсә, Мөдәррис, Тәскирә, Хәкимә һәм Тәлгать.

Бу пособие, соңгы балалары биш яшькә җиткәнче, һәр елны биреп барылырга тиеш була.

1944 елда ун һәм аннан күбрәк бала табып тәрбияләп үстерүче әниләргә Герой ана исеме бирү һәм башка льготалар турында карар чыга.

Безнең авылда Герой аналар икәү: беренчесе Миңлегөл апа. Алар Габдрахман абый белән 12 бала тәрбияләп үстерделәр.

Миңлегөл апа һәм Габдрахман абый Абдуллиннар балалар һәм оныклар арасында.

1. Сәүбән — 1934 елгы, бухгалтер, сәүдә системасында эшләде;
2. Маһиәфтаф — 1936 елгы, Казан медицина училищесын тәмамлап, фельдшер булып эшләде;
3. Фәйрүзә — 1939 елгы, кисүче, тегүче;
4. Тайфә — 1940 елгы, югары экономик белемле хезмәткәр;
5. Бибизарифа — 1942 елгы, укытучы;
6. Сәлмән — 1945 елгы, отставкадагы майор;

7-8. Рөстәм, Мәүлә — 1948 елгы игезәкләр, Чаллыда яшиләр, автозаводта эшлиләр;

9. Халисә — 1950 елгы, тегүче;
10. Зөләйха — 1951 елгы, пешекче;
11. Роза — 1953 елгы, югары белемле тел-әдәбият укытучысы;
12. Әхтәм — 1955 елгы, Ашытбашта механизатор — игенче.

Унике баланың һәрберсе гаиләле. Габдрахман абыйларның 31 оныгы һәм дә оныкларының 35 баласы дөнья күрә, ягъни барысы 12 бала+31 онык+35 онык баласы=78 нәсел дәвамчысы бар дигән сүз.

Габдрахман абый — безнең Шакир бабайның энесе Габдулла улы, ә Миңлегөл апа — күрше Шәмсури апа кызы. Алар соңыннан Кызыл юл районы (хәзерге Арча районына керә), Сталин исемендәге авылга күчеп киттеләр, ул авыл беткәч, Ашытбаш

авылында яшәп, мәрхүм булдылар. Алар турында мәгълүматларны олы уллары Сәүбән бирде. Бу истәлекләрне саклаучы Сәүбән туган бик күркәм холыклы, дингә бирелгән кеше, бөтен гомерен сәүдә хезмәтендә үткәрде.

Икенче Герой ана — Гадәмбану апа. Алар Әдһәм абый белән ун бала тәрбияләп үстерделәр. Хәзерге яшь гаиләләр белән чагыштырганда, Әдһәм абый белән Гадәмбану апаларның иң зур байлыклары — үзара тигез мәхәббәт, бер-берсен хөрмәт итү, чисталык һәм пөхтәлек. Алар Таузардан Карадуганга күчеп яшәделәр. Икесе дә мебель фабрикасында эшли башлагач, бер бүлмәле фатир алдылар. Шул бер бүлмәдә ун бала үсеп, укып чыгып, үз эшләренең остасы булып яшиләр.

Гадәмбану апа һәм Әдһәм абый Зәкиевләр кызлары Нәҗия, киявләре Фидаил, кода-кодагыйлары Оркыя-Исрафил һәм шушы ике нәселне дәвам итәчәк биш оныклары белән.

1. Олы кыз Роза, (1947 елгы), Казан финанс техникумын тәмамлап, авыл Советында баш бухгалтер булып эшләде;
2. Фаил — шофер;
3. Фоат — шофер;
4. Сәгурә — югары дәрәҗәле укытучы;
5. Нурия — авиация техникумын тәмамлаган, мастер;
6. Фәрит — төзүче, ташчы;
7. Галиябану — педучилище тәмамлаган, балалар бакчасы мөдире;
8. Әлфия — урта махсус белемле тегүче;
9. Нәҗия — Казан педагогия училищесын тәмамлаган, балалар бакчасында тәрбияче;
10. Фәридә — экономик белемле, “Игенче” колхозында экономист.

Алар һәрберсе, үз гаиләләрен корып, балалар тәрбияләп үстерделәр. Гадәмбану апа белән Әдһәм абыйның оныклары да 22 булды. Бүгенге көндә ике оныкчыклары бар.

Герой ана исеменнән тыш, күп бала тәрбияләп үстерүчеләргә төрле дәрәҗәдәге “Ана даны” орденнары һәм медальләре бирелә һәм дәрәҗәсенә карап, төрле күләмдә пособиеләр түләнә.

Югарыдагылардан күренгәнчә, халык санын торгызу, арттыру турында реаль кайгыртылган һәм аның нәтиҗәсе дә булган. Хәзер Россиядә халык саны кимү турында бик күп сөйләнелә, ләкин ишле балалы гаиләләргә тормышларын яхшыртырлык реаль ярдәм күрсәтелми диярлек.

Авылда халык саны кимүнең тагын бер сәбәбе — 1937 елдан башлап халыкны гаиләсе белән Көнчыгыш Себер өлкәләренә күчерү башлана. 1937 елның 5 апрелендә Балтач район Советы башкарма комитеты президиумы районнан 240 гаиләне күчерү турында карар чыгара. Таузардан мондый гаиләләр — сигез, Арбаштан — биш, Карадуганнан биш була. Күрәсең, Таузардан мондый гаиләләрнең күбрәк булуы безнең авылның җире аз, эшче көчләре күбрәк булуы белән бәйледер.

Безнең авылдан күчеп китүчеләр Бурят-Монгол автономияле республикасына һәм Иркутск өлкәсенә эләгәләр. Менә ул гаиләләр:

1. Мәрданов Габдулла;
2. Абдуллин Габделхак;
3. Исмәгыйлев Ибраһим;
4. Сабитов Дәүләтбай;
5. Галимҗанов Хәйрулла;
6. Зыятдинов Шаһи;
7. Сәйфетдинов Сәйфулла;
8. Шакирҗанов Гыйльметдин.

Бу гаиләләрдән Мәрданов Габдулла һәм Исмәгыйлев Ибраһимнар гына кабат үзебезнең Таузар авылына кайттылар, калган гаиләләрне язмыш илнең төрле почмакларына таратты.

Билгеле, авылда халык саны кимүгә иң зур тәэсир ясаган чор — Бөек Ватан сугышы еллары. Безнең авылдан сугышка 114 кеше китә һәм шуның 45 е һәлак була. Ләкин авылда кеше саны кимүнең сәбәпләре моның белән генә чикләнми. Район Советы башкарма комитетының сугыш чоры һәм сугыш арты еллары беркетмәләрен караганда, утырыш саен диярлек промышленностьның төрле тармакларына: урман эшенә, күмер, торф чыгаруга кешеләр мобилизацияләү турында карарлар тулып ятуын күрәсең. Моннан тыш, 14 яше тулган ир балаларны, 15 яше тулган кыз балаларны мәҗбүриләп һөнәр мәктәпләренә (ФЗО) җибәрәләр. Призыв (чакыру) өстән төшерелгән план, задание формасында үткәрелә.

Бу кампанияләр вакытында зур булмаган Таузар авылыннан да кырыклап яшь егет һәм кыз туган авылларыннан җибәрелә.

Промышленностьның төрле тармакларына эшкә мобилизацияләнгән кешеләр:

1. Шакирова Зарифа
2. Рәхимова Мәликә
3. Гыйләҗева Гөлҗиһан
4. Гыйззәтуллина Асия
5. Исхакова Хәдичә
6. Галимова Миңзифа
7. Усманова Кәүсәрия
8. Шаһинурова Гөлбаһар
9. Шәрәфетдинова Фәрхинур

ФЗОларга һәм һөнәр мәктәпләренә җибәрелгән кешеләр:

1. Сәгыйтова Рәйсә
2. Төхфәтуллина Гөлҗәүһәр
3. Мәрданов Габделфәрт
4. Исхакова Гөлфарый
5. Хәбибуллина Җүәһирә
6. Хәбибуллина Гарифә
7. Хәлиуллин Рафаэль
8. Галимҗанов Шәкүр
9. Төхфәтуллина Мәдинә
10. Исхакова Өммеһани
11. Шәяхмәтова Маһиҗиһан
12. Гарипова Мөсәвирә
13. Сафина Мөнәвәрә
14. Шакиров Шамил
15. Гарипова Әлфия
16. Исхаков Габделхәй
17. Шәрәфетдинова Әлфия
18. Хәбибуллин Гатаулла
19. Төхфәтуллина Гөлирам
20. Гарипов Вазыйх
21. Хәлиуллин Тәбрис
22. Шаһиева Фатыйма
23. Шакирҗанов Рәфәгать
24. Сәгыйтова Нәкыя
25. Сәгыйтов Мазһар
26. Галиев Шамил
27. Хаҗиева Сәйдә
28. Шәрәфетдинова Маһидилбәр
29. Фәйзерахманов Габдерәүф
30. Габдуллин Фаяз

Бу исемлектәге кешеләрдән Мәрданов Габделфәрт, Хәлиуллин Рафаэль, Фәйзерахманов Габдерәүфләр Ватан сугышына китеп, һәлак булдылар. Исемлектәгеләрнең күпчелеге шулай ук кабат авылга кайтмады, шул киткән шәһәрләрендә калдылар.

Алда авыл халкының кимүе, аның сәбәпләре әйтелде. Сугыш бик күп ир-атларны юк итте. Ә сугыштан соңгы елларда тормыш тиз генә рәтләнә алмады. Сугыш җимереклекләрен торгызу да авыл халкы җилкәсенә төште. Һәртөрле түләп бетермәслек мәҗбүри салымнар: ит, сөт, йомырка, йон, бәрәңге һ. б тапшыру; төрле исемдәге заемнар авыл кешесен авыр хәлгә калдырды. Колхозда хезмәткә түләү юк дәрәҗәсендә түбән иде. Менә шул шартларга түзә алмыйча, читкә "бәхет эзләп" китүчеләр дә күп булды. Читкә китү дә бик авыр — аның матди ягы гына түгел әле, китәргә рөхсәт тә юк. Чөнки колхозчы крепостной хәлендә, аңа паспорт бирелми. Шундый шартларда да китә алганнарны булдыклылар дияргә кирәктер.

Менә алар:

1. Безнең терәлеп торган күршебез һәм кодабыз Шәрәфетдинов Фәттах (Миңлемулла) абый хатыны Рабига апа, кызы Маһидилбәр һәм улы Мөдәррис белән Казанга килеп урнашты. Фатирлары үзәк колхоз базары янында гына иде, шуңа Таузарның Казанга эш белән килгән барлык кешесен дә сыендырдылар, киң күңелләләр иде, күп кешеләрнең рәхмәтен ишеттеләр.

2. Әтинең сеңлесе Нурлыхода апа белән Мөбарәкҗан җизни Шәрәфетдиновлар уллары Мөкатдәс, Марат, Мәгъфур, кызлары Гөлзадә белән Юдино бистәсенә килеп урнаштылар. Тимер юлда эшләделәр. Аларның зур булмаган фатиры безнең өчен дә җылы почмак, сыену урыны булды, без аларга бик рәхмәтле.

3. Гыйләҗетдинов Сөнгатулла абыйның зур гына гаиләсе Магнитогорскига китеп, шунда яшәп калды. (Бу турыда киңрәк итеп алда язылыр.)

4. Каршы як күршебез Төхфәтуллин Әхми үлгәннән соң, хатыны Хәтирә апа кызы Гөлзәминә, улы Шәкүр белән Урал ягына китте, авыл белән элемтәләре бөтенләй өзелде.

5. Сабира апа Ибәтуллина улы Гыйльмулла белән шулай ук Урал ягына китте.

6. Хәкимова Маһинур апа улы Искәндәр белән Ташкентка китте, шунда яшәп калдылар.

7. Хәкимова Шәкүрә апа кызы Сәгура белән Урта Азиягә күчеп китте.

8. Шәяхмәтов Каюм абый хатыны Бибинур апа, балалары Маһиҗиһан, Мәгъфурә, Дамирә, Гөлнура, Илдар белән Ташкентка китте.

9. Насруллина Зәкия апа уллары Рәшит, Вәдүт, кызлары Наилә һәм Раузаны алып Казанга күченде, шунда гомер иттеләр.

10. Хәсәнов Вәли абый үлгәннән соң, хатыны Хәдичә апа улы Барый белән күчеп китте.

11. Гарипов Фатыйх абый үлгәннән соң (хатыны Зәйнәп апа алдарак үлде), балалары Вазыйх, Нәкыйп, Зөлфирә, Нәфыйк, Рәфыйк һәм Гөлчирә әниләре ягыннан туганнары Газзәбану һәм Мәрьям апа янына Юдино бистәсенә китеп, шунда сыену урыны таптылар.

12. Әти-әнисез калган Галимов Наил һәм Ләлә Мәрзия апалары янына Пермь өлкәсенә киттеләр, хәзер Түбән Кама, Чаллыда яшиләр.

13. Әхмәтханов Хаҗи абыйның тол калган хатыны Миңсара апаны сугыш елларында төрмәгә утырталар, ә балалары Зөлхәбирә, Гөлзәйнәп, сабакташым Муллаәхмәт төрлесе төрле җиргә таралды.

Авылда "аргыяк" дигән исем алган безнең як урамыннан гына 13 гаилә һәм аларның киләчәк өмете булган 38 яшь кеше Таузарга әйләнеп кайтмады, чит җирләрне үз итеп яшәп калдылар.

Авыл буенча бирге якка чыгып күңелсез "сәяхәтебезне" дәвам итик:

14. Вәлиуллин Гомәр абый сугышта үлде, хатыны Сәйдә апа да 1944 елны дөнья куйды, балалары Мәсхүт һәм Газзә авылдан киттеләр — йортлары бетте.

15. Аларның күршесе (безнең туганыбыз) Низаметдинов Галәветдин абый сугышта үлгәч, олы улы — минем сабакташ дустым Икрам әнисе Сәхибҗамал апаны, сеңелләре Нурсөя, Бәрия һәм Нажияне дә үзе белән алып, еракка — Кемерово өлкәсендәге шахтерлар шәһәре Киселевскига күчеп китте, шунда яшәп калдылар.

16. Ире Нуриев Рәхим абый фин сугышында үлгәннән соң, Нәфисә апа кызлары Люция, Дания, Расиханы алып, Казанга китеп урнашты.

17. Нәбиуллин Хәбибулла абый хатыны Миңсылу, балалары Кадимә һәм Гыйниятне алып, авылдан китте, йортлары ябылды.

18. Әтинең икенче сеңлесе Хәбибҗамал апа (Якуб җизни Касыймов үлгәннән соң) балалары Гамбәрбикә, Ләбибә, Розалина,

Рәкыйп белән Аракчинога китеп, шунда һәрберсе үзенчә эшкә урнашып, яшәү шартларын көйләделәр.

19. Әниебезнең туганы Ганиева Бибиәсма апа уллары Мөдәррис һәм Рәис, кызлары Сәйдә белән авылдан китеп, Казахстанда яшәүче туганыбыз Фәхерниса апай янында сыену урыны тапты, шунда яшәп калдылар.

20. Әгъзәмов Әхми абый гаиләсе авылдан күчеп китте.

21. Түбән урамнан Фазылов Әгъләм абый гаиләсен калдырып киткәч, хатыны Галия апа балалары Закир һәм Внура белән Юдинога китеп урнашты.

22. Безнең Шакир бабайның энесе Мөхәммәтҗанов Нурмөхәммәт кызы Нәгыймә белән Пөшәңгәрдә яшәүче икенче кызы Язилә янына күчеп китте. Элек мәчеттә мәзин хезмәтен башкарган Нури бабай, диннең кысылган елларында да иплэп кенә авылдашларына имамлык эшен башкарып, игелек күрсәтте. Мәрхүм бик гыйлем кеше иде.

23. Җәләлетдинов Минһаҗ хатыны Сәрвәр апа, балалары Извил, Альберт, Илгизәр, Рафаэль, Мәүлияләр белән Балтачка күчеп урнашты.

Тулы булмаган бу исемлектә шул елларда күчеп киткән 23 гаилә, алардагы авылның киләчәге булырдай 62 бала туганүскән җирен калдырды.

Исемлектәгеләрнең күпчелеге шулай ук кабат авылга кайтмады, шул киткән шәһәрләрендә калдылар. Шулай итеп бу елларда авыл халкы күпкә кимеде.

Әй язмыш, язмыш... Кемнәрне генә кайсы сукмаклардан йөртмисең! Болар арасында ятимә үскән Гомәрова Хафизә дә бар әле. Ул үзенең яхшы укуы, матур җырлавы, чибәрлеге белән туган авылында, “илдә мин дә сандугач” дигәндәй, чәчәк булып яшәргә тиеш иде кебек. Балтач урта мәктәбенең сигезенче классын тәмамлагач (1944—1945 елларда), алга таба уку өчен акча түләү мөмкинлеге булмаганлыктан, мәктәпне ташлый. Соңга таба исәп-хисап эшенә кызыксынып, финанс техникумында (башта Сабада “РКШ”да, аннан Казанда) укый. Юллама аны Чүпрәле районы авылына китерә. Анда хәрби офицер белән гаилә корып, Төмән-Омск якларына китеп урнашалар. Бер улы дөньяга килгәч, хәрби ире үз юлы буйлап китә. Ә улы Тимур Омск музыкаль театрында җырчы артист һәм композитор була. Хафизә шул бухгалтерлык һөнәрендә 65 яшенә кадәр эшли. Газиз улы фаҗигале вафат булгач, читтә йөрүләрдән арыган Хафизә 2002 елның көзендә, туганнары ярдәме белән, үз ягыбызга кайтып урнаша.

Авылда үзидарә

Революциягә кадәр авылда җирле үзидарәнең бер формасы буларак старосталар эшләгән. 1862 елгы ревизия вакытында Таузарның старостасы Ермәк Бикбулатов була. Шулай ук муллалар сайлау документларыннан күренгәнчә, Таузарда Хәсән Рәхмәтуллин һәм Фәсәхетдин Шәрәфетдиновларның староста булганлыгы билгеле. Минем бабам Зыятдин да староста булып тора. Октябрь революциясеннән соң аларны авыл Советлары алыштырган. 1918 елдан алып 1932 елга кадәр Таузарның үзенә аерым авыл Советы була. Татарстан Республикасының милли архивыннан алынган материаллардан күренгәнчә, 1918—1922 елларда авыл Советы рәисе булып Хәлиуллин Хәсбиулла эшләгән, 1922—1924 елларда әтинең абыйсы Зыятдинов Гомәр, 1924—1925 елларда Нәҗметдинов Җаббар, 1926—1927 елларда Зәкиев Җиһангәрәй, 1929—1930 елларда Шакирҗанова Маһинур, 1925—1926, 1927—1929, 1931—1932 елларда Шәяхмәтов Каюмнар рәис булып эшләгәннәр. Ә секретарьлар булып төрле елларда Сәгыйтов Зәки, Төхфәтуллин Йосыф һәм шул ук Шәяхмәтов Каюм эшләгән. Югарыда телгә алынган Шакирҗанова Маһинур Шубан авылында да авыл Советы рәисе булган, архив документларыннан аның партия члены булганлыгы да күренә. Бу исемне кертеп бер кызыклы гына вакыйга сөйлиләр. Шубан кешесе Балтачка волостька ниндидер документ алырга төшкән дә, кайсы авыл Советыннан икәнен сорагач: “Майнурский сельсовет”, дип җавап биргән, ди. Бу төр җавап ашлык тапшыру документларында да очраган, “Шубан авыл Советы” дип, дөресе өстәп язылган.

1932 елдан соң авыл Советлары эреләндерелә һәм безнең Таузар авылы Арбаш авыл Советы составына керә. Соңрак бу авылларны Карадуган авыл Советына берләштерделәр. Арбаш авыл Советында да Таузар кешеләре рәислек иткән чор шактыйга җыела. 1934—1935 елларда Арбаш авыл Советы рәисе булып Шәяхмәтов Каюм эшли, 1938—1941 елларда Хәкимов Мәгъсүм рәислек итә. Ул сугышка киткәч, аны Яппаров Якуп алыштыра, аннары ул үзе дә сугышта булып, аннан кайткач, озак еллар шушы эштә эшли. Таузарлылар Әхмәтов Җәләй һәм Хәлиуллин Миннехан шулай ук Карадуган авыл Советында рәислек иттеләр.

Авылда колхоз төзелү

Ил тарихында тирән эз калдырган колхозлашу безнең авыл халкының яшәешен тамырдан үзгәртә.

Колхоз төзү — ул хосусый милекне берләштерү, гомуми милеккә әйләндерү. Атыңны бөтен дирбияләре, арбасы, чанасы, сука һәм тырмалары белән бернинди түләүсез колхозга бирәсең, сыерың, ашлык амбарларың да гомуми милеккә әйләнә. Чәчүлек ашлыгыңны шулай ук тапшырасың. Ә бирәү атсыз килеш, чәчү орлыгы тапшырмаган килеш тә шул колхоз члены була. Бүгенге көн кешеләре ул вакыттагы авыл кешесенең авыр психологик халәттә булуларын күз алдына китерә алмыйлардыр. Ә колхоз төзү ни өчен кирәк булган соң? Революция һәм Гражданнар сугышыннан соң хуҗалыкны торгызу һәм илне индустрияләштерү фәкать крестьян җилкәсендә булган. Беренчедән, совет хөкүмәте патша Россиясе алган бурычлардан баш тарткан, икенчедән, Бөтендөнья революциясен максат итеп куючы капиталистик илләрне бик нык куркыткан, алар совет хөкүмәте белән хезмәттәшлек итәргә теләмәгәннәр.

Тарихтан белгәнебезчә, крестьянның икмәген алу өчен "продразверстка", "продналог" дигән җыемнар үткәрелгән, аның өчен "продотряд"лар төзелгән. Ашлыгын бушка яки ярымбушка алу крестьянның икмәкне яшереп калырга тырышуына китергән, ул күп ашлык җитештерү белән кызыксынмаган. НЭП үткәрү дә аптыраганнан килеп чыккандыр. Революция һәм Гражданнар сугышы чорында таланган, җимерелгән халык хуҗалыгын шәхси инициативага ирек биреп кенә торгызырга мөмкин булган. Халык хуҗалыгы чыннан да торгызыла башлаган, илдә алга китеш күзәтелгән, шул ук вакытта бу капитализмга кире кайту дип каралган. Ә бит революция капитализмны бетерү өчен ясалды. Шуңа күрә НЭПтан баш тартырга туры килә. Һәм шул ук вакытта, 1929 елда коллективлаштыру, ягъни колхозлар төзү кызу темплар белән башлана. Эре хуҗалыклар булганда гына авыл хуҗалыгын үстерергә, механикалаштырырга мөмкин диелсә дә, аның нигезендә башка сәбәп тә булган. Әйтик, 1930 елларда Балтач районында ун меңгә якын шәхси хуҗалык булган. Аның кадәр хуҗалыкның амбарын карап чыгарга бернинди вәкил дә, милиция дә җитми. Ә 40-50 колхозны, аның ашлык амбарын тик-

шереп тә, икмәк заданиесен үтәүне контрольләп, кирәксә, бөтен ашлыгын чыгартып бетереп тә була.

Күмәкләштерү эшендә Сталин мәҗбүр итү тактикасын гына алып бармаган, мәгълүм әйтемдәге "камчы һәм перәннек" сәясәтен кулланган.

"Көрәш" колхозының беренче рәисе Гарипов Гафурҗан.

Таузар авылында колхоз 1929 елда төзелә башлаган. Аны оештыручы кеше Казанда партия мәктәбендә укучы Гарипов (Исмәгыйлев) Гафурҗан була. Ул үзе Исмәгыйль улы, аны Хәсән Гарифы балалыкка алып тәрбияли һәм шуңа ул Гарипов фамилиясен йөртә. Колхозга башта 14 хуҗалык керә, шул исәптән минем бабам Зыятдин, аның энесе Гыйләҗетдин хуҗалыклары, шулай ук Хәбибрахман абый, Исмәгыйлев Ибраһим, Галимҗанов Һадиҗан һ. б. Беренче колхозга җирне иң уңдырышлы урыннан бирәләр, дәүләткә түләүләр дә булмый. Алар өлеше колхозга кермәгәннәргә өстәп түләтелә. Шуңа мул уңыш алып, хезмәт көненә дә уңышны мулдан бүләләр һәм бу 1930 елдан колхозның ныклап төзелеп китүенә нигез була. Башка авыллардагы кебек, колхоз таралу һәм аны кабат җыю булмый кала. Колхозга "Көрәш" исеме бирелә һәм ул исем 1950 елда өч авыл (Арбаш, Карадуган, Таузар авыллары) бер колхозга берләшеп, Калинин исемендәге колхоз булып оешканчы саклана. Колхозның 1933 елдан башлап 1940 елга кадәрге отчетлары Республика архивында саклана, тик 1930, 1931, 1932 еллар турында мәгълүмат юк.

1933 елгы отчеттан күренгәнчә, колхозда 89 хуҗалык булып, барлыгы 428 кеше исәпләнә һәм шулардан 222 се эшкә яраклы дип санала. Шуның эченнән 7 хуҗалык колхозга 1933 елда керә һәм аларның 4 се атлы хуҗалык була. Бу уңайдан әле Түбән Кенәдә 53 хуҗалык, Кенәбашта 39 хуҗалык, Көшкәтбашта 133 хуҗалыкның (авылдагы хуҗалыкларның яртысыннан артыграгы) 1933 елда гына колхозга кергәнлеген әйтергә кирәк. Нигездә, колхозлашу шул вакытта тәмамлангандыр, чөнки 1934 елгы һәм аннан соңгы отчетларда колхозга яңа кергән хуҗалыклар күрсәтелмәгән.

Колхозның барлык җир мәйданы 610 гектар булып, шуның 560 гектары — сөрү җирләре. 89 хуҗалыкның 64 е сыерлы,

8 енең таналары бар. 17 сендә сыер да, тана да юк. Сыерлы хуҗалыкларның чагыштырма саны буенча Таузар авылы Арбаш, Карадуган, Кенәбаш авыллары рәтендә була (Хәсәншәех, Шубан авылларының сыерлы хуҗалыклары саны чагыштырмача аз). Колхозда атлар 57 баш булып, шуларның 49 ы — эш аты. Мөгезле эре терлекләр 59 баш: шулардан 1 баш сыер, 2 баш үгез һәм 56 тана була. Колхозда 30 сабан, 3 чәчкеч, 1 урып-җыю машинасы — лобогрейка, 2 сепаратор, 2 атлы сугу машинасы, 5 ике атлы арба, 41 башка төрле арбалар була. Колхозда 1933 елда 4150 ц ашлык җыеп алына, бу 1 гектардан 9 ц чамасы: арыш уңышы 7,43 ц, бодай — 11,1 ц, арпа — 14,6 ц, тары — 14,6 ц, солы — 10 ц була. Барлык сөрү җиренең өчтән берен алып торган арыш уңышны азрак биргәнлектән, 1 гектардан уртача уңыш зур булмый. Барлык ашлыкның 25% чамасы, ягъни 1051 центнеры дәүләткә тапшырыла, 1394 центнеры хезмәт көненә колхозчыларга бүленә. Бу барлык уңышның өчтән бере дигән сүз. Бер хезмәт көненә 7,464 кг икмәк бүлеп бирелә.

1934 елда уңыш район буенча да зур булмый. Күрәсең, ел коры килгәндер һәм хезмәт көненә 1,1 кг гына икмәк бүленә. 1935 елда уңыш 1 гектардан 10,41 ц, ә арпадан 17 ц була. Беренче ашлама кертелмәгән җирдән алынган бу уңыш ул чор өчен әйбәт санала, ә Арбашта уңыш 1 гектардан 6,54 ц, Карадуганда 7,91 ц була. Бу елны "Көрәш" колхозында һәр хезмәт көненә 5 кг икмәк бүлеп бирелә. Күрше Арбаш — Калинин исемендәге колхозда 1 хезмәт көненә 2,9 кг, ә Карадуган — "Мәгариф" колхозында 1 хезмәт көненә 2,35 кг икмәк бүленгән.

Гомумән, сугышка кадәр "Көрәш" колхозы районның иң алдынгы колхозларыннан санала, ул МТС хезмәтеннән файдаланмый, шуңа натуралата түләүгә (МТС хезмәте өчен натуралата түләнә) икмәк тапшырмаганлыктан, хезмәт көннәренә ашлыкны күрше авылларга караганда шактый артык бүлә. Сугышка кадәр ашлык иң яхшы уңган 1937 елда Таузарның "Көрәш" колхозында бер хезмәт көненә 9,8 кг уңыш бүленә, Арбашта бу күрсәткеч 5,48 кг, Карадуганда 5,5 кг, Түбән Шубанда ("Шушмабуй" колхозы) 6,8 кг, Югары Шубан ("8 Март" колхозы) 6 кг, Түбән Кенәдә ("Кызыл чишмә" колхозы) 7,5 кг, Хәсәншәехта ("Кызыл көч" колхозы) 7,25 кг, Кенәбашта ("Марс") 7,27 кг була. Бу фикерне нигезләү өчен тагын бер елгы саннар китерик: 1940 елда "Көрәш" колхозында бер хезмәт көненә 1,8 кг ашлык бүленә, ә бу сан "Мәгариф" колхозында 250 г, Калинин исемендәге колхозда 1,1 кг, Югары Шубанда 650 г, Түбән Шубанда 800 г, Түбән Кенәдә 990 г, Балтачта (Ленин исемендәге колхоз) 700 г, шулай ук рай-

онның алдынгы колхозларыннан саналган “Марс” (Кенәбаш) колхозында 2,2 кг була. Җир мәйданнары һәм хуҗалыклар саны берберсенә якын булган Таузар һәм Карадуган авылларындагы колхозларны чагыштырсак, “Көрәш” колхозының нык колхоз булуы күренеп тора.

Сугыш алдыннан колхозның фермасы да зурая. Мөгезле эре терлек саны 38 булып, савым сыерлар 18 баш була. Шуңа өстәп сарык фермасы да төзелә һәм анда 17 баш сарык була. Ә сөрү җире генә дә 1824 гектар булган (Таузарныкы 560) Калинин исемендәге колхозда (Арбаш авылы) 12 баш сыер, 69 баш сарык; “Мәгариф” колхозында 26 баш дуңгыз, 12 баш сарык булган.

Хезмәт көненә ашлык бүлү турында сүз барганда, шунысын әйтик: трактор хезмәте кулланылган колхозларда, уңыш нинди булуга карамастан, механизаторларга хезмәт көненә 3 кг нан ким бирмәү гарантияләнгән.

Таузар авылы игенчелектән тыш яшелчә үстерү белән дә нык шөгыльләнә. Мин колхозда күпләп кыяр, кишер, кәбестә, чөгендер үстергәннәрен хәтерлим. Кыяр, кишер бакчаларына яшерен сәяхәтне ясамаган малайлар булмагандыр дип беләм. Болай үзе һәрвакыт каравылчылары була иде.1937 елда хезмәт көненә бүлгән яшелчә белән безнең бер лапас (без аны трантас лапасы дип йөртә идек, чөнки аерым хуҗалык вакытында анда безнең трантас торган) тулган иде. “Көрәш” колхозы районда орлык өчен яшелчә үстерү белән дә шөгыльләнә иде һәм ул да колхозга күпмедер керем китерде. Яшелчәчелек буенча безнең як колхозларында агроном булып безнең авыл кешесе Хәлиуллин Хәсбиулла абый эшләде. Ә яшелчәчелек бригадасы белән шактый еллар Мусина Рабига апа җитәкчелек итте. Таузарда үз авылы кешеләре генә рәислек итте. Колхоз төзүче һәм беренче рәисе Гафурҗан абыйдан соң 1931 елда Ганиев Габдрахман күпмедер вакыт рәислек иткән, аннан соң Хәбибуллин Солтангали, Сафин Хәлиулла, Зәкиев Җиһангәрәй, Гыйльметдинов Фәттах, Зыятдинов Шәймулла, Шәяхмәтов Каюм һәм Яппаров Якуплар колхозның рәисләре булып эшләгәннәр.

Сугышка кадәр колхозларга дәүләтнең ярдәме булмады һәм ул була да алмагандыр, чөнки илне индустрияләштерү дә шул авыл халкы хисабына алып барылды. Шуңа колхозчының тормышы табигать шартларына бик бәйле: иген уңса — аның тамагы тук, ә уңмаса — ярым ач иде.

Минем әти Шәймулла 6 ел “Көрәш” колхозында бригадир булып эшләде. Шуңа аның сөйләгәннәреннән һәм үзем күргәннән

колхоз тормышының күп нәрсәләре, гыйбрәтле вакыйгалары истә калган.

Безнең колхоз өч кырчылык бригадасыннан тора иде. Бригадалар арасында ярыш (ул социалистик ярыш дип атала) шул вакыт өчен көчле оештырыла. Бигрәк тә урак өстендә һәр көн җиңүче бригада ачыклана, аңа Кызыл байрак бирелә, ә арттагысына — чыпта байрак. Стена газетасы да регуляр чыга, анда алдынгылар макталу белән бергә, арттагылар нык тәнкыйтьләнә. Шуннан бер очрак: ни сәбәптәндер күрше Әнвәр апа эшкә соңга калган һәм аны стена газетасына йоклатып, зур кызыл борынлы итеп ясаганнар. Аның "минем борыным шундый ук түгел", дип үпкәләп йөргәне истә калган. Ике бригадада лобогрейка дигән уру машинасы белән уралар иде, бер кеше ат куа (машинага таза ике ат җигелә), ә бер кеше урган ашлыкны агач сәнәк белән берәр көлтәлек итеп ташлатып бара. Сүз дә юк, бу кешегә бик авырга туры килә, ул тирләп чыга, шуңа ул ургычка "лобогрейка" дип, бик характерлы дөрес исем бирелгән. Ә икенче бер ургыч "самоброска" дип атала, ул урган ашлыкны (учма) үзе ташлата.

Билгеле, халыкның тормышы авыр булу төрле хикмәтле хәлләрнең килеп чыгуына сәбәп була. Шулай ферма көтүен көтүче Заһидулла абый бригадирдан (этидән) аягына чабата ясарга дип, эштән калырга сорый һәм эти риза була. Шуннан кич наряд вакытында, эшкә кеше бүлгәндә, бригадир колхоз рәисе Солтангали абыйга Заһидулла урынына Гайфулла абыйны бер көнгә колхоз көтүенә чыгарып торырга кирәк булуын әйтә. Солтангали абый (ул яшь — 21-22 яшьләрдә) риза булмыйча, "шуны да чыгара алмаска", дип әтәчләнеп, Заһидулланы чабатасыз эшкә чыгарырга уйлый, ләкин тегесе барыбер чыкмый. Икенче көнне нарядка кадәр бригадир Заһидуллага кереп: "Үз эшеңә — көтүгә чыгарсың инде, Гайфулла абый башка эшкә кирәк", — ди. Ә Заһидулла: "Мин хәзер колхоз түгел, Солтангали мине колхоздан куды", — ди. Эти: "Ярар инде, колхоз (Заһидулла "колхозчы" сүзен әйтә алмый) булырсың", — дип карый. Ә тегесе: "Мине син чыгармадың колхоздан, Солтангали чыгарды", — дип, көтүгә чыгудан баш тарта. Шуннан икенче көнне Солтангали абый өйләренә барып, Заһидулла абыйны "колхоз" ясап кайтырга мәҗбүр була.

Тагын бер хәтергә сеңеп калган вакыйга: колхозда наряд — эшкә бүлү (һәр ат, һәр кеше көн саен эшкә бүленә) иртән иртүк була. Ләкин еракка эшкә барасы булса, иртүк чыгып китәсен истә тотып, бригадир эшне кичтән куша. Шулай Вәли абый дигән кешегә бригадир кичтән урманга барасын әйтеп куя. Гадәттәгечә,

колхозның планы үзгәреп тора, ни сәбәптәндер урманга барасы булмый һәм бригадир, Вәли абый чыгып киткәнче дип, өенә кереп: “Сезгә урманга барасы булмады инде, син салам алып кайтырга барырсың”, — ди. “Һай, Шаһимулла, мин бит урманга барырга дип ашаган идем, ник кенә нарядны үзгәрттегез”, — дип уфтанган Вәли абый. Сүз чыккач, Вәли абый турында (мәрхүм, урыны оҗмахта булсын) берничә сүз әйтү урынлы булыр. Вәли абый буйга озын булмаса да, киң җилкәле, бик таза кеше иде. Андый кешеләр турында төптән юан чыккан, диләр. Ул эшкә гаҗәп булган кеше. Кемдер бик нык эшләсә, “Вәли күк эшли” дип әйтерләр иде. “Аның болында печән чапканын карап тора идек: покосы кешенекенә карганда күпкә киң, бөтенесеннән алдан бара, иң гаҗәбе — шулкадәр такыр калдырып чаба, аның артыннан йомырка тәгәрәтерлек”, — дип сөйлиләр иде. Ашаганнан соң ул, кешеләр утырып ял иткәндә, ял итмичә чаба башлый. Шуңа аңа хезмәт көнен 1,5 норма белән язалар һәм ашауны да шулай ашаталар. Ул кадәр эшләү өчен тиешле ашау да кирәген аңлап, иптәшләре бу хәл белән килешәләр иде. Аның печән чабуы турында тагын бер хикмәт сөйләгәннәре истә калган. Колхозлар төзелгәнче Карадуган янындагы Ишморат болынында ялланып печән чабучылар эшкә тотынганнар һәм ни сәбәптәндер бераз соңга калган Вәли абыйны башкалар артыннан өлгермәс дип, араларына кертмәскә булганнар. Шуннан, ялына торгач, “чапса чабып карасын” дип риза булганнар. Ул кыска гына вакытта тегеләрне куып та җиткән, узып чабарга да керешкән. Шуннан бай: “Бу янып үләр, туктатыгыз”, — дип, эшен әкренәйттергән. Ни кызганыч, шундый эшчән кешенең тормышы гаепсезгә төрмәдә өзелде. Бу турыда алдарак язылыр.

Тамак туклыгы мәсьәләсе колхозда һәрвакыт көн тәртибендә торды. Һәр көнне өйлә вакытында урып-җыючыларга пешкән ипи өләшәләр. Аны үлчәп биргәндә сыныклары да була. Әниләр амбардан ипи алып кайтканда, яследән (хәзергечә әйтсәк балалар бакчасыннан) каршыларына чыгып, шул сыныкларны алып калуыбыз хәтердә калган. Бәләкәй генә булсам да, яңа пешкән ипи кисәгенең тәме әле дә телемдә кебек. Сугышка кадәр колхозларда сезонлы ясле-бакчалар да оештырыла иде.

“Көрәш” колхозы Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соң

Сугыш башлану турындагы хәбәрне үземнең ничек кабул итүем истә дә калмаган. Балалыгым беләндер. Яшьләр ул сугышның озакка сузылып, зур афәтләр алып киләсен күз алдына да китермәделәр, чөнки пропаганда: “безгә каршы сугыш башласалар, ул дошман җирендә генә барачак һәм дошман тиз тармар ителәчәк” дип алып барылды. Ләкин беренче Герман сугышында булучылар, шул чор кешеләре, аны күзаллаганнар. Бу уңай белән Исрафил абый истәлекләре гыйбрәтле. Сугыш башлану хәбәре килгәндә Исрафил абыйның Һадиҗан абый белән түбә ремонтлап яткан чагы булган. Бу хәбәрне ишеткәч, Һадиҗан бабай кулындагы бөтен әйберен тотып ыргыткан. Исрафил абый: “Нәрсә ул кадәр исең китте, каккалап бетерик инде”, — дигәч, сугышны күргән абзый: “Әй, сез яшьләр Герман белән сугышның нәрсә икәнен аңламыйсыз бит”, — дип, аны әрләп ыргыткан. Ләкин бу сугышның озакка сузылачагын олыларның да һәммәсе аңлап бетермәгән иде әле. “Үзем сугыш яшеннән чыккан, малаем әле 15 яшьтә генә, афәт безгә кагылмаячак”, диючеләр улларының 17 яшьтән сугышка алынып, шунда һәлак булачагын башларына да китермәгәннәр. Чөнки тыныч елларда армиягә 20 яшьлек егетләрне генә алалар иде.

Һәр көнне авылдан 5-6 ир-егет сугышка алына башлагач, шом һәрберебезнең күңелләренә үтеп керде. Бөтен ил өчен зур афәт буларак, колхоз һәм колхозчылар тормышын чиктән тыш авырайтты сугыш. Ир-атлар фронтта, хәтта яхшы атлар да сугышка алынды. Моның өстенә хатын-кызлар, олырак яшьтәге ир-атлар оборона корылмалары төзүгә — окоп казуга тартылды. Шулай да сугыш башланганчы чәчелгән иген әйбәт кенә уңды, аны урып-җыюда фронтка чиратлары җитмәгән ир-атлар да катнаша алгач, ул уңай гына җыйналды. Элеккеге запаслар да булгандыр, шуңа күрә сугышның беренче елында ачлык үзен артык сиздермәде.

1942 елда инде сугыш авырлыклары үзен нык сиздерә, иген уңышы да түбән була.1942 елда “Көрәш” колхозында 1 гектар җирдән 4,43 ц, Калинин исемендәге колхозда (Арбаш) 2,1 ц, ә

"Мәгариф" колхозында (Карадуган) нибары 1,65 ц гына уңыш алына. Балтач район Советы документларыннан күренгәнчә, район буенча 1943 елда язгы чәчү планы 65% ка гына үтәлгән, язгы чәчү 60-65 көнгә сузылган. Билгеле, мондый шартларда уңыш та бик түбән була. Бу халыкның ач калуына, терлекләрнең күпләп үлүенә китерә. Атларга түбә саламына халыктан җыелган бәрәңге пешереп кушып, башак ашатырга мәҗбүр булалар, алай да ачлыктан атлар үлә. Менә шул хәлләрнең фаҗигасе буларак, атлар үлүдә гаепсезгә гаепләп, безнең колхоз рәисе Сафин Хәлиулла, ат караучылар Хәсәнов Вәли һәм Мәрданов Шаһинур абыйларны төрмәгә утырталар. Вәли абый һәм Шаһинур абый шунда мәрхүм булдылар, ә Хәлиулла абый төрмәдән чирләп кайтып, күп тә тормыйча, авылда үлде.

Шушы фаҗигале һәм иң авыр чорда "Көрәш" колхозына рәис итеп сугышта бер аягын калдырып кайткан әтием Зыятдинов Шәймулланы сайлап куйдылар. Аның рәислек итә башлаган вакытында мин инде 14 яшьлек малай идем һәм ул вакыйгаларның шаһите дә булдым. Мәктәп укучысы гына булсам да, Таузар авылының хат ташучысы да идем үзем. Солдат гаиләләренә шатлыклы хатлар да, кара печатле язулар да тапшырырга һәм күп очракларда аларны укып та бирергә туры килде. Бу алфавит алмашыну белән бәйле иде. (Күп кешеләр хатларны авырдан яза һәм укый торган вакыт булды бу.) Күп кенә карчыкларга хатны укып кына түгел, язып та бирергә туры килә иде. Мин каникул чорында ат белән, Тукай әйтмешли, "җирне аз-маз сукалап, чәчкән идем, урган идем". Җиденче классны бетергәч, бер елга укуны туктатып торып, колхозда эшләргә дә кирәк булды.

Әти рәислек итә башлаганда колхозда тимерче дә юк иде. Язгы чәчүгә сука, тырма-чәчкечләрне хәзерләү өчен күрше Кенә авылыннан тимерче Бәхтияров Закир абыйны алып төште әти. Аның тамак ягын кайгырту өчен Күлтәс колхозыннан бер капчык бодайны әҗәткә алып кайтканы нык искә кереп калган. Аннан соң инде даими тимерче итеп Мирҗәм егете Каюмны эшкә алды. Чәчү ашлыгын да хатыннар Шәмәрдән станциясеннән чана белән тартып ташыдылар. Шулай итеп, зур авырлыклар белән чәчү чәчтеләр, бер гектар да буш җир калдырмадылар. 1945 елны да колхоз язгы чәчүне тиешенчә үткәрде һәм уңышны да күрше авылларга караганда уңайрак алды. Таузар авылы аша агучы инештә электр станциясе төзү проекты 1945 елда, колхоз рәисе Зыятдинов Шәймулла чорында эшләнде. Ватан сугышы тәмамлангач, исән калган авылдашлар кайта башлады. Ниһаять, әтигә үзе кулдан ясап өстәгән агач аяк һәм бер таяк белән җәяүләп тарткан колхозны

яшьрәкләргә тапшыру мөмкинлеге туды. 1945 елның ахырында колхоз рәисе итеп Шәяхмәтов Каюм сайланды.

"Көрәш" колхозы сугыш арты елларында да күршеләренә караганда уңайрак барган, иген уңышы да бездә чагыштырмача югарырак (1 гектарга туры килгән центнерларда):

	1946	1948	1949
"Көрәш" (Таузар)	**5,2**	**7,08**	**5,3**
"Мәгариф" (Карадуган)	**3,7**	**2,45**	**3,7**
Калинин ис. (Арбаш)	**2,0**	**4,04**	**4,04**
"Кызыл чишмә" (Т. Кенә)	**3,71**	**3,53**	**4,7**
"Кызыл көч" (Хәсәншәех)	**3,26**	**4,2**	**3,5**
"Шушмабуй" (Т. Шубан)	**3,10**	**2,8**	**3,58**

1950 елның 11 июнендә Калинин исемендәге колхозны (Арбаш), "Мәгариф" (Карадуган) һәм "Көрәш" колхозын (Таузар) берләштерәләр. Яңа колхозга Калинин исеме бирелә. Колхоз рәисе итеп Арбаш кешесе Хисмәтуллин Вәзих сайлана. 1953 елдан 1961 елга кадәр (1958—1959 елда Әхмәтов Готыф абый эшләп ала) Таузар кешесе Гыйззәтуллин Хәким абый рәис булып эшләде. Бу елларда колхоз районда иң алдынгылардан булды, рәис үзе КПСС райкомына бюро члены итеп тә сайланды. "Карадуган авылы лекторлар берләшмәсе" дигән брошюрада аның эш тәҗрибәсе яктыртылды. 1961—1963 елларда Калинин исемендәге колхоз рәисе булып Таузар кешесе Зәкиев Зәкәрия эшләде. Менә шул 1963 елдан башлап 2003 елга кадәр Калинин исемендәге колхоз белән (хәзерге исеме "Игенче") читтән китереп куелган кешеләр җитәкчелек итте:

1963—1973 елларда Сөләйманов Камил (Кариле авылыннан)

1973—1980 елларда Хәкимов Филсур (Апаз авылыннан)

1980—1985 елларда Зарипов Марат (Балтач авылыннан)

1985—1987 елларда Әхмәтханов Фәрит (Нөнәгәр авылыннан)

1987—2003 елларда Нургалиев Ришат (Каргалы авылыннан).

Ниһаять, 2003 елның февралендә "Игенче" колхозына рәис итеп үз колхозыбыз, үз авылыбыз кешесе Зыятдинов Булат сайланды, аңа эшендә уңышлар телик.

Колхозларны берләштерү дә (өстән кушып) колхозларның киләчәген уйламыйча эшләнде. Менә шуңа бер мисал. 1950 елгы колхозларны берләштерү вакытында Кенәбаш авылының "Марс" колхозы Түбән Кенә һәм Югары Кенә авылларын берләштергән "Фән" колхозына кушылырга теләмичә, өстән басымга биреш-

мичә, аерым яшәде һәм аның нәтиҗәсе дә яхшы иде. Мәсәлән, "Марс" колхозы 1951 елда бөртекле ашлыкның һәр гектарыннан 7,72 ц уңыш ала, барлык төр йөкләмәләрен тулысынча үти, тиешле чәчү орлыгын сала, ә "Фән" колхозы бер гектардан 5,44 ц гына уңыш ала, йөкләмәләренең бер төрен дә үтәми, орлык салу планы да 51% кына була, колхозчыларның хезмәт көненә 600 г гына ашлык бүлә. Менә шушы ике колхозны өстән басым ясап мәҗбүри берләштерделәр һәм нәтиҗәдә уңышлары белән беркайчан да артык сөендермәгән "Авангард" колхозы барлыкка килде.

Колхозлар башта өстән кушып берләштерелде, ә 80 нче еллар ахырында яңадан колхозларны ваклау башланды. Колхозларны эреләндерү аяныч хәлләр китереп чыгарган кебек, колхозларны ваклау да фаҗигасез узмады. Калинин исемендәге колхоздан (хәзерге исеме "Игенче"), элеккеге "Авангард" колхозы (хәзер Рәхимов исемендәге колхоз) бүленгәндә Таузар авылының иң уңдырышлы 240 га җире Кенә ягына бирелде, моннан тыш Арбаш авылының элеккеге җиреннән дә берничә йөз гектар җир шул ук Рәхимов исемендәге колхозга мәҗбүри алынды. Шулай итеп, бу авыллар күп гасырлар буена файдаланган җирләрен югалттылар. Арбаш, Карадуган һәм Таузар авылларында яшәүчеләр саны Карадуган авыл Советы халкының 60% ын алып торганын, ә Түбән Кенә, Югары Кенә һәм Кенәбаш авылларында яшәүчеләр саны 40% кына булуын искә алсак, һәм бүленү нәтиҗәсендә "Игенче" колхозының җире Рәхимов исемендәге колхоз җиреннән ким булып калуы нәтиҗәсендә, "Игенче" колхозы колхозчыларының нинди кимсетелүгә дучар булуын күз алдына китерергә мөмкин.

Сугыш бер йортны да читләтеп үтмәде

2005 елның язы да җитәр. Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Ватан сугышы беткәнгә дә 2005 елның 9 маенда 60 ел була. Әмма сугыш хатирәләре, дошманга күкрәк киереп каршы торган, иминлек өчен гомерен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмас. Халык үзен-үзе аямады, көрәште. "Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!" — бу чакыру һәркемнең коралына әйләнде. Татарстан халкы сугышчыларга берөзлексез 600 дән артык төр корал, кием-салым, азык-төлек озатып торды.

Җиңү зур корбаннар таләп итте. Татарстанның 560 меңнән артык улы һәм кызы илне сакларга китте, аларның 250 меңнән артыгы кире әйләнеп кайта алмады.

Балтач районыннан 10 меңнән артык кеше сугышка китеп, шуларның 5981 е сугыш кырларында мәңгегә ятып калды, хәбәрсез югалды.

Арбаш авыл Советына караган авыллардан — Арбашта 143 сугышчыдан 90 кеше, Карадуганда 89 сугышчыдан 42 кеше, Таузарда 114 сугышчыдан 45 кеше туган авылларына әйләнеп кайта алмадылар — илебез өчен барган каты сугышларда һәлак булдылар.

Алар киттеләр дә кайтмадылар... Хәбәрсез югалганнар турында уйлавы да авыр... Үлгән хәбәре килгәннәр турында да тулы мәгълүматны табуы кыен. Чөнки аларны барлау, өйрәнү эше дә соңга калды. Җиңүнең 30 еллыгына хәзерләнгәндә генә эзләнү эшләре башланды. Карадуган урта мәктәбе укытучылары Йосыпов Рәҗәп, Зыятдинова Мәдинә бу эшкә җаваплы итеп билгеләнде һәм укучылар белән мәгълүматлар туплау эше башланды. Әмма эш шома гына бармады, сугыштан исән кайтканнар белән сөйләшү һәм материал туплау чагыштырмача җиңел булса да, кайтмый калганнар белән эш катлаулы иде. Җирле үзидарә Советы секретаре Сиражиева Хәдичә апа үзе белгәнчә зур ярдәм итсә дә, район архивы һәм хәрби комиссариатында һичнинди мәгълүмат юк иде. Укучылар белән өйдән өйгә йөреп, өзелгән тормыш, сүнмәс өмет һәм җуелмас хәтер турында белешмәләр җыйдык. Йосыпов Рәҗәп җитәкчелегендә Даутова Зөләйха, Җәләлиева Фәрдия, Рамазанов Фәргать, Шәфигуллина Люция, Шакирҗанова Резеда, Хәкимов Рафис, Ибраһимов Наил, Хәлиуллина Халидә, Гарипов Дамир, Зиннәтуллин Рифатлар катнашында, фотографлар: Ибраһимов Әнәс Гарипович, Хәлиуллин Илнур, Әүхәдиев Рафис, Закиров Фәрит, Сәгъдиев Рафил, Галиев Зөфәрләр хезмәте белән "Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел" дип исемләнгән "Изге китап" эшләнде. Анда билгеле булган белешмә һәм фотолар куелды. Ул китап кулдан, альбом формасында эшләнеп, мәктәпнең Муса Җәлил музеенда сакланды.

Китапның икенчесе Карадуган, Арбаш, Таузар авылларыннан китеп, Бөек Ватан сугышында һәлак булган солдатлар истәлегенә багышланды. Әлеге белешмә материалларны туплауда һәм язуда Карадуган сигезьеллык мәктәбе укытучысы Зыятдинова Мәдинә җитәкчелегендә Абдуллина Тәгъзимә, Әүхәдиев Рафис, Әшрәпов Ринат, Вафин Рәфәгать, Нәбиуллин Әхмәт, Тукачев Маркиз, Усманов Наил, Закиров Фәрит, Рамазанов Тәлгать, Садыйкова Рәүфәния, Хәлиуллин Илнур катнаштылар. Китап 1975 елның 9 Маена әзер булды. Әлеге материалларны тулыландырып, икенче мәртәбә эшләгәндә, укытучы Зыятдинова Мәдинә җитәкчелегендә Карадуган урта мәктәбен 1981—1982 уку елында тәмамлаучылардан Зәкиева Фәридә — күчереп язучы; Кама-

лиева Рәмзия, Садыйкҗанова Бәһрамия — альбом эшләүчеләр; Шәрипова Клара, Гарипов Фәрит — материал туплаучы; Галиева Гөлсәрия, Хөснетдинова Равилә — актив эзтабарлар күп көч куйды. Альбом ("Изге китап") 1982 елның 9 Маенда өч авыл халкына тәкъдир ителде.

Сугышка Таузардан китеп исән кайткан 69 кешенең 34 е турында "Изге китап"та белешмә бар. Калганнары инде сугыштан соңгы төзелеш һәм сугыш җимереклекләрен торгызу елларында төрлесе төрле якта урнашкан булыр дип уйларга кала. Әйткәнемчә, укучыларның эзләнүләре Җиңүнең 30 еллыгы уңаеннан, ягъни шактый соңарып башланды. Белешмәләр тупланган 34 ветеранның 20 се каты яраланып кайта, шулар арасыннан 6 ветеран госпитальдән туры фронтка — ут эченә кереп, икенче мәртәбә тән ярасы ала. Менә алар: Шәрәфетдинов Сәхәбетдин, Хафизов Гариф, Гыйләҗетдинов Шәмсетдин, Гыйззәтуллин Хәбибелхак, Гарипов Гомәр, Әхмәтов Җәләй. Авылга баш исәнлеге белән кайткан ветераннар барысы да "Германияне җиңгән өчен", "Җиңүнең 20 еллыгы", "Җиңүнең 25 еллыгы", "СССР хәрби көчләренең 50 еллыгы" медальләре белән бүләкләнә. Галимҗанов Мансур, Яппаров Ягъфәр "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнәләр. Әхмәтов Җәләй, Исмәгыйлев Мәгъсүм, Әүхәдиев Габделхак III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнәләр. Галимҗанов Шәкүр, Хафизов Гариф, Йосыпов Габделхәй "За боевые заслуги" медале белән бүләкләнәләр. Ситдыйков Зариф, Усманова Мәйсәрә апа "Кенигсбергны алган өчен" медале белән бүләкләнәләр. Мәйсәрә апа 132 номерлы госпитальдә санитарка булып эшли, аның "Отличник санитарной службы" значогы да бар.

Бу мәгълүматлар әлегә билгеле булганнары гына, илнең азатлыгы өчен үзләрен аямыйча утка-суга кергән авылдашларыбызга мактау һәм дан, диябез. Билгеле, командалык итү сугыш кырында аерата катлаулы. Хәлиуллин Рафаэль кече сержант, Гыйззәтуллин Хәким — кече лейтенант, Хәйруллин Мансур гвардия подполковнигы, Галиәхмәтов Сәхәбетдин — сержант, Мостафин Мансур — кече сержант, Галиев Шәймулла — гвардия өлкән лейтенанты; Гыйззәтуллин Габделхак, Исмәгыйлев Гафурҗан, Галимуллин Барый — офицерлар (хәрби дәрәҗәләре билгеле түгел).

Таузар авылыннан Бөек Ватан сугышына 114 кеше китә дип әйткән идек. Исән кайткан 69 авылдашыбыз исемлеге:

1. Галиев Мортаза,1908 елда туган, 1942—1945 елларда сугышта була, 1944 елда яралана, 1945 елның февралендә кайта. Колхозда эшләде, намуслы колхозчы.

2. Гыйззәтуллин Һидият, 1909 елда туган, 1941 елның декабрендә сугышка китә, 1942 елда контузия ала, 1945 елда кайта. Көчле-куәтле колхозчы.

3. Гыйззәтуллин Зиннәт, 1911 елда туган, 1941—1946 елларда сугышта була. 1946 елда кайта. Үтә пөхтә колхозчы, балта остасы.

4. Әхмәтов Җәләй, 1915 елда туган, 1941 елның июленнән сугышка китә, танкист, ике мәртәбә яралана, 1945 елның 29 апрелендә кайта. III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Төрле оешмаларда эшләде.

5. Әүхәдиев Габделхак, 1901 елда туган, Гражданнар сугышы ветераны, 1941 елның 22 июлендә сугышка китә, Сталинград янында яралана, 1941 елның ноябрендә икенче группа инвалид булып кайта. III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Тегермәндә эшләде.

6. Гомәрова Тәскирә, 1924 елда туган, 1943—1945 елларда сугышта була, сугыш бетү хәбәрен Варшавада ишетә. Мактаулы элемтәче.

7. Галимҗанов Шәкүр, 1925 елда туган, 1943 елның 1 июлендә сугышка китеп, 1943 ел ахырында бик нык яраланып кайта. "Сугышчан хезмәтләре өчен" һәм "Батырлык өчен" медальләре белән бүләкләнә. Оста бухгалтер.

8. Галиәхмәтов Муллахмәт, 1924 елда туган, 1942 елның сентябрендә сугышка китә, 1943 февралендә яралана, 1943 елның июль аенда кайта. Сәүдә системасында эшләде.

9. Гыйззәтуллин Хәким, 1916 елда туган, 1941 елда сугышка китә, 1942 елның 19 ноябрендә Сталинград фронтында каты яралана, 1943 елда кайта. Запастагы кече лейтенант, колхоз рәисе һәм башка җитәкче эшләрдә.

10. Гарипов Гомәр, 1905 елда туган, 1941 елның 25 июлендә сугышка китә, ике мәртәбә яралана, тагын алгы сызыкка җибәрелә, 1945 елның декабрендә кайта. Колхозчы, алдынгы бригадир.

11. Гыйззәтуллин Хәбибелхак, 1908 елда туган, 1941 елның 1 августында сугышка китә. Контузияләнеп 1 ел госпитальдә ята, тагын сугышка керә, 1945 елда кайта. "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнә, колхозчы.

12. Гыйләҗетдинов Шәмсетдин, 1906 елда туган, 1941 елның июнендә сугышка китә, 1941 елда яралана, тазарып тагын сугышка керә, 1947 елның сентябрендә кайта, мебель фабрикасында эшләде.

13. Абдуллина Разия, 1919 елда туган, 1943 елның мартында сугышка китә, 1945 елда кайта. Фронтта химинструктор булып

хезмәт итә. 1967 елда "Хезмәт Кызыл Байрагы ордены" белән бүләкләнә. Казанда яши.

14. Галиев Якуб, 1894 елда туган, Гражданнар сугышы ветераны, 1942 елда сугышка китә, хезмәт армиясендә була, 1945 елны кайта, колхозчы.

15. Галимҗанов Мансур, 1924 елда туган, 1942 елда сугышка китә. Гвардия подполковнигы Галимҗанов "Кызыл Йолдыз" ордены һәм сугышчан медальләр белән бүләкләнә. 1953 елда Ленинград югары офицерлар мәктәбен тәмамлый. Казанда хезмәт итә.

16. Зыятдинов Шәймулла 1899 елда туган, Гражданнар сугышы ветераны, 1941 елның 22 октябрендә сугышка китә, 1942 елның сентябрендә II группа инвалид булып кайта. 1949 елны "ТАССРның иң яхшы налог агенты" исеменә лаек була.

17. Зәкиев Исрафил, 1922 елда туган, 1942 елның 25 февралендә сугышка китә, яраланып, 1943 елның 8 апрелендә кайта, колхозда да, кибетче дә, клуб мөдире дә булып эшләде.

18. Исхаков Галимулла, 1896 елда туган, Беренче бөтендөнья сугышы ветераны, Гражданнар сугышында катнаша, 1941 елның 15 ноябрендә сугышка китә, 1945 елда кайта, колхозчы.

19. Зәкиев Мөдәррис, 1926 елда туган, 1943 елда сугышка китә, 1945 елның 8 маенда Германиядә кулы яралана, 1945 елның июлендә кайта. Колхозчы.

20. Мәрданов Габделхәй, 1923 елда туган, 1941 елны сугышка китә, 1945 елда кайта.

21. Хәлиуллин Гайфулла, 1900 елда туган, 1941—1945 елларда сугышта була. Колхозчы.

22. Мәрданов Габдулла, 1895 елда туган, Беренче бөтендөнья сугышы һәм Гражданнар сугышы ветераны, 1941 елны сугышка китә һәм 1945 елны кайта. Оста мич чыгаручы.

23. Сәгыйтов Хәсбиулла, 1895 елда туган, Беренче бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы ветераны, 1941—1945 елларда сугышта катнаша. Колхозчы.

24. Ситдыйков Зариф, 1926 елда туган, 1943 елның декабрендә сугышка китә, 1950 елда кайта. "Кенигсбергны алган өчен" медале белән бүләкләнә, колхозчы.

25. Усманова Мәйсәрә, 1923 елда туган, 1942 елның 22 июнендә сугышка китә, 132 нче госпитальдә санитарка, 2 нче Белоруссия фронтында, Балтыйк буе, Көнчыгыш Пруссия фронтында була, "Кенигсбергны алган өчен" медале белән бүләкләнә, Балтач район социаль тәэминат бүлегендә эшләде.

26. Хәкимов Мәгъсүм, 1910 елда туган, 1941 елның июнендә китә, 1941 елның августында яралана, тазаргач, авылга кайта, колхозчы.

27. Хөсәенов Хәбибрахман, 1895 елда туган, Беренче бөтендөнья сугышында, Гражданнар сугышында катнаша, Бөек Ватан сугушына 1942 елда китеп, 1945 елда кайта, колхозчы.

28. Хәлиуллин Корбангали, 1920 елда туган, 1940 елны армиягә алына, шуннан сугышка керә, 1945 елда Япониягә каршы сугышта катнаша, 1946 елның июнендә кайта, "Сугышчан хезмәтләре өчен" медале белән бүләкләнә, райсоюз системасында эшләде.

29. Хафизов Гариф, 1919 елда туган, 1940 елны Армиягә китә, сугыш башы белән сугышка керә, яралана, тазаргач, тагын фронтка китә һәм 1946 елда кайта, "Сугышчан хезмәтләре өчен" медале белән бүләкләнә, мебель фабрикасында эшләде.

30. Шәрәфетдинов Сәхәбетдин, 1916 елда туган, 1941 елны сугышка китә, 1942 елның сентябрендә яралана, 1943 елны тагын яралана, 1944 елның гыйнварында кайта, "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнә, сәүдә системасында эшләде.

31. Яппаров Якуб, 1901 елны туган, 1942 елның сентябрендә сугышка китә, 1943 елның маенда яралана, 1943 елда кайта, Арбаш авыл Советы рәисе.

32. Яппаров Ягъфәр, 1924 елда туган, 1942 елның 1 августында Армиягә алына, 1943 елның апреленнән 1944 елның августына кадәр фронтта була, 1944 елның августында яраланып кайта, "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнә, 1963 елда "РСФСРның атказанган укытучысы" исеменә лаек була.

33. Йосыпов Габделхәй, 1910 елгы, 1942 елның декабрендә сугышка китә, 1945 елда кайта. "Сугышчан хезмәтләре өчен" медале белән ике мәртәбә бүләкләнә, колхозчы.

34. Исмәгыйлев Мәгъсүм, 1906 елгы, аягы яралангач, 1942 елның августында кайта. III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә, колхозчы.

35. Галимов Әюп Галим улы, 1921 елда туган, "Дружба" артелендә эшләде.

36. Гыйззәтуллин Габделхак Гыйззәтулла улы, 1905 елда туган, офицер, укытучы.

37. Гыйззәтуллин Исхак Гыйззәтулла улы, 1914 елда туган, Казанда.

38. Галимҗанов Әгъләм Хәйрулла улы, 1920 елда туган, Казанда.

39. Зыятдинов Шаһи Зыя улы, 1909 елда туган.

40. Зыятдинов Мөбарәк Зыя улы, 1912 елда туган.

41. Исмәгыйлев Габдерәүф Ибраһим улы, 1923 елда туган, Казанда.

42. Исмәгыйлев Фарук Ибраһим улы, 1925 елда туган, Казанда.

43. Исмәгыйлев Рәхмәтулла Исмәгыйль улы, 1911 елда туган, пекарняда эшләде.

44. Касыймов Якуб Касыйм улы, 1902 елда туган, колхозчы.

45. Насруллин Әсхәдулла, 1918 елда туган, укытучы, Яңгулда.

46. Насруллин Хәсбиулла, 1914 елда туган.

47. Нәбиев Әхмәтгәрәй Нәбиулла улы, 1925 елда туган, "Дружба" артелендә эшләде.

48. Сафиуллин Шәйхетдин, 1916 елда туган.

49. Сәгыйтов Рәҗәп Зәки улы, 1920 елда туган, кооперация системасында эшләде.

50. Сәләхов Барый Сәләхетдин улы, 1919 елда туган.

51. Фәттахов Мөбарәкҗан Фәттах улы, 1911 елда туган, Юдинода яшәде.

52. Фәхретдинов Гомәр Фәхретдин улы, 1914 елда туган, Үзбәкстанда.

53. Хәбибуллин Солтан Мөхәммәтгали улы, 1913 елда туган, Казанда.

54. Хәбибуллина Зөлхибә, 1921 елда туган, укытучы, инвалид артелендә.

55. Хәсәнов Хөсәен, 1899 елгы, Гражданнар сугышы ветераны, Чапаев дивизиясе солдаты, 1942—1945 елларда сугышта катнаша, колхозчы.

56. Хаҗиев Нурмөхәммәт Хаҗи улы, 1919 елда туган, укытучы, Апазда.

57. Шәяхмәтов Каюм, 1902 елда туган, Үзбәкстанда.

58. Шәйхетдинов Хисаметдин, 1914 елда туган, Үзбәкстанда.

59. Шакирҗанов Гыйльметдин.

60. Җәләев Габделхак, 1915 елда туган.

61. Мәрданов Габделхәй Габдулла улы, 1923 елда туган, Казанда.

62. Абдуллин Габделхак Абдулла улы, 1902 елда туган, Үзбәкстанда.

63. Абдуллин Закир Абдулла улы, 1911 елда туган, Үзбәкстанда.

64. Абдуллин Габдрахман Абдулла улы, 1905 елда туган, Арча районында.

65. Җәләлиев Минһаҗ, 1914 елда туган, Балтачта, ашлык кабул итү пунктында.

66. Гарипов Фатыйх, 1906 елда туган, колхозчы.

67. Гарипов Газыйм, 1910 елда туган, Казанда.

68. Фазылов Әгъләм, 1914 елда туган, Шәмәрдән бистәсендә яшәде.

69. Гыйльметдинов Рәфыйк Фатыйх улы, 1922 елда туган, Казанда яшәде.

Искәрмә: *Авылдан читкә китеп яшәүче кайбер авылдашларның адреслары ачыкланмаганлыктан, алар турындагы мәгълүмат тулы түгел.*

Алар кайтмый калдылар:

1. Әхмәтов Сәхәбетдин Галиәхмәт улы, 1920 елгы, өйләнмәгән, сержант, 1944 елны үлгән хәбәре килә.

2. Вәлиуллин Усман, 1895 елгы, 1943 елның 17 февралендә яраланып үлә. К-ц. Тверь өлкәсе, Ржев р-ны, Ножкино авылында күмелә.

3. Вәлиуллин Фәсхетдин Усман улы, 1925 елгы, өйләнмәгән, 1943 елның 7 гыйнварында сугышка китә, 1944 елда Красноводски госпиталендә үлә.

4. Галиев Шаһимулла Хәбибулла улы, 1923 елгы, өйләнмәгән, 1942 елның 23 сентябрендә һәлак була. Чехословакиядә, Комарно өязе, Коляндинда җирләнә.

5. Галиев Шәйдулла Хәбибулла улы, 1925 елгы, өйләнмәгән, 1943 елның 25 ноябрендә һәлак була, Запорожски өлкәсе, Васильевски районы, Благовещенски авылында күмелә.

6. Галиев Зиннәтулла Хәбибулла улы, өйләнгән, ике кызы була.

7. Галимуллин Барый Хәбибулла улы, өйләнмәгән, 1916 елгы, 1944 елның 3 сентябрендә һәлак була. Эстониянең Выру шәһәрендә күмелә.

8. Галимуллин Габделхак Хәбибулла улы, 1914 елгы, 1941 елның 11 ноябрендә һәлак була, Иваново өлкәсе, Золино ярымутравына күмелә.

9. Ганиев Габдрахман Гани улы, 1901 елгы, 1942 елның 4 гыйнварында Мәскәүне саклаганда һәлак була.

10. Ганиев Хаҗи Гани улы, 1897 елгы, 1943 елның 14 гыйнварында һәлак була, Ленинград өлкәсе, Кировски районы, Синявино-1 бистәсендә күмелә.

11. Гыйльметдинов Фәттах Гыйльметдин улы, 1910 елгы, 1942 елның 2 гыйнварында хәбәрсез югала.

12. Шәрәфетдинов Хәбибелхак Җәләй улы, 1922 елны туган, өйләнмәгән, 1943 ел азагында үлгән хәбәре килә.

13. Исхаков Заһидулла Исхак улы, 1899 елгы, к-ц.

14. Исмәгыйлев Идрис Исмәгыйль улы, 1902 елгы.

15. Гарипов Гафур Исмәгыйль улы, 1904 елгы, 18 нче армиянең 9 нчы укчы бригадасы кече лейтенанты, 1942 елның 29 октябрендә Краснодар крае, Лысая Гора авылы янында һәлак була.

16. Ибрагимов Хәбибулла Ибраһим улы, 1903 елгы, к-ц.

17. Низамиев Галәветдин Низами улы, 1904 елгы, 1945 елның маенда мина алганда һәлак була.

18. Низамиев Шиһабетдин Низами улы, өйләнмәгән.

19. Насруллин Мәхмүт Насрулла улы, 1908 елгы, 1943 елның 22 гыйнварында һәлак була, күмелгән җире — Ленинград өлкәсе, Кировски районы, Синявинские Высоты.

20. Нуриев Рәхим Нури улы, 1910 елгы, 1940 елда Фин сугышында һәлак була. Өч кызы һәм хатыны Нәфисә апа калды.

21. Мостафин Мансур Мостафа улы, 1920 елгы, өйләнмәгән, 1942 елның 9 гыйнварында һәлак була, Ленинград өлкәсе, Подпорожески районы, Ивановская авылында күмелә.

22. Мәрданов Габделфәрт Шайнур улы, 1924 елгы, өйләнмәгән, Сталинградта һәлак була.

23. Вәлиуллин Гомәр Вәлиулла улы, 1903 елгы.

24. Сафиуллин Кәлимулла, 1921 елгы, кр-ц, өйләнмәгән.

25. Сабирҗанов Барый Сабирҗан улы, 1914 елгы, 1944 елның 20 августында һәлак була, Тернополь өлкәсе, Микулински районы, П. Березовица авылында күмелә.

26. Сафин Кәлимулла Гыйльмулла улы, 1918 елгы, к-ц.

27. Сафин Ризван Гыйльмулла улы, 1926 елгы, кр-ц, өйләнмәгән.

28. Сәлахов Нәкыйп Сәлах улы, 1921 елгы, кр-ц, өйләнмәгән.

29. Сабирҗанов Мөбарәк Сабирҗан улы, 1911 елгы, 1942 елның 10 сентябрендә һәлак була.

30. Сәгыйтов Гариф Кәлимулла улы, 1909 елгы, кр-ц.

31. Хәсәнов Кәрим Хәсән улы, 1901 елгы, 1942 елның 18 октябрендә һәлак була, кр-ц, 303 укчы полкта сугыша.

32. Хәкимов Сәгыйтҗан Хәкимулла улы, 1915 елгы, кр-ц, кызы Сәгурә.

33. Хәкимов Мәгъсүмҗан Хәкимулла улы, 1908 елгы, улы Искәндәр.

34. Хәкимов Ибраһим Хәким улы, 1916 елгы.

35. Хәкимов Кәләметдин Хәким улы, 1913 елгы.

36. Хәлиуллин Зиннәт Хәлиулла улы, 1908 елгы, кр-ц, кызы Гадения.

37. Хафизов Фатыйх Хафиз улы, 1915 елгы, кр-ц, өйләнмәгән.

38. Фазылов Закир Фазыл улы, 1919 елгы.

39. Шәрәфетдинов Рамазан Фәттах улы, 1924 елгы, өйләнмәгән.

40. Яппаров Мәхмүт Яппар улы, 1903 елгы, кр-ц.

41. Хәлиуллин Рафаэль Хәсбиулла улы, 1926 елгы, өйләнмәгән, кече сержант, 1945 елның 23 апрелендә Германиядә һәлак була, М. Велефанс дигән урында күмелә.

42. Гыйләҗев Сөнгатулла Гыйләҗ улы, 1911 елгы, 1944 елның 16 апрелендә үлә, Псков өлкәсе, Псков районы, Станки авылында күмелә.

43. Габделбәров Габделхәй Габделбәр улы, өйләнмәгән.

44. Шакиров Габдрәүф Фәйзерахман улы, 1926 елгы, кр-ц, өйләнмәгән.

45. Шакирҗанов Кашшаф Шакирҗан улы, 1901 елгы.

Искәрмә: *Сугышка Таузардан китүләре билгеле булып та, бүгенге көнгәчә алар турында анык мәгълүмат булмаганлыктан, ул авылдашларның фамилия һәм исеме генә теркәлде.*

Югарыда саналган авылдашларның егермегә якыны әле туй, гаилә шатлыгын да күрә алмыйча, сугыш кырында ятып калган, алай гына да түгел, егет булып урамнарны иңләп, кызлар күңелен җилкендереп йөрү, сөю һәм сөелүдән мәхрүм булган егетләр.

Ә өйләнеп гаилә корганнарының тол калган хатыннары, ятим балалары гомерләре буена кайтмый калганнарны көтеп яшәделәр. Ә көтүе дә гади генә, сабыр гына, шатлыклар килеп ирешкәнне тели-тели көтү түгел бит әле. Галиев Хәбибулла бабайның сугышка өч улы китә — Зиннәтулла, Шаһимулла һәм Шәйдулла — алар гел алгы сызыкта булалар, өчесе дә әйләнеп кайтмый.

Зиннәтулла сугышка кадәр Казанга китеп урнаша, өйләнә. Автобус шоферы булып эшләгән җиреннән ике кызын, яраткан хатыны Гасимәне калдырып сугышка китә. Дания һәм Дамирә исемле кызлары (1938 һәм 1941 елгылар) — әле сабыйлар. Икмәк заводында эшләүче Гасимә, ачлыктан балаларның хәле начарланганына түзә алмыйча, яшереп кенә ике нарасыена ике кабартма (кечкенә булки) алып кайтып ашатмакчы була — тотыла. Тикшерүче ананың хәлен аңлап, эш зурга китсә, 5 ел төрмә янаганын аңлатып, Гасимәгә шәһәрдән чыгып китәргә киңәш итә. Гасимә ике баласын танышларына калдырып, Ташкентка китә, ә балаларны Хәбибулла абый авылга алып кайтып, исәнсау тәрбияли. Гасимә Ташкентта прокуратурага бүлмәләр җыештыручы булып эшкә урнаша. Хәле җайлану белән паспорт

алып, балаларын Таузардан үзе янына алып китә. Кызлар үсә, укыйлар, югары белем алалар. Берсе авиация институтын тәмамлап, конструктор булып эшли; икенчесе медицина институтын тәмамлый — табибә.

Әлеге "Изге китап"лар бүгенге көндә Карадугандагы "Себер юлы тарихы" музееның Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларыбызга багышланган залында саклана. Бу китаплар һәр елны 9 Майда Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган — кайтмый калган авылдашларыбыз истәлегенә куелган һәйкәл янында Җиңү бәйрәме уңае белән үткәрелә торган митингка чыгарыла. Митинг буласы көнне иртәдән үк авылның яше һәм өлкәннәре шушы һәйкәл янына җыела. Укучылар махсус әзерләнеп, үзләренең укытучылары белән аерым киләләр. Сугыш һәм тыл ветераннарыннан ике кеше укучылар колоннасыннан ике метрга алдарак, шушы "Изге китап"ларны кызыл япма белән бик кадерләп тотып киләләр дә китаплар өчен алдан хәзерләнгән өстәлгә куялар. Бу көнне һәйкәл янында икешәр укучы (дежур, почетлы каравыл) сакта тора. Укучылар икешәрләп торып, һәр 30 минут саен алмашыналар. Митингта сугыш һәм тыл ветераннары, җирле үзидарә әгъзалары, укучылар чыгыш ясый. Ә сакта тору кичке сигезгә кадәр дәвам итә. Чөнки митинг таралгач та әле "Изге китап" лар яныннан кешеләр өзелми, үзләренең танышларын эзлиләр, туганнары турында укыйлар. Шушы ук көнне музейга да экскурсия ясала. Ә инде сугыш һәм тыл ветераннарын колхоз идарәсе аш-су өстәле янына чакыра — чәй эчү оештырыла, бүләк-күчтәнәчләр бирелә.

Туган туфрагына кайтмый калучыларга багышланган "Изге китап"ның беренче битенә

"Беркем дә, берни дә онытылмый", —

дип язылган. Шул ук биттән фикерләрне, уй-сагышларны тирәнәйтеп,

"Эзләмәгез безнең каберләрне —
Ил туфрагы белән кушылган..."

дигән сүзләрне укыйсың. Бу сүзләр үзәкләрне өзеп, кайнар күз яшьләре тамдыра. Ничек кенә сагынмыйсың, ди дә, ничек кенә уйламыйсың-эзләмисең, ди. Ел саен 9 Майда — Җиңү бәйрәмендә авылдашлар аяк өсте торып, бер минут тынлык белән кайтмый калган авылдашларыбызны искә алабыз. Ул бер минут тынлык йөрәкләрне парә-парә китерә. Сугыш елларын ачлыкта, кара кайгыда үткәргән толлар әтисез үскән балаларын юатыр

сүз таба алмыйча, сагышлы гомерләрен йомгаклап баралар инде. Ә балалар "Хәтер" китабын актаралар, әтиләре турында мәгълүмат таба алсалар, шуңа да куаналар. Кайберләре — хәзер инде ап-ак чәчле абый-апалар — хәстәрен күреп, китапта күрсәтелгән адрес буенча юлга чыгалар...

Разведчик истәлекләре

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 60 еллыгы якынлаша, хәзер сугыш ветераннарының сафлары да сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Аларның сугыш фаҗигаләре турында истәлекләре дә үзләре белән китә.

Мин шундый ветераннарның берсе, сугыш инвалиды Исрафил абый Зәкиев турында язарга уйладым. Исрафил абый 1922 елда Таузар авылында туа һәм Карадуган мәктәбен тәмамлаганнан соң, колхозда эшли, сәламәтлеге буенча аны сугышка үз кордашларыннан соңрак алалар. Шуңа күрә әле аңа 1941 елда һәм 1942 елның башында күп кенә авылдашларын Шәмәрдән һәм Арча станцияләренә кадәр сугышка озатырга туры килә.

Исрафил ага Зәкиев.

Сугыш күп корбаннар белән бара, шуңарга башта яраксыз дип калдырылганнарны да сугышка ала башлыйлар. Шулай итеп, Исрафил абый да 1942 елның 25 февралендә китә. Солдатларны фронтка хәзерләүче Суслонгер лагерендагы авыр хәлләр турында язгаладылар. Исрафил абый шундыйларның берсенә — Горький өлкәсенең Гороховецк лагерена эләгә. Анда салкынга, ярымач торуга түзә алмыйча, күпләр үзләре теләп сугышка китә һәм апрель урталарында Исрафил абыйга да чират җитә. Алар Мәскәү аркылы үтеп, Смоленск өлкәсендәге бер урман кырыенда, фронтка якын килеп урнашалар. Ул вакытта әле аларга корал бирмәгән булалар һәм ул берничә көн продукция ташуда эшли. Ипи алып кайтканда ипи башын кисеп ашаган өчен наряд бирүләрен һәм ашны да иписез ашарга туры килгәнен искә ала. Ике көннән соң аларга автоматлар бирелә һәм 12 сентябрь көнне яңа солдатлар немец уты астында Зебр елгасын кичәләр. Аңа

яңадан ут астында продукция ташырга туры килә. Взвод командиры ярдәмчесе татар егете була, ул Исрафил абыйга башка кешеләр барында татарча сөйләшмәскә куша. Берничә көннән Исрафил абыйларны разведкага китеп, кайтмый калган отрядны эзләргә җибәрәләр. Алар разведчикларны табалар, тик отряд дошман уты астында алга да кузгала, артка да чигенә алмаслык хәлдә була. Исрафил абыйлар ярдәме белән разведчиклар үз ягыбызга чыгалар. Сугышчан бурычны үтәп кайтып, үз траншеяларына җиткәч, немец минасы төшеп шартлый. Шул шартлаудан аның уң ягындагы рус егете шунда ук үлә, сул ягындагы күрше Сәрдә авылыннан мари егете каты яралана, соңыннан ул да үлә. Сәрдә егете хакында Исрафил абый бик күңелле егет иде, дип искә ала. "Аз гына куркынычрак вакыйга килеп чыкса, чукына башлый, үзе аннары шунда ук кычкырып "Әлхәм"не укый иде. Ник алай итәсең дип сорагач, кайсысының саклап каласын белгән юк, дип җавап бирә иде", — дип сөйли ветеран. Бу вакытта Исрафил абыйның да җилкәсе яралана һәм аны кыр госпиталенә салалар. Анда бер атна дәваланганнан соң, Мәскәүдәге бер мәктәп бинасына урнашкан госпитальгә китерәләр.

Тазарганнан соң, алар бераз урман кисү эшендә эшлиләр һәм кабат фронтка китәләр. Ул автоматчылар взводына эләгә. Шунда бер инженер-капитан килеп, алардан миналар турында сораша башлый. Исрафил абый миналар турында бераз белә һәм аны минерлыкка өйрәнергә дип, өч айга тылга чыгаралар. Ләкин 25 көннән аларны ашыгыч төстә фронтка җибәрәләр. Монда килгәч, миналарны белүен кабат тикшерәләр һәм ул имтиханнарны бик яхшыга тапшыра.

1943 елның 20 февралендә Совет Армиясе көненә разведка отряды командирына тере немец (тел) алып кайту бурычы куела һәм алар үзләре белән бер сапер алырга тиеш булалар. Командир, миналарны иң яхшы белүче буларак, Исрафил абыйны ала. Ул миноэзләгеч ярдәмендә немец траншеяларына бару юлын ача һәм кагыйдә буларак, аның эше беткән санала. Ләкин командир аңа траншеяларга кадәр барырга куша, үзләре аны сакларга булалар. Шул вакыт боларны сизеп, немецлар көчле ут ачалар һәм алар кире кайтырга мәҗбүр булалар. Тагын ике тапкыр дошман позицияләренә бара алмыйча, кире кайтканнан соң, өченче мәртәбә разведкага баралар. Бу юлы да Исрафил абый юлны миналардан чистарта, командир элеккечә үк траншеяга кадәр барырга куша. Шул вакытта ул бер карамчык күреп, теге нидер сизенгәнче, аның өстенә ташлана һәм муеныннан буып ала, ул арада командир да килеп җитә. Немецның авызына чүпрәк тыгып, кулларын бәйлиләр. Бу безнең якка разведкага чыгып, группа-

сыннан аерылган солдат булып чыга. Алар группаның калган өлешен читләтеп узалар. Кайтып җитәрәк безнең солдатлар немецны кыйный башлыйлар һәм немец үлә. Штабта разведка отряды командирына каты эләгә, шулай да немецны кулга төшергәнен сорашып, шушы батырлыгы өчен Исрафил абыйны "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләүгә тәкъдим итәләр. Ә икенче көнне "тел" алып кайту өчен аларны кабат разведкага җибәрәләр. Бу баруда Исрафил абый каты яралана. Аны сугыш кырыннан бер татар егете һәм Зенин фамилияле командиры алып чыгалар. Итеген ярып алып, аягын бәйлиләр һәм кыр госпиталенә озаталар, аннан Мәскәүгә җибәрәләр. Анда дәваланулар нәтиҗә бирмәгәч, апрель аенда Төмәнгә озаталар. 1943 елның июль аенда ул икенче группа инвалид булып туган авылы Таузарга кайта.

Исрафил абый инвалид булса да, авылда күп кенә файдалы эшләр башкарды: колхозда хисапчы булды, клубта үзе якты, үзе мөдир булып эшләп, авыл халкына игелекле хезмәт күрсәтте. Тормыш иптәше Хәерниса белән тату гомер кичереп, дүрт бала үстерделәр. Карчыгы вафатыннан соң, Исрафил абый улы Гаяз, килене, оныклары тәрбиясендә, тормыштан канәгать булып, балаларына, оныкларына рәхмәт укып, ил-көннәрнең иминлегенә сөенеп байтак яшәде әле. 2004 елның кышында тыныч кына бакыйга күчте. Ходай хозурында шәһит хөрмәте күрсә иде.

Танкист авылдашым

Җәләй Әхмәтов (уңда) сугышчан иптәше, Арча районы Пошалым авылы егете Харис Гарипов белән.

Яңадан язлар килде. Бүген — Җиңү көне. Ә шул җиңүне алып килүчеләр безнең арадан китеп бара. Авылдашым Әхмәтов Җәләй абый Җиңүнең 58 еллыгына килеп җитә алмыйча, бу дөньядан мәңгелеккә күчте.

Җәләй абый сугышка кадәр шактый еллар безнең əти белән "Көрәш" колхозының Таузар авылында бригадир булып эшләде, шул вакыттан ук ул күңелгә якын булып

калган. Җәләй абый армиягә сугыш башланганчы ук, 1940 елда алына. Башта ул хезмәт армиясендә була. Сугыш башлангач та әле фронтка китми, ә Казанны саклау өчен Апас районында оборона корылмалары төзүдә эшли. Ул халык хәтерендә окоп казу булып кереп калган. Безнең авылдан да бу эшкә күп кенә хатын-кызлар, өлкән ир-атлар тартылды, шул исәптән минем әни дә 1941 елда Чувашия АССР җирендә шундый хезмәттә катнаша.

Башта ук фронтка китмәгән хезмәт армиясендәге егетләрне 1942 ел башында, Яшел Үзән шәһәренә җыелма пунктта туплап, төрле частьларга бүләләр. Анда белемлерәк егетләрне танкистлар хәзерли торган курсларга билгеләүләрен ишетеп, танкист буласы килгән Җәләй абый, үзенең белемен урта мәктәп бетергән итеп күрсәтеп, танкистлар хәзерли торган курска эләгә. Билгеле, уку бик авыр була, ләкин теләк зурлыгы һәм тырышлыгы аңа бу биш айлык курсларны уңышлы тәмамларга мөмкинлек бирә. Аларны танклар кабул итәргә Горький шәһәренә җибәрәләр. Анда Америка танкларын кабул итәләр. Биш кешелек экипажда ул башнер (заряжающий) була. Билгеле, Америка танкларының үзенчәлекләрен өстәмә өйрәнергә туры килә. Җәләй абый Пошалым авылы егете Гарипов Харис белән ике мәртәбә дошман снаряды тиеп янган танктан чыгып, исән калалар. Союзниклар биргән танклар Ленинград тирәсендәге сазлыклар аша чыгарга да яраклаштырылмаган була, шуңа күрә әлеге сугышларда аларга күп михнәтләр чигәргә туры килә. Бу фронтта алар Кызыл Байраклы 16 нчы танк бригадасында сугышканнар. Аларны атаклы “Т-34” танкларына утырталар һәм бу бригада өченче Балтыйк буе фронтына күчерелә. Фронтта сугышлар аеруча каты була. Җәләй абыйның командиры авыр яралана һәм аңа командирын ут астында кыр госпиталенә алып чыгарга туры килә. Батырлыгы өчен “Дан ордены” белән бүләкләнә, үзе дә әлеге сугышта контузия ала. 1944 елның декабрендә өченче Балтыйк буе фронтында аеруча батырлык күрсәткән сугышчыларны ун көнгә өйләренә ялга кайтаралар. Җәләй абый, кыска вакытка булса да, туган авылына кунакка кайта. Әнисе, хатыны Рабига апа һәм иң кадерлесе, үзе сугышка киткәч туган беренче баласы Тәнзилә белән очраша.

Ялдан килгәннән соң, иң тәҗрибәле сугышчы коммунистларны яңа гына оештырылган Икенче Польша армиясе составына алалар. Ул Берлинны алу өчен каты сугышларда катнаша. 1945 елның 18 апрелендә, танкларны ягулык һәм корал белән тулыландыру өчен урман эченә туктагач, җиңелү хәленә җиткән немецлар актык көчләрен туплап, аларга каршы көчле сугыш

башлыйлар һәм бу сугышта Җәләй абый каты яралана, аның бер күзенә снаряд кыйпылчыгы эләгә. Аны кыр госпиталенә иптәше Гайнетдинов Фәсәх озата. Польша армиясендәге сугышчан батырлыклары өчен ул Польша дәүләтенең орденына тәкъдим ителә, ләкин орден Җәләй абыйны таба алмый... Кыр госпиталеннән аны Познань шәһәре госпиталенә озаталар. Госпитальдә ятканда күптән көткән иң зур куанычлы хәбәр — Җиңү көне килгәнен ишетә. Тазара төшкәч, шәһәргә чыгып йөри башлагач, ул үзенең Совет Армиясендә бергә хезмәт иткән командирын, капитан Цирлинны очрата, ул Җәләй абыйны Дрезден шәһәре янына урнашкан үз частьларына чакыра. Чыннан да, Җәләй абый аларны эзләп таба һәм бу бик күңелле очрашу була.

Ул туган авылына 1945 елның ноябрендә кайтып төшә. Аның кайтуы да хикмәтле. Сугыштан исән-имин кайтсам, иң беренче әни белән күрешер идем дип, сүз куйган була. Нәкъ шулай эшли дә. Урам буенча үткәндә аның бер кеше белән дә күрешмичә, турыга карап кызу-кызу кайтуына гаҗәпләнәләр. Өендә әнисе Әсма апа, хатыны Рабига апа һәм кызы Тәнзилә белән күрешкәч кенә урамга чыгып кешеләр белән күрешә Җәләй абый.

Җәләй абый сугыштан соң төрле җаваплы эшләрдә эшләде. Арбаш авыл Советы рәисе булып та сайланды. Әлеге авыл Советына Арбаш, Карадуган, Таузар авыллары керә иде. Ул авыл Советы рәисе булган вакытта Таузар зираты беренче мәртәбә койма белән әйләндереп алынды.

Җәләй абый Рабига апа белән өч кыз, дүрт малай тәрбияләп үстерделәр, алар барысы да тәртипле, тормышта үз урыннарын таптылар.

Мин бу язмамны хәзерләгәндә аның кызы Фәния, төп нигездә торучы төпчек улы Илфатның истәлекләреннән, оныгы Эльмираның Җиңүнең 55 еллыгына багышланган "Бабамның Җиңүгә керткән өлеше" темасына язылган сочинениесеннән файдаландым.

Мәрхүм Җәләй абый дөнья, район хәлләре белән бик кызыксынучан, юморга бай, сөйләшеп утыру өчен күңелле кеше иде.

Миңа аның хезмәтләре һәм батырлыклары алдында баш иеп, урыны оҗмахта булсын дип теләргә генә кала.

ЗЫЯТДИНОВА Мәдинә — минем хатыным. 1950 елдан Карадуган мәктәбендә Таузар балаларын да укыта, аларның тормышын, әти-әниләрен дә яхшы белә. 1955 елда бу авылга килен булып төшкәч, авыл халкын, авылның холкын, тормышын, гореф-гадәтләрен якыннан белергә-өйрәнергә мөмкинлек туа. Аның шул чордагы авыл тарихын ихлас күңелдән яктыртучы язмалары укучылар өчен кызыклы булыр дип, бу китапка мин аларны да кертүне кирәк санадым (51—99 битләр).

Автор.

Сугыш өчен тумаган идек тә...

Сугыш бер йортны да читләтеп үтмәде...

Әмма бу ил белән күрелгән афәт тә күршебез Усманныкыларга — Маһикамал апага, ата-ананың таянычы булырга тиешле олы балалары Мәйсәрә апа белән Фәсхетдин абыйга, аларга мөлдерәп карап, ачлыктан тилмерүче үсмер малайлар Гыйльфан белән Гыйльванга, укучым Фәргатькә, дустыбыз Кәүсәриягә үтә дә авыр булып төшә.

Яшьтәшләре хезмәт армиясендә калганда, 1942 елны 1895 елгы әтиләре Усман абыйны сугышка, 17 яшьлек Мәйсәрә апаны БАМ төзелешенә җибәрәләр. Ә БАМда 17 яшьлек кызлар өчен хезмәт авыр — ике куллы пычкы буе җитмәслек юан агачларны кисү һәм юл төзү эшләре. Тору урыннары, эш киемнәре Себер якларына түзмәле түгел. Ярым ач кызларның бер төркеме качып китәргә мәҗбүр була. Авылга кайтып җиткәнче күптөрле кыенлык һәм тоткарлыкларга очрыйлар. Ә кайтуга, таң белән, икенче төрле юллама тоттырып, окоп казырга җибәрәләр. Әниләре Маһикамал апа авыл Советы рәисенә күз яшьләре белән ялынса да, кызын үз янында калдыра алмый. Бу юл, укенечле сагыш булып, Мәйсәрә апаның күңелендә гомер буена саклана.

Казаннан ерак түгел “Клыки” дигән урында (сугышка китүчеләрне хәзерләү лагеренда) әтисе Усман абый белән очраша

ул. Әмма бу соңгы очрашу һәм соңгы саубуллашу була...Усман абый (аңа ул чакта 48 яшь!) 1943 елның 17 февралендә яраланып, Тверь өлкәсенең Ржев районы, Ножкино авылында вафат була, шул авылда җирләнә. Ә Мәйсәрә апаны әтисеннән соңгы хәбәр килгәнче үк — 1942 елның 20 июнендә сугышка алалар. Ул "фронт юллары әти белән кабат очраштырыр әле" дигән сабыйларча якты өмет белән үзен юатып йөри. Әнисенә булышчы булып үсеп җиткән 1925 елгы энесе Фәсхетдиннең 1943 елның 7 гыйнварында сугышка китүен белми әле Мәйсәрә апа. Фәсхетдин абый әтисенә һәм апасына изге юллар, сәламәтлек тели-тели офицерлык хезмәтен намус белән үти.

Мәйсәрә апа авылдан бернинди хәзерлексез килеш китеп, фронт сызыгындагы кыр госпиталендә санитарка булып эшли. Яралылырны ут эченнән — снаряд яңгыры астыннан күтәреп ташу, операция вакытында еш кына кан биреп сугышчыларны коткарып калу, юкны бар итеп ашау ризыгы табу, әзерләп ашату, исәннәрне тагы да сәламәтләндерү өчен тылга озату кебек, санап бетергесез эшләр үтә кыр госпиталендә эшләүчеләр кулыннан. Өстәвенә, фронт сызыгы күчкән саен госпиталь бөтен тормышы белән күченергә тиеш. Сугыш бит ул "Аҗаган" уены гына түгел, һәрчак көтелмәгән хәлләр чыга тора, үлгәннәрне күмәргә, исәннәр белән алга таба барырга кирәк була.

Мәйсәрә апа 1945 елның сентябрендә туган авылына "Батырлык өчен" ("За отвагу"), "Кенигсбергны алган өчен" медальләре белән исән-имин кайтып җитә. Балтач район хәрби комиссариаты аны район үзәгендәге социаль-тәэминат системасына эшкә урнаштыра. Мәйсәрә апа үзе кебек сугыш ветераны (сугыш инвалиды) Гыйният абый белән гаилә корып, Балтачта яшәде, өч ир-егет, ике кыз тәрбияләп үстерделәр, хәзерге көндә оныклар белән (алары да 9 булган) күңелле генә гомер итәләр.

Ә менә энесе, офицер Фәсхетдин абыйның, сугышта булган еллары үкенечле дә, кызганыч та... Яраланып, Америка солдатлары ягында кала ул. Яралары бераз төзәлгәч, хәрби суд карары аны җиде елга туган ягына кайтудан мәхрүм итә, Фәсхетдин абый Красноводскида яши башлый. Әмма йөрәк әрнүләре сугыш яраларын яңарта... Фәсхетдин абый Красноводскида үлә һәм шунда җирләнә.

Авыр, бик авыр була Мәһикамал апага. Әтисез калган ятимнәренә тагын да авыр. Үз көннәрен үзләре күрергә өйрәнеп, авырлыкларны җиңә-җиңә яшәде сугыш ятимнәре. Балаларның өлкәнрәкләре: Гыйльфан, Гыйльван, Кәүсәрия колхозда төрле эшләрдә эшләп, кеше арасына керә бардылар. Армия

хезмәтеннән соң Гыйльфан трактор белән урман кисү һәм ташуда, ә Гыйльван "Дружба" артелендә балта эшендә булдылар. Гыйльфан (Рәйсә белән) гаилә корып, биш егет үстерделәр, хәзер оныклар өчен кадерле әби-бабай булып, Арчада матур гына яшиләр. Гыйльван агачтан чәчәкләр ясарлык оста булып, балта эшендә эшләде. Таузарда гына түгел, әйләнә-тирә авылларда йорт салу, аны эчке һәм тышкы яктан бизәү эшен үзләштереп, һәркем өчен кирәкле һөнәр иясе булып яшәде. Аның турында авылдашлары,"бик күп матур йортлар салып, үзенә һәйкәл калдырды" дип сөйлиләр. Инде ул оста да вафат, авыр туфрагы җиңел булсын.

Гыйльван белән Таузар кызы Оркыя ике егет, бер кыз үстерделәр. Оркыя да биеме Маһикамал апа кебек ачык чырайлы, эшчән, матур килен булып төп нигездә яшәде. Кызлары Роза Карадуган урта мәктәбендә укыта. Гыйльван уллары Данил белән Наилгә үз һөнәренә иң кирәк сыйфатларны иңдерә килде. Билгеле, һәр әти-әни шикелле, алар да балалары өчен саклык запас та әзерләгәннәр иде, ләкин... "Их, шул ләкин булмаса..." ди иде мине укыткан тарих укытучысы. Ләкин дөньялар болганды куйды, хәтта әбиләрнең үлемтеккә саклаган акчалары да бер кисәк исле сабынлык кына булып калды. Күршебез Гыйльванның да билен бөгеп, җан көче белән тапкан, үсмер балалары өчен саклаганы җилгә очты. Әйе, бер аныкы гына түгел, күпләр инде саклык кассаларына ышанычларын югалттылар. Элегрәк, акча реформасы булса да, саклык кассасындагы җыем саклана иде, ә монысы бөтенләй бетерде — гади халыкны тагын фәкыйрьлек басты.

Кыз бала буларак, Кәүсәрия районыбызның Көек авылы килене булып китте. Укучым Фәргать риясыз көләч йөзе белән күңелемә якын булып калды. Аның да тормыш сукмаклары бормалы булды, әмма ул аны уңай эзгә сала алды. Фәргатьнең ихтыяр көче Усманныкыларча ачык һәм нык. Билгеле, мин читтән күзәтүче буларак, аның җәмәгате Оркыяга да (икенче килен дә Оркыя) рәхмәтлемен. Гаилә тормышын уңай кора алган кешеләр мине дөрес аңлар дип уйлыйм. Гаиләнең матур яшәвендә ир дә, хатын да җаваплы! Фәргатьнең авыл урамнарын, сабантуй мәйданнарын, авыл һәм район сәхнәләрен шаулаткан тальян моңнарын да кәгазь битләренә төшереп булсачы?!

Уйна, Фәргать! Барлык күргәннәрең, толлык әчесен татыган әниең, туган авылына кайта алмыйча сугыш кырында калган әтиең һәм абыең, янында яшәүче туганнарың, сине үстергән Таузар иле өчен уйна! Шушы авылда синдәй гармунчы егетләр үссен иде диеп шаулат урамнарны!

Рәхмәт сиңа, йөрәк!

112 кеше була алар, Таузар авылыннан Ватан сугышына чыгып китүчеләр. Җан саулыгы белән 65 е әйләнеп кайта. Ә бүгенге көндә исәннәре — нибары алты. Алтау гына калдылар. Ямансу, моңсу... Түбәндәге сүзем шул алтының берсе — Тәзкирә апа Гомәрова турында булыр.

"Мәгариф" колхозы рәисе Зыятдинов Гомәр улы Вагыйз, кызлары Хафизә һәм Тәзкирә белән. Гомәр абый "халык дошманы" дип кулга алынып, шул китүдән кайтмады.

1934 ел.

Бөек Ватан сугышы ветераны Тәзкирә апа балалар белән очрашуларга чакырган саен килә иде. Ул үзе дә шушы мин эшли башлаган Карадуган мәктәбенең укучысы булган. 1938 елны җиденче классны тәмам иткәч, класс җитәкчеләре Салих абый Никитин аны Арча педучилищесына алып барып урнаштырырга тели. Әдәбият белән мавыгучы, нечкә хисле бу кыз баладан менә дигән тәрбияче чыгар дип уйлый мөгаллим. Әмма... Өлгереше бик әйбәт булса да, Тәзкирәне укырга алмыйлар, чөнки аның әтисе "Мәгариф" колхозы рәисе булып эшләгән җиреннән "билгесез сәбәпләр белән" кулга алынып, "халык дошманы" дип игълан ителгән кеше була. Әниләре Һәдия апа "Көрәш" колхозының алдынгы сыер савучысы булып эшләп, колхозчы-ударникларның республика киңәшмәләрендә катнашса да, Мәскәүгә — Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә кунак итеп чакырылса да, аннан бүләкләр белән кайтса да, дүрт ятимен кочаклап, "халык дошманы" хатыны булып яши.

Тәзкирә апа ул елларны әле дә күз яшьләренә манып сөйли. Шул 1938 елны әтисенең сеңлесе Нурлыхода апа ярдәме белән

"Кызыл мехчы" артеленә өйрәнчек булып эшкә урнаша ул, кичке мәктәптә укый башлый. Әмма фин сугышы башлану белән уку туктатыла. Бөек Ватан сугышы башлангач, тормыш тагын да катлаулана. 17 яше тулган көннәрдә, 1941 елның көзендә Тәзкирә апаны окоп казу, урман кисү бригадасында еракларга йөртә башлыйлар. Ул үзенең Урмар станциясе, Чувашия авылларында күргәннәрен сөйли башласа, күп серияле кызганыч фильм караган күк буласың. Хәер, ул "фильмда" күңелле күренеш тә бар: Шигали авылы янында окоп казыган чакта, сугышка киткән авылдашы Җәләй абыйны очратып, шатланып күрешүләре ул...

1943 елның көзендә унтугыз яшьлек Тәзкирә апаның үзен дә сугышка алалар. Кечкенә генә Таузардан дүрт кыз китә алар: Тәзкирә апа, Усманова Мәйсәрә апа, Хәбибуллина Зөлхибә апа, Абдуллина Разия апа. Шәмәрдән аша Казанга килеп төшәләр. 16 нчы завод ишегалдында землянка казытып, кызларны башта шунда торалар. Урнашып кына беттек дигәндә, 40 нчы завод ишегалдына күчерәләр. Тагын землянка казыйлар.

Фронт Мәскәү янына якынлашкач, Горький шәһәре дә бомбага тотыла башлагач, Идел буен саклар өчен кече калибрлы зенит артиллериясе полкы төзергә кирәк була. Менә шушы полкның беренче солдатлары була инде бу кызлар. Аларны көндез телефон, телеграф, радиолокация белгечлекләренә укыталар, ату кораллары белән эш итәргә өйрәтәләр. Төнлә кызлар Идел буенда саллардан агач бушаталар. Ашаган ашларын да хәтерли Тәзкирә апа — бер телем ипи сохарие (тәме әле дә телдә, ди) һәм өшегән кәбестәдән пешерелгән бәрәңге шулпасы... Анысы өч мәртәбә.

Ниһаять, 1944 елның гыйнварында кызларны фронтка озаталар. Полк килә-килешкә Коростень тирәсендә ут эченә эләгә һәм... таратыла. Исәннәрне Сарно шәһәренә җибәреп, Стырь елгасы буенда землянкалар казытып урнаштыралар. Шунда алар янына Казаннан концерт бригадасы килә. Казан ягы кызлары өчен бу зур бәйрәм була! Тәзкирә апа аны хәзер олы хөрмәт белән исә итеп тә искә ала. Зита Измайлова дигән кыз "Кошлар кебек" җырын башкарганда ул үзе дә, аңа кушылып башкалар да сулкылдап яшь түккәннәр. Җыр Тәзкирә апаның күңеленә шулкадәр кереп утыра, ул аны әле дә тыныч кына тыңлый алмый. Җырчы кызны кабат очрату хыялы белән яши ул, төрле концерт бригадаларына хатлар язып эзләтеп тә карый. Җылы хәбәр ала алмыйча, шул көйне үзе җырлап ямансулап йөри торгач, язмыш аларны очраштыра. Бу 1993 ел була инде. Ә теге, онытылмас концертта матур биюләре белән катнашкан Хәдичә белән алар 1981 елны ук, Сарнога ветераннар очрашуына баргач күрешәләр. Сарнодагы музейга Татарстан кызы Хәдичәнең бию киемнәре куела.

“Безнең аяк җиңел булды, — дип сөйли Тәзкирә апа. — ”Казанские лаптики”лар килгәч (безне шулай атыйлар иде), фронт сызыгы гел алга барды. Польша җирен үтеп беткәндә сугыш бетү хәбәрен алдык”. Элемтәчеләрнең хезмәт “бәхете” шундый: алар яңалыкны беренче булып ишетәләр. Сугыш башлану хәбәре иң элек элемтәчеләр йөрәген телгәләсә, сугышның җиңү белән тәмамлануын да алар белде.

И йөрәк! Ничек парә-парә килеп бетмәдең дә, ничекләр түздең икән син ул күргәннәргә?! Сугыш беткәч, инде илгә кайткач, Тәзкирә апа аңа багышлап шигырь дә чыгарган.

Шатлыклар да булды, хәсрәтләр дә,
Тик соңгысы булды күбрәк.
Рәхмәт инде сиңа, рәхмәт инде,
Сыкранмыйча түздең син, йөрәк!
Мактаулар да булды, хурлаулар да,
Нахаклары булды күбрәк.
Рәхмәт инде сиңа, рәхмәт инде,
Кимсенсәң дә, түздең син, йөрәк...

Ветеран итеп чакырылган бер очрашуда укыды ул бу тезмәләрне. Салмак кына яңгыраган юлларда Тәзкирә апаның үз тормыш фәлсәфәсе. Соңгы еллардагы эзләнүләре буенча алар әтиләре Гомәрнең 1936 елда, Свияжск төрмәсендә үлеп калуын ачыкладылар. Хаксызга гаепләнгәннәр акланды. Тәзкирә апа бүген дөнья матур, дөнья киң дип, булган кадәресенә канәгать булып, заман хәлләре белән кызыксынып яши. Аның белән теләсә нинди темага сөйләшеп-серләшеп була. Үзе шикелле фронтовикка — Ватан сугышының буеннан-буена катнашып, 1948 елда гына илгә кайтып җиткән Кенә егетенә кияүгә чыгып, матур тормыш корды ул. Алар Шәрифулла абый белән өрлектәй өч егет үстерделәр. Өчесе дә мәҗбүри хәрби хезмәттә яхшы хезмәт итеп кайттылар. Өчесе дә югары белемле. Гаиләдә акыллы, сабыр килен, киң күңелле пөхтә әни, ирен яратучы бик түземле хатын булып яшәде Тәзкирә апа. Хәзер — оныкларының Дәү әнисе! Аның өчен бүгенге көндә иң авыры — ире Шәрифулла абыйның вафаты. Кырык җиде ел буе пар күгәрчендәй яшәгән бу пар Җиңүнең 55 еллыгын бергәләп каршылау турында уйлаштыргандыр. Әмма язмыш алдында без бәндәләр көчсез шул.

“Казанские лаптики” кызлары элгәрерәк елларда сугышып узган юлларында очрашып торгалыйлар иде. Ил сугыш яраларыннан арынгач, ветераннарга күрешү мөмкинлеге бүләк ителгән иде бит. Тәзкирә апа беренче очрашуга 1975 елда,

Җиңүнең 30 еллыгын бәйрәм иткәндә барды, Коростень һәм Ровно шәһәрләрендә булып кайтты. Сугышчан кызлар шуннан соң тагын алты мәртәбә күрешеп шатланыштылар.

Очрашулар...Үлем тырнагыннан исән калган фронтташ дуслар очрашуы кебек кайнар хисле очрашу була да алмыйдыр. Тәзкирә апа аларның һәркайсына әзерләнеп, дулкынланып бара, кайтканда тагын да яшәреп, яшәү көче алып кайта иде. Сугыш гарасаты эчендә исән калуның, яшәүнең никадәр кадерле икәнен чынлап уйларга мөмкинлек тә булмаган, өстәвенә, унтугыз-егерме яшьлек ваемсыз кыз балалар булган бит әле үзләре дә. Ул елларның истәлекләрен барлаганда, очрашуларда күргән кадер-хөрмәтне искә төшереп, Тәзкирә апа ил өчен көрәштә булуы белән горурлана. Казан кызлары, татар кызларының һәрнәрсәгә сәләтле булуларын күрсәтә-аңлата алуларына чын күңелдән куана. Бу ханым балалар үстергәндә дә әдәбият укырга, мәдәният белән кызыксынырга вакыт табып, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Ш. Хөсәенов кебек күренекле язучылар белән хатлар аша хәбәрләшеп, фикерләшеп яшәгән кеше. Сарно шәһәрендәге музейга сугышчан кызларның шәхси әйберләре куела дигән идем бит, ә Тәзкирә апа әйберләргә өстәп, Татарстан турындагы альбом да тапшыра.

Сарнодагы очрашуларның берсендә кунакларга хөрмәт күрсәтүче бер әфәнде аның татар хатыны икәнен белгәч: "Сез шуларның ничәнчесе?" — дип сорый. Тәзкирә апа: "Я одна, единственная", — дип җавап биреп, Казан татарларының бер генә хатын белән торуын аңлата һәм әңгәмәдәшеннән: "Князь Владимирның 750 хатыны булган дип укыганыгыз юк идеме үзегезнең?"— дип сорап куя. Әңгәмәдәш әфәнде кич буе үзалдына "750" не кабатлап йөри. Апабызга да уй сала бу сөйләшү. Сарнога кабат баруында ул музейга "Идел буе болгарлары тарихы" китабының русчасын тапшырып кайта. Сугышчан дусларына Г. Тукай, М. Мәһдиев китапларын, "Сабантуй" альбомы бүләк итә. Тәзкирә апа Гомәрова, шулай итеп, йөргән җирендә халкыбызның илчесе булып йөри.

Шагыйрь Равил Фәйзуллин:

Яшәсен картларның олыгайган саен
Һаман яшәрә алганнары, —

дип, юкка гына сокланмый. Безнең Тәзкирә апабыз да шул токымнан. Ул әле тыныч картлык турында түгел, сугышчан дуслары белән очрашулар турында хыяллана.

Гыйбрәтле “очрашулар”

Гыйләҗетдинов Сөнгатулла Гыйләҗетдин улы 1911 елны Таузарда туган Каратай кызы Шаһиева Маһиәнвәр апайга өйләнеп, ике кыз, өч ул үстереп, “Көрәш” колхозында эшләп яшәгәндә, Бөек Ватан сугышы башлана. Сөнгатулла абый 1941 елның 21 ноябрендә биш баласын, хатынын, әнисен һәм әле кияүгә чыкмаган сеңлесен калдырып сугышка китә. 1944 елның 14 апрелендә һәлак була. Псков өлкәсе, Псков районы Станки авылында җирләнә. Ятим калган балаларның иң олысына ул чакта 13 яшь була. Әмма ул кыз — Рауза — кечкенә вакытта каты авырудан колаклары ишетми башлап, иң аянычы, чукраклыкның нәтиҗәсе буларак, телсез дә кала. Аны әтисе Сөнгатулла абый сугышка кадәр үк Казан шәһәренең чукрак-телсезләр мәктәбенә укырга урнаштырган була. Ә сугыш беркемне дә аямый шул, бу бичара сабыйлар мәктәбе дә вакытлыча туктарга мәҗбүр була. Тормыш авырлыгы аларны Магнитогорск каласына — кулак тамгасы сугылып Каратай авылыннан сөрелгән Әхмәтгали бабай янына — Әнвәр апаның әтисе янына илтә.

Гомер үтә тора, исәннәр яши — үз көннәрен үзләре күрә. Балалары үсеп эшкә урнаша, гаилә кора, Сөнгатулла абыйның оныклары үсеп җитә. Игелекле-савaплы эшләр башкара ала торган киң күңелле, нык характерлы кешеләрнең хезмәте әтисез ятимнәрнең күңеленә җылылык өсти. Беркем дә, берни дә онытылмавы ятимнәргә көч бирә. Ул көч — “Хәтер” китабының барлыкка килүе! “Хәтер” китабы Президент М. Ш. Шәймиев Указы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә 1994 елны нәшер ителә башлый. Илне саклауда Татарстанның 560 меңнән артык улы һәм кызы катнашты. Аларның 250 меңнән артыгы кире әйләнеп кайта алмады, сугыш кырларында ятып калды. “Хәтер” китабының кереш битендә түбәндәге сүзләр язылган:

“Бу китапта Бөек Ватан сугышы фронтларында һәлак булган, яралардан үлгән, хәбәрсез югалган — сугыш бетүгә ярты гасырга якын вакыт үткәнгә күрә, без хаклы рәвештә, хыянәтче булмаган барлык хәбәрсез югалган сугышчыларны һәлак булганнар дип саный алабыз — солдат һәм офицерларның тулы исемлеге беренче мәртәбә бәян ителә”.

Карадуган Себер тракты музее хезмәткәрләре, Карадуган җирле үзидарәсе ярдәме белән, кайтмый калган сугышчы-авылдашларыбызның якыннарына "Хәтер" китабын бирүне оештырдылар.

Әтиләре турында белешмә булган "Хәтер" китабы Магнитогорскида яшәүче балаларга, әниләре Әнвәр апага килеп җитү сагышлы үткән гомерләрне искә төшереп, сабыр холыклы әтиләрен сагыну, юксыну хисен кабат яңарта. Олы бала буларак, үз күңелендә әтиле бала чагы хатирәләрен саклаучы Раузага әтисе турындагы шушы ике юлга сыйган белешмә бик кадерле була. Ул аны берничә кәгазьгә күчереп яза да юлга җыена. Рауза рус алфавиты белән укый-яза белә, башкалар белән язып аңлаша ала. Менә шул уч төбе кадәр белешмә кәгазьләре белән Псков өлкәсе, Псков районы, Станки авылына барып, әтисе каберен зиярәт кыла. Рауза ханымның андагы халәтен, күңелениләр кичергәнен беркем дә белми, билгеле. Язып аңлатырга да сүз байлыгы чикле, сагышлы шатлыгын күзләреннән генә аңлап була. Ул шушы сәяхәтен Таузарда яшәүче әтисе ягыннан өченче буын туганнарына да язып уртаклашты. Рауза Казанда укыгында, сәламәтлеге үзе кебек бер егет белән танышып, аңа кияүгә чыккан, алар ике кыз үстергәннәр. Кызлар икесе дә чибәр, саусәламәт. Һәр икесе гаилә корып, әти-әниләрен оныклар белән сөендерәләр.

"Әти", дип бер әйтү өчен...

Шәкүр абыйның бертуган апасы Рәхимова Хәдичә апага 1944 елның маенда бик пөхтә итеп язылган конверт килә... Анда 86630 нчы хәрби часть командиры гвардия майоры Егоров Хәдичә апаның ире Рәхимҗанов Йосыфның 1944 елның 10 апрелендә геройларча һәлак булуын, Одесса шәһәреннән ун километр гына ераклыкта, Татарка авылында җирләнүен хәбәр иткән. Әле өч яше дә тулмаган, ә әтисе киткәндә биш-алты көнлек кенә булып калган улы Илдус та нидер аңлаган кебек, нәни куллары белән әнисенең күз яшьләрен сөртә-сөртә: "Әни, елама, мин зур үсәм", — диеп юатырга тырыша. Бердәнбер юанычы һәм өмете булган сабыен кочып, сабырлыгын җыеп Хәдичә апа бөтен көчен эшкә бирә.

Илдус Рәхимҗанов әнисе Хәдичә апа белән Прилиманское авылында.

1914 елда туган Таузар кызы Хәдичә апа Арбаш авылында ясле-бакчада эшли. Гомеренең соңгы көненә кадәр "ясле Хәдичә" булып кала ул. Улы Илдус белән килене Зөбәрҗәт (сугыш еллары ятимнәре) — минем укучыларым — күркәм холыклы, үтә тырыш балалар булып хәтеремдә калган. Алар әниләре Хәдичә апаны кадерләп, бергә яшәделәр, хөрмәтләп соңгы юлга да озаттылар. Илдус 1985 елны 71 яшьлек әнисе Хәдичә апаны Одесса шәһәренә, әтисе каберенә алып бара. Татарка авылында җирләнгән офицер Йосыфның гәүдәсен Одессадан ун километр ераклыктагы Прилиманское авылына күчереп, туганнар каберлегенә күмгәннәр икән. Эзләп табуда шушы авылда яшәүчеләр ярдәм итә. Әтисен эзләп килгән Илдусны һәм Хәдичә апаны әлеге авыл халкы зур хөрмәт белән очрашуларга чакырып кунак итә. Хәдичә апа Прилиманское авылы халкына, ятимлектә үскән улы Илдусның бу изге эшенә олы рәхмәтле булып кайткан иде.

"Исәнме, бабай..."

...1897 елны Таузар авылында туган Ганиев Хаҗи җиде баласын — Факия, Фәүзия, Оркыя, Сәйдә, Мөдәррис, Рәис, Рөстәмне, хатыны Әсманы калдырып, 1942 елның 1 февралендә сугышка китә. Ленинград оборонасында яралана, сәламәтләнгәч, тагын шундагы ук — Ленинград блокадасын өзү өчен барган сугышларда катнаша. Бу сугыш 1125 тәүлек буе бара, анда 2 млн. 700 мең кеше һәлак була. Ганиев Хаҗи — шуларның берсе. Гомере 1943 елның 14 гыйнварында, Ленинград өлкәсе, Кировски районы, Мга бистәсе янында өзелә. Җәсәде 50 нче ел-

лар азагы, 60 нчы еллар башында шул ук райондагы Синявино-1 бистәсендәге туганнар каберлегенә күчереп күмелә...

Ленинград сугышларыннан соң, алтмыш еллап узгач, Хаҗи солдатның икенче баласы Фәүзиянең кызы журналист Фирая Бәдретдинова 2000 елның салкын көзендә, октябрьнең соңгы якшәмбесендә бабасы каберен эзләп туганнар каберлегенә килә...

Ганиев Хаҗи күмелгән туганнар каберлеге.

"Исәнме, бабай..."

Шул көнне генә төшкән беренче карны сыпыра-сыпыра бабасы исеме язылган плитәне эзли Фирая.

"Исәнме, бабай... Кулларым туңды. Әнигә охшап, суыкка чыдамсыз мин. Әни синең үлем хәбәреңне ишеткән көнен тәне дә өшегән, җаны да өшегән көн итеп хәтерли. Педучилищедан кайтышлый язгы суны көч-хәл белән, боздан-бозга сикерә-сикерә кичкәннәр алар ул көнне. Әби өйдәгеләрне: "Апагызга сиздермәгез, үзем җайлап әйтермен", — дип кисәткән булган. Арада балдызыңның кызы, дүрт яшьлек Разия бар икән. Тыела алмаган сабый: "Синең әтиең дә үлгән әле",— дип куйган. Идәнгә ятып, "никләргә генә суларга акмадым икән?" — дип тәгәрәп елауларын, әбинең: "И бала-бала, шул бер бәрәңгесен дә ашарга ирек бирмәдең бит", — дип, Разия апаны битәрләп маташуын әни безгә сөйләсә бер сөйләгәндер, ә ул күренеш күңелгә шулкадәр сеңеп калган, мин моны үзем күргәндәй беләм, бабай...

Ә теге иптәшең, Башкортостан кешесе, сүзендә торган. Әбигә, балаларның һәркайсына исемләп сәламнәр әйтеп, ничек һәлак булуыңны язып җибәргән. Ул кешене балаларың онытмыйлар, Заһретдинов Риза исемле иде ул дип, әлегечә хәтерләрендә тоталар.

Кечкенә вакытта без әнидән: "Әтиең нинди иде синең?" — дип сорый идек. Әни: "Бабай нинди иде, дип сорагыз", — дип үпкәли иде. Күргәнебез булмагач соң... Бердәнбер карточкаңны

да үзебез ерткanбыз. "Саклап бетерә алмадым", — дип, әни гел әрнеде шуңа. Әни сине "зур кеше иде, зәңгәр күзле, мыеклы иде" дип искә ала иде. Мөдәррис абый сиңа охшагандыр, мөгаен. Мыегы гына юк.

Кызыларміяче кенәгәсенә, "туганнары" дигән графага Факия апаны яздырган булгансың. "Олы кызым, нык кызым" дигәнсеңдерме? Алай-болай булсам, әби каушап төшәр дип уйладыңмы? "Бабайның каберен күреп кайттым", — дип сөендерергә өлгермәдем шул Факия апаны. Ике айга соңардым...

Балаларың олыгая инде, бабай. Тик ашыктырма син аларны, яме. Берүк ашыктырма..."

Архив белешмәләре буенча нәкъ шушы урында булырга тиеш булса да, язулы плитәдә эзләгән язу табылмый. "Каберлек өстендәге эреле-ваклы истәлек ташлары, истәлек калайлары, истәлек такталары күңелләре безнеке кебек тырналганнар тарафыннан китереп куелганнар, мөгаен", дип яза Фирая "Сөембикә" журналында. — "Икенче килүегездә плитәләрдә сезнең бабайларның фамилиясе булыр, — диде полковник Красницкий".

Җәсәдләре шушы каберлектә булган һәммә кешенең исемен ташта мәңгеләштерергә, әлеге дә баягы, матди кыенлыклар мөмкинлек бирми. И дөнья... Гомерләре хакына, аннан да мөһимрәге, балаларының ятимлеге хакына һәммәсенең, һәммәсенең бердәнбер исеме ташка уелуга гына лаектыр бит инде аерым кабердән дә, аерым таштан да мәхрүм бу җаннар. Һәм ниндидер могҗиза булып, ул җаннар телгә килә алса, исәннәрдән иң элек газиз балалары өчен хисап алыр иде кебек алар.

Әйе, сугыш афәтеннән исән кайтканнар хаккый хөрмәткә һәм кадергә ия булдылар. Бу хөрмәт һәм кадернең әҗере аларның балаларына да тиде, әлбәттә. Күпсенүдән түгел. Сугышта улларын-кызларын югалткан аналар, сугыш аркасында тол калган хатыннар да, соңлабрак булса да, күпмедер кадер күрделәр. Ленинград блокадасын кичергәннәргә, фашист концлагерьларыннан исән чыкканнарга, шулай ук соңлабрак, төрле ташламалар каралды. Ә менә сугыш ятимнәренә беркайчан да ни аерым кадер, ни ташлама булмады. ФЗӨ мәктәпләренә дә әтисез ятимнәр җибәрелде, "бу гаделсезлекләр монда гынадыр" дип, читкә дә күбрәк сугыш ятим-ятимәләре чыгып китте...

Хаҗи Ганиевнең үзе китүгә вафат булган төпчек улы Рөстәмнән калган балалары ятимлекнең, сугыш чоры михнәтләренең бар ачысын татып үстеләр. Үз тырышлыклары белән ке-

ше булдылыр. Илгә-көнгә игелек күрсәтеп, намуслы гомер кичерделәр, ата-баба рухына тугрылыклы балалар үстерделәр.

2000 елның көзендә шул балалардан берсе бабасының җәсәден япкан җиргә килеп тезләнде.

Туганнар каберлегендә бер минут тын калу адәм баласының бу фани дөньяда ни өчен яшәвенә, нинди гамәл кылуына хисап тотуыдыр, яшәвенең үкенечле мизгелләрен булдырмас өчен нәселе алдында антыдыр.

Мәктәбем минем — белем чыганагым

1921 елны тутырылган анкета (отчет) формасында Таузар башлангыч белем бирү мәктәбенең (мәдрәсә) нигезләнү (основание) вакыты итеп 1895 ел күрсәтелгән. Бу фикер мәчет янында махсус мәдрәсә бинасы салу белән бәйле булырга мөмкин. Совет мәктәбендә укыта башлау вакыты итеп 1918 ел язылган. Анкетада күренгәнчә, гомуми мәйданы 64 квадрат метрлы ике класс бүлмәсендә 100 бала укыган. Шуның 79 ы беренче класста, 21 е икенче класста укыганнар. Укытучылары булып Таузар егете Исмәгыйлев Идрис һәм яшь мулла Мөхәммәтгариф улы Әхмәтов Мөхәммәтхаҗи язылган. Мөхәммәтхаҗиның Арча рус-татар училищесын тәмамлаганы, Уфада имтихан тотып, указлы мулла булып, Таузарда имам итеп сайланганы билгеле. Ә Идрис Исмәгыйлевнең татар мәктәбе тәмамлавы һәм коммунист булуы күрсәтелгән.

Хәсән Якупов.

Элек-электән авыл халкы үзенең мөгаллимнәрен, газиз балаларына аң-белем һәм тәрбия бирүчеләрне олылап яшәгән. Ничек шулай туры килгәндер — авылга килеп укытып киткән укытучылар барысы да алдынгы фикерле, мәгърифәтчелеккә омтылган кешеләр була. 1899 елны Сосна авылында туган Якупов Хәсән Даут улы җәйге чорда шәһәрдә эшләп, кышкы якта авыл мәктәпләрендә укыткан. Ул 1924—1925 уку елында һәм 1929—1932 елларда (тагын өч ел) Таузарда укыта. Колхозлашу елларында авыл халкының ышанычлы киңәшчесе була.

Мәктәп яшеннән узган өлкән буын кешеләрен укырга һәм язарга өйрәтә. Таузарда эшләгән еллардагы хезмәтен бәяләп (өч елга ике мәртәбә), укытучыларның август һәм гыйнвар конференцияләрендә акчалата премияләр белән бүләкләнә. 1949 елны СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Ленин орденына лаек була.



Гарифә апа һәм Габделхак абый Гыйззәтуллиннарның төрле елларда төшкән фотосурәтләре.

1931—1935 елларда Таузар егете Гыйззәтуллин Габделхак абый, Рабига апа, 1932 елдан Шода кызы Гайсина Гарифә апа (алар Габделхак абый белән гаилә кордылар) килеп, укыту-тәрбия эшен тагын да җанландыралар. Гыйззәтуллин Габделхак абый Бөек Ватан сугышына кадәр үк педучилище тәмамлый, сугышта офицер хезмәтендә катнаша, яралана. Сугыштан соң да укытучылык эшендә һәм партия юнәлешендә эшли. 1945—1953 уку елында Нөнәгәр башлангыч мәктәбендә мөдир һәм укытучы була. Сугышта алган яралары ачылып, Казанда госпитальдә дәваланганда, 1956 елның 5 гыйнварында үлә, Казанның Иске Татар зиратында җирләнә.

Галия апа Гыйбадуллина (Гыйззәтуллина).

1936 елда Таузар башлангыч мәктәбенә Карадуган (ШКМ) мәктәбен тәмамлаган Кариле кызы Гыйбадуллина Галия апа килгәндә, мәктәптә Кенәбаш егете Вәлиев Мөбарәк укыткан. Вәлиев Мөбарәк армия хезмәтенә киткәч, Көшкәтбаш кешесе Гыйбадуллин Шәрәфи килгән. Галия апа Таузар егете Гыйззәтуллин Хәким абый белән гаилә корып, беренче кызы Венераны тудырганда аның урынына Апаздан килгән Нуриев укыткан.

Мәсрүрә апа Сафина.

Инде килеп, Бөек Ватан сугышы елларында Галия апа төрле укытучылар белән эшли, алар — Таузар кызлары Сафина Мәсрүрә, Шакирова Тайфә апалар. Сугыш еллары укытучыларының эшен, аларныңниләр күргән, төрле авырлыклардан нинди юллар белән чыгуын тасвирлап язарга сүзләр җитмәстер... Ул еллардагы мәктәп хәлен тыл ветераннары белә. Әмма алар да кими бара шул. Сугыш еллары мәктәбенең иң-иңямансу хәле — укучыларның ач-ялангач булуы, өстәвенә, класс бүлмәләренең салкынлыгы һәм дә иң авыры — ятимлек. Күпчелек өйләрдә бозланып каткан ишекне ачарлык ир-ат заты (олырак малай яки көчлерәк бабай) да юк. Күршеләрнең морҗа башыннан төтен чыгуына карап, үзара исәнлек турында чамалап беләләр, инде хәле булган кеше күршегә кереп хәл-әхвәл сорашуны үзенең бурычы итеп саный. Ашау ягы үтә фәкыйрь: ипи юк, каты суыкларда булган бәрәңгеләре дә өшеде, бер чокыр он туглап шулпа ясарга тоз юк, ут тергезеп учак яки мич ягарга шырпы юк. Бүген яга алса, иртәгесе өчен көлгә күмеп, кисәү очын саклыйлар, сакланмаса, төтен чыккан өйләрдән утлы күмер алып кайталар. Яхшылап киенергә кием яки тәнеңне юарга сабын юк. Анысының юклыгына түзәр дә идең, чөнки утын көленнән селте ясап киемнәрне юып чистартып була. Ягарга утын булмаганда, лапас түбәсеннән умырып алып салам ягалар иде, ә салам көленнән селте ясап булмый. Сабынсызлыкның үз чире — ачлыкка өстәмә авырлык — бет һәм аның да аламасы — тире, тиф авырулары кешеләрне, балаларны бик-бик җәфалады. Ә бит мондый тормыш бер яки берничә көн генә түгел, 1418 көн...

Мин үзем дә укучы, безнең гаилә зур: бер әнигә биш бала һәм дә бер әби. Өйнең салкынлыгы, ачлык, хәерчелек тәмам үзәккә үтте. Әни дә, әби дә күрмәс әле дип уйлап, лапас артына чыгып, "кайчан бетә инде бу сугыш..." дия-дия кычкырып елый идем, әби күреп, миңа үзенең киңәшләрен бирде:

— Син зур инде, әнә синнән кечкенә өчәү бар бит, аларны күр, кузгалак җыеп булса да ашатып кара, алар бит акбаш яки кузгалакны танып белми... — диде дә әбием-мәрхүмә, миңа кушылып елады. Кайчандыр җыеп саклаган бер чокырдай арыш табып, аяклы табада (аны өчаяк дияләр иде), астына чыра ягып,

кыздырып бирде. "Өйдә генә ашагыз, бригадир апагыз күрсә, әниегезне алып китәрләр," — дип куркытып та куйды.

Ул 1418 көндә күргәннәрне, ашка агулы үлән кереп (вак ак чәчәкне җыеп салгач, аш тары ярмасы ашына ошап китә), аңсызланып егылып ятуларны, ачтан шешенүләрне, суыктан чирләүләрне адәм баласына Аллаһы Тәгалә бүтән күрсәтмәсен иде.

Ә мәктәп... Мәктәп тормышның дәвам иткәнен күрсәтеп яшәргә тиеш. Моны ул елларның һәр укытучысы, авыл-колхозның җитәкчеләре аңлап эшләделәр. Каяндыр язу карасы (аны корымнан ясадык) табасы, район газетасы яки иске китапларның юл арасына булса да яздырып, язарга өйрәтәсе, укырга өйрәтәсе бар. Аны укытучылар намус белән үтәделәр. Оста куллы бабайлар каурыйдан ручка, агач линейка, хәтта циркуль кебек уку әсбапларын да үзләре ясап, мәктәпкә ярдәм иттеләр.

Укытучылар мәктәпкә килә алмый калганнарның өенә барып хәлен беләләр: ә анда... укытучы юата алмый торган хәлләр... Әтиләренең сугыш кырында геройларча ятып калуы турында кара пичәтле язу-белешмә. Берничә минут сүзсез тыңлаганнан соң, укытучы сүзләрен барлап өйдәгеләрне юатып карый, утын кисәкләре табып мичкә ягып җибәрә, колхоз идарәсенә ике-өч көнлек кенә булса да умачлык он сорап бара... Болар барысы да юкны бар итеп эшләнә, көн саен (1418 көн буена) үзе дә ач-ялангач укытучы кайлардан көч тапкандыр? Әле төне буе утын хәстәрләп, мәктәпне ягып җылыту, мөмкинлеге булган йортларга кереп фронт өчен җылы киемнәр җыю кебек көндәлек эшләрне дә башкарасы бар. Ә инде кышкы салкын көннәрдә колхозның авыр хәлдә калган терлекчелек фермасында терлек караучыларга булышу, иң кирәкле көч булган атларны тәрбияләү-саклау буенча төрле эшләрдә катнашырга кирәк. Чөнки төн үтүгә яңа көн туасына, авылның — тылның яшәргә тиешлегенә, безнең урамга да бәйрәм — җиңү киләчәгенә ышанып, башкаларның да офык артындагы якты өметен сүндермәү кирәк бит.

Караңгы салкын кышлар үтә, якты җылы кояш карау бераз яшәүгә дәрт өсти. Әмма көннәрнең озыная баруы белән ачлыктан бәгырьләр киселә, буыннар хәлсезләнә, төрле авырулар арта. Колхоз җитәкчеләрен чәчүгә җир эшкәртү һәм тиешле агротехник шартларда язгы чәчүне башкару өчен чәчүлек орлык җитмәү, атларның хәлсезлеге һәм сан ягыннан елдан-ел кимүе (үләләр, уңайрак атларны фронтка алалар), тагын-тагын бик күп нәрсәләр борчый.

Бу урында М. Мәһдиевнең "Кеше китә — җыры кала" повестеннан бер өзек китерәсе килә: "Тимерхан бөтен күрәчәкне Ста-

линград белән Курск дугасында күреп бетердем дип уйлаган иде. Менә монда икән ул тормышның чыны... Фронтта, ичмасам, ашау кайгысы булмады, бөтен куркынычы шунда — үлем синең күзеңә текәлеп карап тора.

Ә монда... авылда... үлем үзе читтәрәк. Ул каядыр басу артыннан салкын гына карап тора. Ул акрын килә. Әмма ышанычлы килә. Фронттагы үлемне бер минут эчендә читкә куып була, бик көчле артподготовка барганда үлем чигенеп тора. Монда исә ул кояшлы көнне дә, яңгырлы көнне дә теш ыржайтып басу читеннән авылга карап тора. Салкын сулышын өрә...

Госпитальдән Хәкимулла кайтып төште. Ике култык таягына арык гәүдәсен салган, бер аяксыз, күзе бәйләүле. Пуля колак яныннан кереп бер күзне, яңак сөяген, борынны, теш казнасын җимереп чыккан. Юлда очраса, танырлык түгел.

Күрешергә кергән Тимерханны танымады. Дер-дер калтырап:

— Менә мин шушылай булдым инде, старшой, — дип, сыңар күзеннән яшь коя башлады.

Йортта ашарга юк иде. Хәкимулланы көн саен арбага утыртып Васфикамал борчак җиренә эшкә алып йөрде. Үзе борчак чаба, Хәкимулла борчак чүмәләсе янында кузак ярып ашый. Янына килгән кешеләргә сугыш хәлләрен сөйли..."

Әлеге өзектә нәкъ менә Таузар иле авылының сугыш еллары сурәтләнгән. Тик геройларның исемнәре генә башкача. М. Мәһдиевнең әсәрендә чынбарлык ничек бар шулай бирелгән. Шуңа да авыл кешеләре өчен кадерле язмалар алар.

Алда тасвирланган тормыш ул аерым кешеләр өчен генә түгел, ә барлык авылларда, барлык мәктәпләрдә барлык укытучылар һәм укучылар күргән хәлләр турында кыскача гына язылган дип аңларга кирәк. Чөнки сугыш — сугыш инде ул... Ә сугыш чорында Карадуган җидееллык мәктәбен тәмамлаган Таузар яшьләре Хаҗиева Фәүзия, Гомәров Вагыйз, Касыймова Фирдәвесләр 1942—1945 елларда Арча педучилищесында укып, укытучы булып кайталар. Шунда ук 1943—1946 елларда укыган Хәсбиев Равил, Хөсәенов Исламнар да укытучы һөнәре алалар. Әлеге яшь укытучылар Балтач районының төрле авылларында укытып, алдынгылар исемлегендә булдылар. Алар мәрхүмнәр, авыр туфраклары җиңел булсын дип әйтик.

Халыкның көткән көне — җиңү килде! Җиңү көнен кем кайда ишетеп, нинди халәттә булуын язып аңлатып булмыйдыр да! Чөнки ул барыбызның да иң-иң көткән көнебез, өметебез, яхшы киләчәккә хыялыбыз иде — тулы мәгънәсе белән бәйрәм! Бу бәйрәм бер ягы белән гомерем буена күңелемдә якты истәлек

булып саклана, ул да булса — беркем дә аны аракы белән юмады! Сугыштан соң эшләнгән киноларда гына Җиңү көне бокаллар чыңлавы, рюмкалар чәкеше белән бизәлә башлады. Әле ул елларда авыл халкы кайгы яки шатлыкны аракы белән юа белми иде.

Инде икенче көннән үк кайтачакларны көтү башланды, ә кайтмый калучыларның өйләрендә үкенечле күз яшьләре белән чыланган ятимлек салкынлыгы дәвам итте.

Класс укучылары болай да төрле иде, ә хәзер әтиләләр һәм гомерләре буена әтисез калганнарга бүленде. Укытучылар күңеленә, борчулы тынгысыз җанына бары да сыя, һәркемгә, һәр укучыга үзенә генә хас җылы сүз табыла. Менә алар, әти диеп әйтергә, өйдә дә, урамда да әти кешенең көчле һәм акыллы сүзен ишетергә тилмереп яшәргә дучар ителгәннәр:

Фәттахова Мөнирә, Разия — әтиләре Фәттах;

Насруллина Наилә, Рауза, Рәшит, Вәдүт — әтиләре Мәхмүт;

Хәкимов Искәндәр — әтисе Мәгъсүм;

Яппаров Хәниф, Ләлә, Зөлхәбирә — әтиләре Мәхмүт;

Хәсәнова Әминә, Мәүлизә, Зәлфәр, Кадим — әтиләре Кәрим;

Гыйләҗева Рауза, Әлтәф, Рәкыйп, Глара, Рәдиф — әтиләре Сөнгатулла;

Низамиев Икрам, Нурсөя, Бәрия, Наҗия — әтиләре Галәветдин;

Нуриева Дания, Люция, Расиха — әтиләре Рәхим;

Габдрахманова Сәкинә, Сафура, Әдарәт, Барис — әтиләре Габдрахман;

Кашапов Рәфәгать, Мәсхүдә, Флера Тәслимә — әтиләре Кашафетдин;

Хаҗиева Факия, Фәүзия, Оркыя, Сәйдә, Мөдәррис, Рәис — әтиләре Хаҗи;

Сабиров Ринат — әтисе Барый;

Сабирова Сәгурә — әтисе Мөбарәк;

Ибраһимова Нәкыя — әтисе Хәбибулла;

Исхакова Мәгъсүмә, Сәвия — әтиләре Заһидулла;

Хәлиуллин Фәрит, Филсур, Гадения — әтиләре Зиннәтулла;

Ситдыйкова Венера — әтисе Габделхак;

Усманова Кәүсәрия, Гыйльфан, Гыйльван, Фәргать — әтиләре Усман;

Гарипова Сәвия, Рөстәм, Суфия — этиләре Гариф;

Вәлиуллин Мәсхүт, Газзә — этиләре Гомәр;

Гарипова Розалина, Ринат, Дамир, Налия — этиләре Гафурҗан.

Бу хәл Таузар иле хәле генә түгел, ә районыбыз авыллары, республикабызның һәр шәһәре, районы авыллары буйлап, ил буйлап шулай — ятим балалар, аларның тол калган әниләренең хәле. Этиләре сугышта югалган ятимнәр "инде үзем күргәннәр газизләремнең башына килмәсен" диеп тели-тели гаилә корып, балалар үстерделәр, оныклар тәрбиялиләр. Жырдагыча:

Гомер уза аккан сулар кебек
Йөрәкләрдә кала ярасы...

Әйе, этисез үскән ятимнәр гомерләре буена ярдәмгә, ичмаса, эчкерсез хәл белүчеләргә, йомшак сүзгә, игътибарга мохтаҗлар иде. Бөек җиңүнең күптөрле санда юбилейларын үткәрдек, ел саен үлеп калганнарны бер минут тынлык белән искә алабыз, балалары һәм оныклары өйрәнү өчен "Хәтер" китабы да өләштек, әмма ятимнәрнең яралы күңелләренә җылы сүз таба алмадык. Тормыш дәвам итә, ятимнәрнең дә исәннәре үз көннәрен үзләре күрергә, гадел тормыш итүгә, намуслылыкка үзләренең ачы күз яшьләре аша, маңгай тирләре түгеп өйрәнделәр. Колхоз-совхозларда һәм һәртөрле җитештерүчән хезмәттә үз урыннарын табып, алдынгылар сафында эшләделәр һәм яшиләр.

Алда әйтеп киткәнемчә, авыр сугыш елларында Таузар башлангыч мәктәбендә укыткан, балаларга һәм авыл халкына һәрьяклап ышанычлы таяныч булган Галия апа, Тайфә апа, Мәсрүрә апаларга барлык авылдашларыннан — Таузарлылардан иң изге теләкләр белән олы рәхмәтләре ирешсен иде.

Тыныч төзелеш еллары башланды... Әмма мәктәп әле сугышка кадәрге хәленә тиз генә ирешә алмады. Билгеле, бу ил белән сугыш җимереклекләрен торгызу башлануга бәйле иде. Эти-әниләр һәм балалар хәленә караганда, 1945—1950, 1950—1955 уку елларында укыту-тәрбия эшләренең шул еллар өчен генә хас булган кыенлыклары, проблемалары бар иде. Сугыш елларында ир-егетләр булмаудан һәр гаиләнең яшәү урыны (йорты һәм абзар-курасы) ярым җимерек хәлдә; кием-салым искереп тузган; колхозчыларга хезмәт көненә икмәк бик аз бирелә; йортларда ипи, май, ит кебек туклыклы ризыклар бөтенләй кулланылмый, чөнки юк алар. Сугыш җимереклекләрен торгызу өчен күптөрле

салым (ит, май, сөт, йон салымнары) салына, заемнар җыела. Болар барысы да укыту-тәрбия эшен кыенлаштыралар иде.

Ире Гыйззәтуллин Хәким абый, сугышта алган яралары яңарып, 1946—1947 елларда госпитальдә ята, шунлыктан Галия апа мәктәптән китәргә мәҗбүр була. Аны Касыймова Фирдәвес алыштыра. Фирдәвес апа колхоздан мәктәп җире өлешенә тигән икмәкне аерып алып, онга тарттырып, ипи пешереп, балаларга өлешләп ашата торган була. Яшь укытучының бу изге эшеннән дә кер эзләүче табылып, дәгъва суд тикшерүчеләренә җитә. Ләкин ул тулып җитмәгән дип саналган граммнар шулкадәр кечкенә була, тикшерүчеләр яла ягучыга тиешенчә аңлатып бирәләр: әлегә өендә ипинең исен дә тоймаган баланың кулына мәктәптә ипи сыныгы тоттырып ашату ул еллар өчен иң-иң игелекле эш санала. Сугыштан соңгы елларда укыткан Фирдәвес апа, Тайфә апа, Мәсрүрә апаларның эшләрен укучылары рәхмәт белән искә алалар.

Шакирова Тайфә (сулда) һәм Касыймова Фирдәвес Таузарда укыткан елларда.

1950 елның 15 августында, район мәгариф бүлеге приказы белән (укып кайткач та), беренче мәртәбә Карадуган мәктәбенә эшкә килүем исемдә калган. “Укытучылар бүлмәсе менә шушында” диеп, мине бер катлы, өчкөлле йорт янына китерделәр. Керергә кыймый торам, чөнки баскыч төбендә ак җәймәсе пөхтә итеп корылган, сарыга буялган (тәртәсе һәм көпчәкләре кара төстә) бәбәй арбасы тора. Шикләнеп калдым, гаиләле кешеләр йорты кебек тоелды. Кереп танышкач аңладым, укытучы Фәүзия апа кызын (икенче баласы Илзияне) кечкенә бәбәй арбасына тартып, Таузардан, Карадуган мәктәбенә эшкә — укытырга йөри икән.

Сугыштан соңгы елларда балалар саны җитмәүдән (класслар кушып укытыла иде) аз комплектлы мәктәпләр барлык-

ка килде. Таузарда укыта торган Шакирова Тайфә апа янына 1950 елны укытучы-мөдир итеп Галимова Зәйтүнә билгеләнә, ике укытучыга — дүрт класс. Әле аларга, ярты ставка булса да риза булып, Кенәбаштан Нуруллина Оркыя апа төшеп кушыла. Тагын бер елдан Дөбъяздан Капкаева Рәйсә апа кайтып керә. “Аның торыр урыны да, тотарга акчасы, ашарга ризыгы да юклыгын белгәч, үзебезгә — Арбашка алып кайттым. Эшне дә табарга туры килде — тагын шул бер өлешне бүлеп эшләдек”, — дип яза укытучы Галимова Зәйтүнә. Капкаева Рәйсә апага аерым эш урыны табылгач, 1952—1953 уку елында Зәйтүнә үзе янына Хәлиуллина Фәүзия апаны алып, бер ярым штатлы урынны бүлеп, бергәләп эшлиләр. Әмма балалар саны кимү дәвам итә, Фәүзия апа кыскартыла, ул биш ел элек килен булып төшкән авылы Таузардан туган авылы Арбашка йөреп, ясле-бакчада эшли.

Линура Миннебаева.

1957 елны Галимова Зәйтүнә Карадуганга күчерелә, Таузарга яшь укытучы Миннебаев Марсель килә. Ул елларда эш урыны булмаса да, укытучыларны төрлечә күчергәләп, яшь кадрларны, ягъни уку йортын тәмамлап кына кайтучыларны беренче чиратта эшкә урнаштыралар иде. Әмма Марсельгә озак эшләргә туры килми — аны армия хезмәтенә чакыралар. Башланган уку елын тәмамларга ике-өч ай гына калганда, ул урынга Таузар иле оныгы Линура килә. Әтисен 1956 елда гына җирләгән Линура өчен Таузар авылы бик якын була. Шушы авылда туып-үскән укытучы әтисе Гыйззәтуллин Габделхак белән әнисе Гарифә апаның бергәләп яши һәм эшли башлаган авылы бит ул. Укып кайтып, район мәгариф бүлегендә эшли башлаган Линура җай чыгу белән: “Мине әти белән әнием эшләгән мәктәпкә җибәрегезче”, — дип, РОНО мөдире Рамил Фазлыев бүлмәсенә керә. РОНО мөдире: “Ике-өч ай гына эшлисе бит, анда сиңа уңайлы булмас...” — диеп аңлатып караса да, Линура Таузар башлангыч мәктәбенә эшкә килә. Шул ике-өч ай вакытта булса да, Линура әтисе-әнисе йөргән сукмаклардан атлап, әтисенең төп йорты булган Таузардан җаны борчылуларына дәва тапкандай була. Бәлки шушы башлангыч Линураның үз фәнен яратучы мактаулы тел-әдәбият укытучысы булып китүенә нигез булгандыр.

1958—1959 уку елында Хәлиуллина Фәүзия апа Таузар башлангыч мәктәбенә укытырга билгеләнә. Шул кайтудан Таузар ки-

Фәүзия Хәлиуллина.

лене 1958—1967 еллар арасында игелекле хезмәт итте — укытты. Фәүзия апа белән Корбангали абый дүрт кыз, бер егет тәрбияләп үстерәләр. Кече кызлары Разия Арча педучилищесын тәмамлап, Карадуган ясле-бакчасында эшли, югары дәрәҗәле методист, халык мәгарифе отличнигы һәм методик белешмәләр, китаплар авторы.

1967—1968 уку елында Арча педучилищесын тәмамлап, Таузар кызы Әхмәтова Фәния белән Югары Кенә кызы Дәүләтшина Рәйсә Таузар мәктәбенә укытучылык эшенә киләләр. Яшь кызлар эшне үзләренчә җанландырып җибәрәләр. Әмма бу хәл озакка бармый. Балалар саны кимүне сәбәп итеп, югарыдан килгән әмер белән, 1977 елны Таузар башлангыч мәктәбе ябыла.

1895 елда нигез салынып эшли башлаган һәм авыр елларда (сугыш еллары, сугыштан соңгы еллар) яшәгән, эшләгән мәктәпнең бетерелүе Таузар иленең тагын да кечерәеп, бөрешеп калуына нигезле сәбәп булды. 14 елга сузылган бу “аерылу” авылның яшәү рәвешенә, сулышына фәкать тискәре йогынты ясады. Авыл халкы бу хәлне авыр кичерде. Укымышлы кадрлар үстергән авыл мәктәбе яшәргә тиеш иде! Шул рәвешчә колхозларны эреләндерү сәясәте бу елларда үзәктән читтә калган авылларның сүнүенә китерде.

Халык сорый торгач, ниһаять, 1991 елны мәктәп яңадан эшли башлады.

Мәктәп ябуны авыр кичергән шул ук Рәйсә, (ул Таузар егете Василга кияүгә чыгып, Ибраһимова булды) канатланып, мәктәп ачу артыннан йөри башлады. Мәктәп яңадан туды, диярсең! Җәйге көннәрдә тиешле төзекләндерү эшләре барды, бакча булдырып, анда җиләк-җимеш куаклары утырттылар, чәчәк түтәлләре төрле төстәге чәчәкләргә күмелде. Укучы балаларның шау-гөр килгән матур тавышлары авылга элекке сулышын өрде.

Бүгенге көндә мәктәптә җиде бала укый, Гыйззәтуллина Тәнзилә белән Ибраһимова Рәйсә укыталар. Алар икесе дә авылның игелекле киленнәре. Балалар саны кимүне сәбәп итеп, авылны башлангыч (1 баскыч) мәктәпсез калдырудан авыл халкының рухи көче, аның киләчәге яхшы якка үзгәрмәде. Бу ачы тәҗрибәне киләчәктә дә истә тотарга кирәктер.

ТАУЗАР ИЛЕ —
МӘГЪРИФӘТ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ЧИШМӘСЕ

...Моңсу өянкеләр кебек
Уйларга талган чагым...

Гарифҗан Мөхәммәтшин.

Мин Таузар иле килене, уйлануларым да — укыткан укучыларымның туган авылы, кешеләре — таузарлылар турында. Мин 1950 елдан башлап Карадуган мәктәбендә укытып, лаеклы ялга да шул мәктәптән киттем.

1955 елда Таузар авылына килен булып төштем. Ул елларда җитмешләп хуҗалыктан торган Калинин исемендәге колхозның сарыкчылык белән шөгыльләнүче бер бригадасы булган бу авыл турындагы фикерләр минем күңелемдә тирәнәйде, киңәйде, кыскасы, үсте дә үсте. Колхоз үзәгеннән читтә булса да, анда төпләнеп яшәүче халык үз-үзен тотышы, сөйләм теленең йомшаклыгы, гомумән, итагатьлелеге белән аерылып тора иде. Бу авыл халкының зур булмаган инешне бөяп, анда көндез тегермән тарттыруы һәм кичләрен районда бердәнбер суга көйләнгән электростанция эшләтә алулары ул еллар өчен гаҗәеп хәл иде. Колхозның яшелчә бакчаларының тиешле агротехник чаралар белән эшкәртелгән, күрер күзгә үк сокландыгыч түтәлләре, Шушма елгасындагы Карадуган тегермән бөясе суы менеп җитүдән авылның нәкъ уртасыннан, ике урам арасыннан агучы инешнең ярларын тутырып утырулары, ә инде башыңны күтәребрәк күзәтсәң, ком базы үрләре, Шушма аръягындагы текә ярлы Дүче тау сыртлары, Шушма буе болыннары күңелләрне дулкынландыра торган матурлык бирә иде. Уйландыра торган сихри гүзәллек...

Сүзем бит укучыларым турында әле... РСФСРның атказанган укытучысы Фәрзетдин абый Гыймадиев Карадуган мәктәбенең 70 еллык юбилеенда ясаган чыгышында мәктәп директоры булып эшләгән елларын тасвирлап: “Минем эшләгән елларымда биш авылдан килеп укучы балалар арасында Таузар балалары һәрьяклап үрнәк алырлык тырыш булулары, фәннәрне яхшы үзләштерүләре белән аерылып тордылар. Алардан чын кешеләр үсеп җитте”, — дигән иде. Ул чорда Таузар башлангыч мәктәбендә сугыштан соң Арча педагогия училищесын тәмамлап

кайткан үтә дә тырыш кыз Зәйтүнә Галимова укытты. Мәчеттән бераз үзгәртеп эшләнгән мәктәп бинасында җыештыручы булып эшләүче Зәйнәп апа һәм ата-аналар белән урманнан утын хәзерләтеп алып кайтып, шул утын белән укучылар дәрескә килгәнче класс бүлмәләрен җылытып куялар иде.

Зәйтүнә Галимова.

Зәйтүнә Галимова укыту-тәрбия өлкәсендә балалар хәлен аңлап эшләүче оста педагог була. Ул елларда колхозчыларның эш урыннарында дөнья хәле белән таныштыру, ата-аналарны тәрбияләү эшен дә укытучылар алып бара иде. Кыскасы, укытучылар — агитатор, пропагандист һәм дә авылның "артистлары" да. Зәйтүнә Галимова һәркем күңеленә үтәрлек итеп моңлы матур тавышы белән озын көйләрне дә оста башкара иде.

Чыннан да, уйланырсың да шул... Бүген район җирлегеннән үсеп чыгып, татар мәктәпләрен тәмамлап, үзләрен фән дөньясында балкыткан дүрт академикның (Мазһаров Әхмәт, Габделхәев Билсур, Зыятдинов Азат, Әхмәдиев Фаил) икесе Таузар иле егетләре булуына ни диярсең!

Юкка түгелдер, юктан түгелдер... Уйлана торгач, өлкәнрәк буыннарның яшәү рәвеше, тормыштан ямь таба белүләре, алга карап максатчан яшәүләре ачыклана бара. Һәр авылның үз тарихы, ягъни яшәүчеләрнең буыннан-буынга күчә торган үзләренчә яшәү рәвешләре була.

Таузар халкы хөрмәт белән карап, үзенең олы киңәшчесе итеп санаган Хәбибрахман абый Хөсәенов Гражданнар сугышында катнашкан, атаклы Азин дивизиясендә хезмәт иткән, Бөек Ватан сугышы ветераны һәм күркәм холыклы кеше иде. Укучылар белән очрашуга чакырып сөйләшкәндә, аның заманга ярашлы ачык фикерле, зирәк зиһенле булуына соклана идек. Хәбибрахман абзый белән күп очрашырга, тормыш сабакларын өйрәнү өчен киңәш-табышка барырга туры килә иде. Ул һәркемне берничә сүздән аңлый белде, тиешле киңәшен бирде, авылның мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырышучы аксакалы иде. Ул диннең бик нык кысылган чакларында да ипле генә итеп, халык күңеленә тынычлык, сабырлык иңдерерлек акыллы сүзләре белән, белгән гамәлләрен эчкерсез башкара иде. Әйтик, кеше туды — исем кушарга кирәк. Вафатыннан соңгы олы хәсрәткә җан тынычлыгы бирерлек итеп фани дөньядан озату — җирләү

эшләрен дә Хәбибрахман абзый тыйнак һәм җыйнак башкара иде. Авылның — колхозның барлык эшләрендә дә үтә дә намус белән катнашып, һәрчак башкаларны әйдәүче кеше иде. Хөсәеннекеләр электән таза тормышлы көчле нәсел: абыйсы Фәйзерахман Казанда яши — Таузардан шәһәргә килүчеләр өчен бердәнбер тукталу урыны була, энесе Ярулла турында Карадуган музеенда документлар саклана — ул кулаклар исемлегендә куылырга тиешле була. Олы улы Илдусны абыйсы Хәбибрахманга тәрбиягә калдырып, кече малае (2 яшь) Энгель һәм җәмәгате Зәйнәп белән Казахстан ягына китеп урнаша Ярулла, гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яшиләр. Улы Энгель һәм аның ике улы да югары белемле инженерлар. Ә Хәбибрахман абыйда калган Илдус җәмәгате Фәймә белән өч егет тәрбияләп үстерәләр. Югары белемле бу егетләрнең икесе (Рәис белән Фәнис) авылда сәүдәгәрлек эшен оештырып, уңай гына эшлиләр, авыл халкы аларга рәхмәтле. Ә уртанчысы Рубис — Татарстан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш министры урынбасары хезмәтендә. Мәктәптә укыган елларында ук Рубис үзе актив һәм алга карап эш итә иде. Пионер дружинасы белән яхшы җитәкчелек иткәне өчен Бөтенсоюз пионер активының теплоходта Идел буйлап сәяхәтенә катнашу хокукына иреште — сәяхәткә юллама белән бүләкләнде. Кече уллары Фәнис тә оста оештыручы һәм яхшы укучы буларак башкалардан аерылып тора иде, ул укучылар комитеты председателе булып актив эшләде. Хәбибрахман абыйның барлык кыз туганнары да укымышлылар. Абый кеше буларак ул үзенең сеңелләре: Мәһибәдәр, Мәһикамал, Сәйдәбикә, Мәчтүрәләрне укыту өчен тырышты.

1911 елда туган Мәчтүрә апаның сөйләве буенча, Таузарда башлангыч белемне алгач, алар апасы Сәйдә белән Түнтәр мәктәбендә укыганнар. Хәбибрахман абый һәр атнада сеңелләрен алып кайтып, атна башында илтеп куя торган булган. Түнтәр мәктәбен тәмамлагач, кызлар Казанда педагогия техникумында укыганнар, икесе дә Казан дәүләт университетына укырга кергәннәр. **Мәчтүрә апа 1936—1937 уку елында университетның химия-биология факультетын тәмамлый.** Ул безнең якта сугышка кадәр үк университет тәмамлаган беренче хатын-кыздыр, мөгаен. Мәчтүрә апаның кызы — табиб-терапевт, фән кандидаты, улы — инженер. Сәйдә апа университетның физмат факультетының икенче курсын бетергәч, гаилә хәле буенча, укытучылык эшенә күчә. Мәһикамал апа (1905 елда туган) Күлле Кимедәге укытучылар әзерләү курсында укып, гомерен укытучылык эшенә багышлый. Ул Казанда партия мәктәбен тәмамлаган

Уртадагы ханым — Шәмсекамәр апа — укымышлы Хөсәеновлар: Фәйзрахман, Хәбибрахман, Ярулла, Мәһибәдәр, Мәһикамал, Сәйдәбикә, Мәчтүрәләрнең әнисе.

XX гасырның 20 нче еллары.

авылдашы, Таузар егете Исмәгыйлев (Гарипов) Гафурҗанга кияүгә чыга. Сүз уңаеннан әйтим, Гафурҗан абый Таузарда беренче колхоз төзүче, колхозның беренче председателе була. Ул соңрак Красный Бор (хәзерге Әгерҗе районы) Исәнбай МТСына политбүлек начальнигы итеп җибәрелә, анда колхоз төзи, председателе булып эшли... һәм репрессиягә эләгә. Срогын тутыргач, гаиләсен алдырып, Себердә кала, үзе теләп фронтка китә, офицер була, сугыш кырында ятып кала. Мәһикамал апа белән Гафурҗан абыйның ике кызы һәм ике улы да югары белемлеләр. Олы кызы Розалина музей белән тыгыз элемтәдә тора, үзе шәһәр мәктәбендә математика укыта, завуч булып эшли, өч баласы да югары белемлеләр.

Өлкән апалары Мәһибәдәр 1900 елны туган, медицина техникумын тәмамлый, гомерен кешеләр сәламәтлеген саклауга багышлый. Безнең Таузарда уку-белем алу турында сүз барса, Хөсәеннекеләр — Хөсәен кызлары өлге итеп күрсәтелә.

Гафур абыйның бертуган энесе Идрис абый турында да матур истәлекләр саклана.

1921 елда мәктәптә тутырылган анкетада Таузар мәктәбендә Муллахаҗи белән икенче укытучы булып Идрис эшләгәнлеге теркәлгән. Идрис Урта Азиядә наданлыкны бетерү өчен көрәшкә җибәрелә. Авыл халкы Идриснең белемле булуын, халыкка язу-сызу эшләрендә ярдәмен рәхмәтләр белән искә ала. Әйтик, безнең бабайга да хәлиткеч ярдәме турында сөйләп рәхмәт әйтәләр. Безнең Зыятдин бабайны кулаклар исемлегенә кертеп, Балтачка төшереп ябалар. Шул вакытта Идрис абый бабайның яллы хезмәт кулланмавын, киресенчә, улы Шәймулланың Түнтәр баенда һөнәргә өйрәнүче хезмәтче, икенче улы Гомәрнең Бал-

тач баенда һөнәргә өйрәнүче хезмәтче эшендә булуларын күрсәтеп, русча бик грамоталы белешмә яза, аны авыл Советында раслатып, суд тикшерүчеләренә тапшыралар. Нәтиҗәдә, кырык көн төрмәдә ятканнан соң, бабай азат ителә. Кайткач, куанычыннан төп нигездәге килен — Ләмиганы (Бакыйның әнисе) Казанга, шәһәр күрсәтергә алып бара.

Мәрхүм Зыя бабай (аны авылда кыскартып шулай әйтәләр иде) турында сүз чыккач, аның да авылда алдынгы карашлы булуы, сугышка кадәр үк "Кызыл Татарстан" газетасы алдырып укуы турында сөйлиләр. Авылда буыннан-буынга сөйләнеп күчә торган риваятьләр яши. Гражданнар сугышы елларында Таузарга бер әфәнде килеп, сәнәкчеләр сугышына китәргә кешеләр җыеп, өндәп сөйли. Хәтта барырга, сәнәкчеләр төркеме төзергә теләүчеләр дә була. Шунда әлеге Зыя бабай сорап куя: "Кемгә каршы сугышка барабыз инде?" Әфәндебез кызылларга каршы сугышырга кирәклеген аңлата. Ә Зыя бабай: "...һе-е алай... минем бер улым кызылларда иде, ә бу икенчесен аңа каршы сугышырга өндисезме?!" — ди. Җыелган халык хикмәтне аңлап, ухылдап куя, тавыш күтәрелә... Ә теге әфәнде килгән юлыннан кире китә. Ике-өч көн үтүгә, бу яктан барган сәнәкчеләрне Арчаның кирпеч заводы елгасы ярыннан пулеметчылар уты кырып каршы алу турында хәбәр килеп җитә. Бу шомлы эштән исән калган авыл халкы Зыя бабайга рәхмәтен үзеннән соң килгән яшьләргә аңлата килә. Бабай турында оныклары Бакый, Тәзкирә апа да бик яратып искә алалар. Бабалары һәр ике улыннан туган беренче оныклар — Тәзкирә апаны һәм Бакыйны Казан күрсәтергә алып бара. Таузар—Арча арасында 35-40 чакрымны җәяүләп үтәргә кирәк: берсе малай, икенчесе 70 яшьлек бабай. Юлда бабай оныгының дәрәҗәсен күтәреп очраган юлчыларга: "Отлично укыганы өчен шәһәр күрсәтергә алып барам", — дип, горурланып сөйләп тә куя. Шул ук елны Тәзкирә апа җиденче классны тәмамлый. Икенче баруында Тәзкирә апаны кайсы да булса урта уку йортына укырга урнаштырырга дигән матур хыялы да була бабайның.

Миңа, килен кешегә, Зыя бабайның зирәклеге турында истәлекләр тыңлавы күңелле иде. Ә менә килен булып төшкәндә мине сабыйларча куанып каршы алган Зыя бабайның улы әткәй (Бакыйның әтисе Шәймулла була) турында, барлык уңай сыйфатларын да санап, бу язмамда әйтеп бетерә алмам. Гәүдә һәм йөз матурлыгы, физик һәм рухи яктан көчле булуы, үтә дә туган җанлы һәм дә гармун, музыкага хирыс булган нечкә хисле, заман сулышын аңлап яшәүче булуын уйлап йөрим дә, андый кешеләр күбрәк булсын иде дип телим. Ә ничек шулай булган соң

дип уйланам да, Бакый фикере белән килешәм — ул бит тормыш сабагы алган.

Әткәй 1899 елны, гасыр кичкәндә дөньяга килгән һәм илдә булган һәр үзгәрештә аның эзе калган. Ул Гражданнар сугышында озак була: Себердә Колчакка каршы, Урта Азиядә басмачларга каршы көрәшә, сул кулындагы ярасыннан тыш, ул елларның сугыш авырлыгы — ачлык һәм хәерчелектән туган "цинга" (зәңгелә), тиф, бизгәк авырулары аны берничә мәртәбә фани дөньядан алып китә язып кала. Әмма көчле рух, әллә инде яшәү бәхетеме җиңә — исән кала. Бервакыт үлекләрне җыеп күмә торган чокырда эшләүче кеше: "Бу бәндә яшәргә җыена түгелме?!" — дип, аралап ала аны. Гражданнар сугышы беткәч, Донбасс шахталарында күмер чаба, татарларны яклаучы батыр шахтер булуы турында күңелле истәлекләре бар. Шулай бервакыт шахтерлар арасында татарларны кимсетү башлана. Татарлар сан ягыннан күп, әмма ялланып эшләргә риза булып килгән гади шахтер егетләр үзләрен сакларлык, акларлык дәрәҗәдә кыю булмыйлар, ахры. Шунда Зыя Шәймулласы дөреслекне үзенең кулы белән аңлатырга мәҗбүр була. Тавыш башын оештыручының җилкәсе, әткәйнең биш бармагының да эзе төшеп, икенче көнгә кара күеп чыга. Бу инде "татар печате" дигән һәркем өчен гыйбрәтле бизәк була.

Уралда һәм Себердә алтын приискасында, Мәскәүдә метро төзелешендә эшли әткәй. Эшләгән һәр җирендә мактала бара. Мәскәүдә калдыру өчен фатир да вәгъдә итәләр, әмма авылда әтисе Зыя бабай аның кайтуын көтә. Авылга кайткач, бригадир була, Казанда алты айлык совет-хуҗалык хезмәткәрләре курсында укып кайта. 1941 елда колхоз рәисе булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнашып, бер аяк һәм ике таяк белән туган авылына кайта. Ә сугыш еллары авылы кәгазьгә язып бетерә алмаслык хәлдә — ачлык, ялангачлык һәм ятимлек. Шулай да сугыш кырында калган сул аягын агачтан үз куллары белән "ясап", тагын бер таяк ярдәмендә йөрергә өйрәнә. Колхозны (ул вакытта "Көрәш" колхозы иде) җитәкләү эшенә алына. Сугыш беткәч тә шул сыңар аяк һәм бер таяк белән авылдан авылга җәяүләп йөреп, налог агенты булып эшли. Әмма беркайчан, хәтта агач аяк сөякләрен кырып канатканда да, зарланмый, "хәзер аңа — җәрәхәткә — кара май сөртәбез — тазара ул", дип юана иде. 1950 елдан — Карадуганда укыта башлаган вакыттан ишетеп килә идем, авылның авыр хәлдә калып тиешле налогын түли алмаучылары әткәйгә: "Рәхмәт инде, Шаһимулла, хәлебезне аңладың, авыр сүз әйтмәдең, район хуҗаларына безне әләкләп,

кәнсәләргә чакыртмадың, өйгә тикшерүчеләр китертмәдең", — дияләр иде.

Ата үз урынында булган, ана үз урынын белгән төпле татар гаиләсе иде минем яңа гаиләм.

Мин шундый батыр йөрәкле, киң күңелле ата кешенең олы улы Бакыйга кияүгә чыгып, шушы йортка тугызынчы кеше булабрак — килен булып төштем. Мең шөкер, инде менә ярты гасырга якын бергәбергә яшибез. Өч бала үстердек (алар өчесе дә югары белемле), өчесе дә үз гаиләләре белән яшиләр. Ә без төп нигездә Булат улыбыз һәм киленебез Фираяның балаларын үстерешеп, матур гына гомер итәбез.

Олы кызыбыз Нурия Казан медицина институтын тәмамлап, бүгенге көндә югары категорияле табиб булып Казанда эшли, балалары Нәҗия һәм Фирүзә — уку алдынгылары. Әтиләре Наил хәрби хезмәттә — подполковник. Икенче кызыбыз Чулпан Казан дәүләт университетының математика факультетын тәмамлап, Казан шәһәрендә математика укыта. Татарстан таможнясында эшләүче ире Марсель белән ике ул — Мансур һәм Надирны үстерәләр.

Улыбыз Булат Казан Авыл хуҗалыгы академиясенең агрономия факультетын тәмамлады, "Игенче" күмәк хуҗалыгы рәисе булып эшли башлады. Киленебез Фирая югары белемле укытучы, Карадуган мәктәбендә тарих, татар теле укыта.

Мәрхүм әткәй, урыны оҗмахта булсын, Бакый өйләнү ниятен әйткәч, күп еллар тарткан тәмәкесен (мин килгәндә аңа 56 яшь иде) ялт кына итеп ташлаган. Заманына күрә укымышлы, үткен фикерле кеше иде әткәй. Көндәлек матбугаттан тыш, революциягә кадәр чыккан китапларны укып, әчтәлеген әнкәйгә сөйли торган иде. Аяз матур көннәрдә шул агач аягы белән дә йөрергә ярата. "Ләмига, мин тәтәгә барып кайтыйм", — диеп, Хәсәншәехка җәяүләп китә торган иде. Икенче бервакыт: "Менә бу китапта "кыз туганыңның хәлен бел, вакытың тар булса, морҗасы-

на булса да сәлам биреп кит" дип язган, мин Юдинога барып, Нурлыходаны (сеңлесе) күреп кайтыйм әле", — дип, шәһәргә китәр иде. Бүген уйланып исем китә — 1955-1960 елларда Таузар иленнән Юдинога барып җиту өчен махсус транспорт юк, ничекләр йөреп бетерә иде икән ул аны. Һәрчак шат күңелле, кыңгыраулы яшел гармунын уйнатырга ярата иде. Берчак шулай әткәй 1955 елның көзендә бик нык авырып китте, үзе: "Мин өйдә генә торам", — диеп, ике көн больницага бармады. Инде хәл уңайланмагач, больницага бардык. Хирург Зарипов Камил яшь булса да, инде тәҗрибәсе, тәвәккәллеге җитәрлек, әмма дәвалау авыр бара. Әткәй: "Камил энем, пычагың бардыр бит, әчеп карыйк әле шушы эчне — нәрсә бар икән шунда мине борчырлык..." — дип, үзе кушып, операция ясата. Ачкач күрәләр, чыннан да, бөтен хикмәт эчәкләрдә була. Дәвалыйлар, әткәй савыгып кайта.

Әткәй үзенең җәмәгате белән (миңа әнкәй иде ул) алты бала тәрбияләп үстерәләр, аларның дүртесе егет, икесе кызлар — шуларның һәрберсе үз гаиләләре белән яшиләр, бишесе югары белемле. Һәрберсе үз белемнәре буенча һөнәр ияләре, хезмәтне, дөньяны, тормышны яратып яшиләр. Инде әткәйнең оныкларыннан — Азат улы Нариман, Илгиз кызы Нәфисә фән кандидатлары, Азат кызы Гөлнара чит телләр (инглиз теле) буенча белгеч, унбер оныгының унбере дә югары белемле.

Мин өстән-өстән генә язгалап, академик Азат Зыятдинов туган һәм торган җирлекне аңлатырга тырыштым. Азатның үз тормышы сукмагын белү бүгенге яшьләр өчен тагын да кызыклы булыр кебек. Белгәнемчә, күргәнемчә язам, чөнки Азат белән апасы Фәнияне мин математикадан укыттым да әле. Азат татарның танылган әдипләре — шагыйрь һәм чәчмә әсәр язучылары, композитор һәм атаклы рәссамнары белән тыгыз элемтәдә яши. Аның Фәннәр академиясенә сайлануын ишетеп, телефоннан котлап сөйләшкәндә Азат үзенең яраткан шагыйре Наҗар Нәҗми сүзләре белән әйтеп куйды, янәсе...

...бары да соңлап килде миңа,
язмыш йөреде гелән шаяртып.

"...Миңа бары да соңлап килде..."

Әйе, энем, син бик түбәннән — тормышның төбеннән бары үз көчең белән күтәрелеп зур галим булдың. Авылдашларыбыз сүзендә дә хаклык бардыр. Янәсе, "абыйсы укытучы булгач, бары да китапка ябышты, укыйлар да укыйлар". Чөнки халыкта бит "оясында ни күрсә..." дигән әйтем дә бар. Бакый балаларның

барысына да абый, гаиләдә өлкән балага әти-әни теләге белән зуррак бурычлар йөкләнә. Сугыштан соңгы авыр елларда укып, 1950 елны институт тәмамлагач, Бакый Балтач районына физика-математика укытучысы итеп җибәрелә. Ике ай гына Карадуган җидееллык мәктәбендә укыта да, аны Балтач урта мәктәбенә математика укытучысы итеп күчерәләр. Балтачка, элек үзе укыган урта мәктәпкә укытырга күчүне Бакый зур җаваплылык хисе тоеп, теләп кабул итә. Чөнки анда

Бакый Зыятдинов Балтачтагы дуслары белән: Габделфәт Вәлиев, аның апасы Мәдинә, сабакташы Вагыйз Кәримов.

аның өчен үрнәк булган, үз фәннәрен яратучы, көчле характерлы, үз эшенең остасы булган Закиров Габделхак Закир улы җитәкчелек итә иде. Балтачта эшләгән еллары Бакыйның дөньяга карашын киңәйтә, характерын тагын да ныгыта. Укытучылар коллективының уңай йогынтысына үзенең яшьлек куәте иш булса, район күләмендә зыялы кешеләр — Вәлиева Мәдинә апаларда фатирда торуы аңа нур өстенә нур дигәндәй, бүгенгәчә хәтерендә саклана, үзенә яхшылыклар өсти. Чөнки Вәлиева Мәдинә апа, аның сеңлесе Рәйсә һәм Миңнегөл апалар, энесе Габделфәрт һәм Габделбәр белән Балтач мәктәбендә укыган елларыннан ук таныш була Бакый. Габделфәрт белән бер класста укып, урта мәктәпне бергә тәмамлыйлар. Алай гына да түгел, классташ егетләр Казан югары уку йортларына да бергәләп барып, төрле ВУЗларга керәләр. Югары уку йортларын тәмамлагач, язмыш сабакташларны төрле сукмаклардан йөртә, ә классташ дусты Габделфәрт белән аларның фикерләре, дөньяга карашлары гел дә бердәй үрелеп үсә. Инде Габделфәрт химия өлкәсендә кыйммәтле ачышлар ясаган зур галим, СССРның Дәүләт пре-

миясе лауреаты, шулай да алар гел бергә. Бакыйның характер ныклыгы формалашуда дустының да өлеше булгандыр. Хәзер дә гаилә дуслыгы дәвам итә, инде балалар да бергә ярдәмләшеп үстеләр. Эчкерсез дуслык оныкларга да ирешеп бара. Бакый үзлегеннән күп укый, дөньяви фәннәрне, илнең эчке, тышкы сәяси һәм икътисадый хәлләрен, матур әдәбиятны һәм халкыбызның мәдәни үсешен, мәгърифәтчелек, укыту-тәрбия мәсьәләсендә бөек педагогларның хезмәтен өйрәнә һәм аны үзебезнең шартларда куллану проблемалары өстендә армыйталмый эшли.

46 ел укытучылык хезмәтенең 35 елында Кенә һәм Карадуган урта мәктәпләрендә директорлык эшен алып барды ул. Оста педагог һәм оста җитәкче, "Татарстанның атказанган укытучысы", "РСФСРның атказанган укытучысы" исемнәренә лаек булды. Гаиләдә исә — көчле характерлы гаилә башлыгы. Балалар әтиләренә ихтирам белән карап, хөрмәт итеп яшиләр. Укыткан укучыларының Бакыйга ихтирамы, шушы җирлектә яшәүче халыкның хөрмәте, гаилә җылысы, Аллага шөкер, Бакыйны яшь чактагы көч-гайрәте һәм дә яшәү өчен зур теләге белән яшәтә — картайтмый.

Бүгенге көндә ул инде күп еллар элек башлаган эшен дәвам итә — шушы тирәлекнең, туган ягыбыз халкының тарихын өйрәнә. Беркайчан вакытны бушка үткәрмичә, өйрәнәсе тарихның зурлыгын аңлап, үз планы буенча эзләнә, яза, аңлата. Ә мондый туганың булу, минемчә, шатлык кына түгел — бәхет ул.

Менә шушы "укымышлы абый"ның уртанчы энесе иде Азат. Ул укырга кергәндә I класска сигез яшьтән алалар иде. Бик укыйсы килеп укый башлый Азат. Әмма аннан кече энесен карар кеше булмый. Азатка: "Киләсе елга шушында ук килеп укырсың, улым", — диеп аңлата-аңлата бер елга бала карау эшен тапшыралар. Инде Карадуган җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Казанга барып уку өчен иркен итеп рус телендә сөйләшергә өйрәнергә кирәклеген үзе аңлап, тагын бер ел күрше авылда җиденче классны рус мәктәбендә кабатлап укый. Шуннан соң 1955—1959 елларда Казан технология техникумында белем ала. Тулай торак юк, төрле урыннарда табылган фатирларда яшәү шартлары бик начар.

Еллар үтә тора, техникумны тәмамлау дипломы белән армия хезмәтенә чакыру кәгазе бергә килеп төшә. Азатның өч елы армия хезмәтендә үтә. Ул елларда Казан авиация институтында уку һәм "космос" дигән серле биеклек яшьләрне үзенә тарта иде. Азат, космонавт булу теләге белән документлар туплап

җибәрә, әмма татар егетенә исемлектә урын калмаган. Армиядән туры КАИга кайтып керә, студент еллары башлана. Студент елларын Азат аерым бер рухлану белән сөйләргә ярата. Укуның тәмен белгән, яшәүнең ямен белә башлаган, үзен-үзе карарга тиешле яшькә җиткәнен аңлаган егет эшли-эшли укый: урам да себерә, вагон да бушата.

Еллар үтә, яшьлек хисләре үзенекен итә: өйләнү, гаилә һәм яшәү өчен нигез кору, эшкә урнашу мәсьәләләре килеп баса. Шулай итеп, инде ике төрле һөнәр өйрәнүдән алган каты тышлы дипломнар бар, тормыш та үзенең төрле кырларын күрсәтергә өлгерде, чын-чынлап кешечә яшәү өчен көрәш башланды.

Түбән Кама нефтехимия комбинатына эшкә барып урнашкач, нәкъ менә шул көннәрнең "кадагы" булган химия һәм аның могҗизаларын өйрәнергә кирәк булып чыга. Азатка туганнары аның кечкенә вакытта елак булуын искә төшергәлиләр иде. Ә ул кызык кына итеп: "Мин бәбәй вакытта елыйсын елап бетергәнмен", — дип көлеп куя. Бу аның бүгенге көндә зарланып яшәүчеләргә урынлы гына кинаясе булып та аңлашыла иде. Чөнки ул бервакытта да зарланмый, эшендә уңайсызлыклар килеп чыкса да, гаепне башкалардан күрми, нигезле сәбәбен ачканчы эзләнә, күңелен төшерми. Һәрчак алга карап яши. Алдына куйган максаты, киләчәккә хыяллары белән шапырынырга да яратмый, тыныч кына көн-төн эшләп, тырышып укый, эшли.

Химия комбинаты, бер карашка, торбаларыннан ут-ялкын чыгарып өнеңне алырдай булып күренсә дә, Азат бер дә авырсынмыйча химияне яңабаштан нигезле итеп өйрәнергә керешә. Яшьлек ялкыны комбинат төтеннәреннән яктырак, өметлерәк була. Шәхсән үзенең кешеләр белән аралашучан һәм акыллы, сабыр карашы белән чын дусларны тиз танучан булуы аңа гел дә ярдәм итә. Химияне өйрәнүдә дә Әнвәр абыйсы кебек эчкерсез укытучы-остазга юлыга.

Ул вакытта әле яшь шәһәр Түбән Камага Азат яңа бер гаилә булып, өйләнеп китте. Ул үзе кебек укымышлы (югары белемле математика укытучысы) күрше кызы Сания белән туй үткәреп, Түбән Каманың үзенеке булу өчен китте. Алар барып урнашканда шәһәр әле төзелә генә башлаган: эшчеләр өчен бер ашханә, "Юность" дигән галантерея кибете һәм биш катлы дүрт-биш торак йорт (аның да берсе яшьләр өчен тулай торак санала) бар иде.

Эшкә чын күңелдән бирелгән Азат андагы җитәкчеләр алдында тиз арада абруй казана, аңа яшь белгечләр белән эшләүне тапшыралар. Ул яшь белгечләр советының рәисе буларак, эшкә

килгән яшьләрнең яшәү шартларын кайгырта, аларга шушы шәһәрнең үз кешеләре булып яшәрлек рухи һәм икътисадый ярдәм оештыра. Ә хатыны Сания яңа ачылган техникумда математика укыта башлый. Күп еллар шушы шәһәрдә яшьләрне тәрбияләү өлкәсендәге хезмәтләрен бәяләп, Саниягә "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән исем бирелде. Шулай итеп, яшь шәһәрдә аңа килеп урнашкан яшьләр дә үсә. Азат та хезмәт баскычы буенча тиз күтәрелә, химияне нигезле үзләштерә. Мәскәүдә аспирантурада укый һәм химия фәне буенча Мәскәүдә кандидатлык, аннан соң докторлык диссертациясен яклый. Үзе өйрәнә торган тема буенча эшен җәелдерә, махсус лаборатория булдырып, яңадан-яңа ачышлар ясый. Ул ачышлар шунысы белән кыйммәт, барысы да күп кенә химкомбинатларда файдалы эшкә — җитештерүгә кертелә бара. Фәнгә, химия могҗизаларына колагыннан чумса да, Азат шәһәр тормышы белән бергә яши. Комбинат эшчеләренең сулышын тоеп, алар белән якыннан аралашып, эчкерсез ярдәмен ирештереп бара. Иң беренче ул яшь язучылар берләшмәсенең киңәшмәләрендә катнаша башлый. Аның үзен яшь язучыдыр диеп уйлыйлар. Ә Азат берләшмәнең эшен өйрәнеп, уйланып йөри. "...безгә язу өчен шартлар җитми..." дип зарлануларын озак тыңлый алмый, бераз уйланырлар диеп, үзе сорау куя: "...безнең Тукаебызга шартлар нинди булган, ә?" Еллар үткәч, кайберләре әлеге сорау өчен Азатка рәхмәт белдерә.

Яшь язучыларны илһамландыру, дәрте булганнарга тагын да үсеш өчен, халыкка рухи һәм милли тәрбия өчен "Җидегән чишмә" дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәләр үткәрә башлыйлар. "Җидегән чишмә" кичәләрен оештыру советында Рахмай Хисмәтуллин кебек үткен телле язучылар, Наил Нуретдин кебек театр белгечләре режиссерлык итә, матди яктан Мәсгут ага Сибгатов барлык мәшәкатьләрне үз өстенә ала. "Җидегән чишмә" кичәләре халыкка милли һәм рухи азык бирүдә, халыкның күңел хисләрен баетуда әйтеп бетергесез зур эш башкара. Ул кичәләр турында Рахмай Хисмәтуллинның 4000 данә тираж белән чыккан "Кыйбла җиле" дигән хезмәтендә киң күләмдә яктыртылган. Ул китапта бик матур истәлекләр тупланган. Татар халкының әдәби-музыкаль җәүһәрләрен тагын да үстерүче күренекле язучы, рәссам һәм артистлар белән очрашулар бик җанлы һәм җылы, күңелдә гомер буе сакланырлык итеп үткәрелә. Чакыру кәгазе һәм билетларына түбәндәге сүзләр языла:

Яшәү өчен, яшьнәр өчен
Җыр кирәк дигәннәргә,

Тукай шикелле өзелеп,
Үз моңын сөйгәннәргә,
Ут дәртле, очкын күңелле
Яшьләргә, өлкәннәргә
Багышлана ял кичәсе!
Үзебезнеке һәр нәрсә:
Уйнагыз да көлегез дә
Һәм бераз уйланыгыз —
Буыннардан-буыннарга
Килгән чал моңнарыбыз
Маяк булсын, нурлар сипсен
Гомер юлларыгызга.
Васыять булып күчеп калсын
Кыз һәм улларыгызга!

Ул кичәләр берсе дә алдагысына охшамаган. Ә геройлары — күренекле шәхесләр: Гомәр Бәширов, Сибгат Хаким, Наҗар Нәҗми, Мөхәммәт Мәһдиев, Сара Садыйкова, Фәридә Кудашева, Бакый Урманче, Рөстәм Яхин...

Шәһәр яңа төзелә торган үсеш чорын кичерә, килеп эшкә урнашучыларның төрле милләттән булуы да исәпкә алына. Кичәнең темалары керәшен татарларының,чуваш һәм рус халкының күренекле кешеләренә дә багышлана. Шәһәр бизәлеше, балаларның киләчәге, милләтара татулык, яшьләр тормышы буенча гел алга таба матур-матур үзгәрешләр булып тора. Шәһәрдә Габдулла Тукайга һәйкәл куйдыра алуына да куана Азат, шәһәр эчендә мәчет өчен урын билгеләтә алу, үзәк урамнарның берсенә Бакый Урманче исемен кушу, иң яхшы мәктәп бинасында татар гимназиясе ачу кебек барлык яшәүчеләр өчен хуп күрелә торган гамәлләр — аның куанычлары. Әйтик, Татарстанның Югары Советы депутаты буларак (1990—1995 еллар чакырылышында) Азат Зыятдинов халкыбызның милли азатлыгы өчен көрәште. Сессия утырышларында республикабызның суверенлыгы, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе өчен эшлекле тәкъдимнәр белән чыгышлар ясады, аның фикерләре күпчелекнең яклавын тапты.

Әдәбият, сәнгать кешеләренә ихтирамы аеруча зур. Һади Такташка тиешле игътибар юклыгына борчылып, Такташ эзләре буйлап эзләнүгә алынды. Ике мәртәбә (улы Нариман белән) Тамбов урманнары арасына — Сыркыды авылына сәяхәт ясады. Шагыйрь турында кызыклы материалларны матбугатта яктыртып баруы шигъри җаннарга дәва булды кебек. Азат үзе дә шигъри җанлы. Яраткан шигырьләрен күңеле ямансулаганда

яки шатлыклары ташып торганда сәнгатьле итеп яттан укырга ярата, илһамланып китеп үзе дә язгалый.

Түбән Кама нефть-химия гигантының фәнни-технологик үзәге директоры булып эшләүче, "Татарстанның атказанган химигы" исеменә лаек булган энебез Азат инде — академик. Бу бит мин яки башка туганнары яратканга күрә биргән бәя түгел, ә Татарстан академиясендәге барлык галимнәр биргән бәя! Ишетеп, телефоннан котлаганда: "Ничекләр өлгерәсең, кайлардан шулай көч табасың?" — дип, сокланулы соравыма, ул һич тә уйланмыйча, ышанычлы итеп: "Авылдан, туган апа!" — диде.

Азат Зыятдинов мәйдан тоткан елларында.

Чыннан да, Азат авылны бөтен барлыгы белән, ягъни ничек бар — шулай ярата. Инде биш-алты ел аның эштән китеп ял иткәне юк, ә шулай да бер кичләп булса да авылга кайтып килергә ничек тә җай таба. Күршедә генә яшәгән сабакташ дусты Фәргать белән кулларына тальян алып, авыл урамнарын шаулатып җырлап әйләнәләр, авыл сабантуйларында егет чакта көрәшеп көч сынашканы, хәтта Балтач сабан туенда беренче батыр калганы да булды. Авыл сабантуйларын, аның кунакларын, болыннарын чын ярату белән ярата. "Шул сабантуйлар миңа бер еллык яшәү көче бирә, дәрт өсти", — дип куана ул. Үзгәрешләр барган елларда базар мөнәсәбәтләренә авыл хезмәтчәннәре йомшак керә алмадылар гына түгел, гранит кыялардай катылыкка бәрелделәр. Авыл халкының эчкерсез күңелендә авыр кичерешләр бара. Ә Азат безне, авыл халкын, шул кичерешләребез, дөньяны аңлап җитмәүдән туган борчуларыбыз белән тулаем үзенеке итеп ярата. "Барысы да яхшы булыр, сез туган туфракта яшәүче саф күңелле, җирле, бай халык, өстәвенә, үзегезгә ничек җайлы, шулай үзгәртә аласыз, бераз кыюрак булыгыз!" — дип, төшенкелеккә бирелмәскә чакыра.

Менә Зыятдин улы Шәймулла белән Муса кызы Ләмига гаиләсендә тәрбияләнеп үскән алты баланың икесе турында бераз

белешмә булды. Бу икесе генә түгел, калганнары да сугыштан соңгы авыр елларда юкны бар итеп, тартып-сузып җиренә җиткереп, тырышып эшләү һәм тәрбияләү белән кеше ителгән балалар.

Сугыштан соңгы елларда авылда яшәп, биш балага югары белем алырлык мөмкинлек тудырган әти-әниләргә мең-мең рәхмәт!

Икенче уллары Сәйдәш Днепропетровск шәһәрендә металлургия институтын тәмамлап, инженер булып эшләде. Өченчесе булып туган сеңлебез Фәния, үзе кебек кече күңелле Арча егете Наилгә кияүгә чыгып, матур тормыш кордылар. Арча станциясендә урнашкан әлеге Фәния + Наил яши торган йорт безнең барыбыз өчен дә икенче төп йорт кебек булды. Аларга бару, хәтта кереп кенә чыгу сыман кыска гына арада күрешү дә күңелле була иде. Чөнки Фәния үзе дә, ире (кияү) Наил дә туганнарын, авылдаш дусларын бик якын итеп яшәделәр. Наил инде вафат, урыны оҗмахта булсын, диябез. Фәния сеңлебез әлеге йортны элеккеге җанлылыгында тота, барыбыз да аңа рәхмәтлебез.

Кече энеләре Илгиз химия-технология институтын тәмамлаган инженер, Түбән Кама нефть-химия комбинатында эшли. Хатыны Гөлзәрия балалар бакчасында өлкән тәрбияче, кызлары Нәфисә — химия-биология фәне буенча фән кандидаты, уллары Нияз төзүчеләр институтын тәмамлап килә, киленебез Лилия Түбән Кама мәктәбе һәм институт филиалында математика укыта.

Иң кече сеңлебез Тәэминә — югары белемле табиб, юридик факультет тәмамлаган милиция хезмәткәре Ягъфәр белән ике егет, бер кыз тәрбияләп үстерделәр. Кызлары Алсу әнисе, кече уллары Газинур әтисе юлыннан китте, ә олысы Илнур компьютерлар буенча югары белемле белгеч булды.

Әнкәй (минем каенанам) Таузар иленең оста куллы кешесе — Муса бабай кызы була. Ничек бөтен осталар, укымышлы кешеләр Таузарда гына туды икән дип уйлаучылар да булыр. Мин һич каршы түгел, уйлагыз, уйланыгыз. Бу язмамны укый алган һәрбер кеше үз авылының энҗе бөртекләрен эзләп таба алса, безнең балаларыбыз өчен нинди горурлык булыр иде! Моннан, ягъни үзе яшәгән бу көннән, түгәрәкләп кенә әйткәндә, бер гасыр элек яшәгән бабаларыбыз төрле-төрле һөнәрле, киң күңелле, рухи яктан бай кешеләр булган бит, ә нигә әле безгә калышырга?

Муса бабай (1850—1920 елларда яшәгән) янәшә-тирә авыллардагы су тегермәне өчен кирәкле эчке җиһазны имән агачыннан ясый торган сирәк һөнәр иясе була (ягъни тегермән куласасы ясаучы Муса). Хәтта ул үзе өчен скрипканы да үзе ясап уйный.

Бүген аның кызы Ләмиганың балалары турында яздым, ә Муса бабайның Бибиәсма исемле кызы — бүгенге көндә безнең күңелләрне бизәүче "Сөембикә" журналының баш мөхәррире Фирая Бәдретдинова һәм "Шәһри Казан" газетасының хатлар бүлегендә эшләүче Резеда Бәдретдинованың әбиләре була.

Мин килгәндә каенанам 50 яшендә, соңгы ике бала мәктәп укучылары иде. Һәр баласын мәктәпкә зур игътибар белән хәзерләп, уку кирәк- яракларын кулына тоттырып, изге теләкләр теләп озатып калуына соклана идем әнкәйнең. Укытучы кеше буларак, барлык балаларның да әниләре шулай булса иде дип кызыгып күзәтә идем.

Халыкта берәүләрнең уңышлы тормыш юлын күрү белән: "Аңа ничектер җай чыкты", — дип нәтиҗә ясау гадәте бар. Азатның академикка кадәр үткән юлын ваклап язуымның сере шунда — җай чыгу түгел, ә максатчан тырышлык нәтиҗәсе ул. Техникум тәмамлап, армия хезмәтенә киткәндә фотоальбом бүләк итеп, аның тышлыгына түбәндәге теләкне язып җибәргән идек:

Каушама, һич зарланма син,
Авырлыклар туса да.
Барып егыл максатыңның
Капкасына булса да!

Тырышлык бушка китми, рәхмәт аңа!

Таузар авылының икенче академигы — Фаил Әхмәдиев үткән юл да бик үк шома түгел. Билгеле, Әхмәдиевлар турында сүз чыкса: "Әйе, ул Әхмәдиевлар барысы да башлы, барысы да югарыга тиз үрләделәр", — диеп сокланып әйтеп куялар. Биек үрләр җиңел бирeләме соң?

Әухәдиев Әхмәдине Таузар халкы хөрмәт һәм рәхмәт белән искә ала.

Аларның бабалары Әухәдиев Әхмәди 1944—1952 елларда Таузарда тегермәнче булып эшли. Сугыштан соңгы елларда шул ук тегермән бөясен электр энергиясе алырлык итеп үзгәртәләр. Сүз уңаеннан, бу эшләрдә, нигездә, Таузарның үз халкы, үзенең төзелеш осталары эшли: Хөсәен Хәсәнов, Зиннәт Гыйззәтуллин, Хәбибрахман Хөсәенов, Габделхәй Йосыпов, Хабибелхак абый Гыйззәтуллиннар.

Электростанция төзелешендә эшләгән Хаҗиев Мөдәррис әйтүенә кара-

ганда, электростанция бинасының нигез баганаларын 1949 елны утыртканнар. Ә баганалык агачларны Хаҗиев Мөдәррис апасы Хаҗиева Факия белән Югары Кенә аша урманнан үгез җигеп (урманда атлар тарта алмаслык була) алып кайталар. Станция төзелешендә прораб — Герман исемле кеше (фамилиясен хәтерләмиләр), беренче монтёрлар — Нәҗип, Гриша һәм Таузар кияве (Хаҗиева Сәйдәнең ире) Билалов Мәхсүт.

Әхмәди абый җәмәгате Фәрзәнә апа белән өч ул һәм ике кыз тәрбияләп үстерәләр: Шәмсеруй апа 1924 елгы, Габделбәр — 1926, Раузит — 1931, Мөзәйнә — 1934 һәм Рәшит — 1939 елгылар. Шәмсеруй апа сугыштан соң Яңгул егете Вәлиев Мәлик белән гаилә корып Яңгулда яшәп калалар, сигез бала (ике егет, алты кыз) тәрбияләп үстерәләр. Олы уллары Габделбәр һәм хатыны Рәйсәнең балалары алтау: Фәрит — 1947, Фаил — 1950, Наил — 1953 елгы, әлеге өчесе Таузарда туалар; 1954—1955 елларда гаилә Рәйсәнең туган авылы Яңгулга күчеп яши башлый. Анда Марат, Мәдинә, Ринат дөньяга киләләр. Шулай итеп, Габделбәр абыйның гаиләсе Яңгулда яшәп кала. Тик мәрхүмнәр кыска гомерле булалар: 1976 елны әниләре Рәйсә, 1982 елда әтиләре Габделбәр дөнья куя. Тырыш балалар үстереп калдыралар алар, урыннары оҗмахта булсын дип телик. Габделбәр абый Бөек Ватан сугышында бер күзен югалтып, беренче группа инвалид булып кайткан. Алты баланың бишесе ир бала булу — әти өчен куаныч та, үстереп кеше итү бурычын үтәүдә зур җаваплылык та. Габделбәр аганың балаларына карата гадел таләбе һәм әниләренең хәер-догасы да ирешкәндер, малайлар, тулы мәгънәсендә, ир-егетләр булып үсеп җитәләр. Әтиләре кушканча, авырлыклар алдында югалып калмаска, көрәшергә һәм җиңәргә өйрәнеп үсәләр. Габделбәр ага шахмат уйнарга ярата, көрәшә дә — димәк, малайларга әтиләренең иң кирәкле сыйфатлары күчкән дигән сүз. Габделбәр абыйның өч улы — Фәрит, Фаил, Марат татарча көрәш буенча спорт мастерлары һәм республика ярышлары батырлары.

Рәйсә апа һәм Габделбәр ага Әхмәдиевләр гаиләсенең түгәрәк чагы. Бу балаларның һәркайсы илгә-көнгә игелек итәчәк әле.

Район, авылларында татарча көрәштә катнашып, ярышларның абруен күтәрүче һәм көрәшчеләрне хәзерләүче остазлар да.

Олы уллары Фәрит Казан дәүләт университетының механика факультетын тәмамлый һәм әйтергә кирәк, кече туганнарына югары белем алу өчен юл күрсәтүче була. Университет тәмамлаганнан соң, Казанда "Вакуummаш" фәнни-тикшеренү институтында инженер булып эшли. 1976 елда туган районына — Балтач мех фабрикасына баш инженер булып кайта. Промкомбинаттан аерылып чыккан элеккеге мех эшләү артелен мебель фабрикасы итеп үзгәртү өчен зур оештыру һәм төзелеш эшләре башкарган Хафизов Әүхәдишаның фаҗигале вафатыннан соң, яшь, энергияле егет Әхмәдиев Фәритне Карадуган мебель фабрикасына директор итеп куялар. Бу як авыллары халкының тормышы өчен зур әһәмияткә ия булган мебель фабрикасы эшен тагын да үстерү өчен Фәрит үзенең бөтен көчен биреп эшли. 1988 елгы зур янгын фабриканың киләчәк язмышын зур сорау астына куя. Ләкин Әхмәдиев Фәрит җитәкчелегендә фабрика коллективы бу афәтне җиңеп чыга, фабрика яңадан тулы куәтенә эшли башлый. Шуның өстенә фабрикада теплица, дәвалау үзәге төзелә. Фабрика ат үрчетү белән дә шөгыльләнә, аның атлары район сабантуйларында гына түгел, республика күләмендәге ярышларда да призлы урыннар ала, иң мөһиме — балаларга да "ат җене" кагыла, алар атларны бик яраталар һәм йөртүчеләр (жокей) дә — балалар үзләре, ә бу үзе бер тәрбия чарасы. Әхмәдиев Фәритнең хезмәтләре югары бәяләнде: ул "Дуслык" орденына лаек булды, балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә зур ярдәме өчен "Россиянең халык мәгарифе отличнигы" значогы белән бүләкләнде, шулай ук "Татарстанның атказанган җиңел промышленность хезмәткәре" исемен йөртә.

Фәрит районыбызда күп җәмәгать эшләре дә башкара. Ул "Татар-башкорт көрәше" җәмгыяте, "Аучылар җәмгыяте" һәм ат спорты федерацияләренең рәисе дә.

Тик соңгы вакыттагы үзгәрешләр — "кыргый" капитализмга күчү 1988 елгы янгыннан да хәтәр булып чыкты, ул фабриканың киләчәген бик авыр хәлгә куйды, димәк, безнең төбәкнең шунда эшләгән йөзләрчә кешесенең язмышы кабат сорау астында.

Габделбәр абыйның икенче улы Фаил фәннәр өлкәсендә үсештән-үсешкә барып, академик дәрәҗәсенә иреште. Казанның югары уку йортларында укытуын, озак еллар Казан шәһәре мэры Камил Исхаковның ышанычлы урынбасары булып эшләвен, хәзер кабат югары уку йортына килүен — Казан дәүләт пе-

дагогика университеты проректоры булуын әйтсәк, аның көндәлек эш-гамәлен күз алдына китереп булыр. Фаил дә этисе шикелле тәвәккәл, һәр эшне җиренә җиткереп эшләүчән. Аңа "Татарстанның атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде. Ул фән һәм техника өлкәсендә Татарстан республикасының дәүләт бүләге лауреаты. Бу эшләр белән бергә Фаил актив җәмәгать эшлеклесе дә: Казан шәһәр Советы депутаты, милли көрәш буенча Казан шәһәр федерациясе рәисе, "Фән һәм тел" журналының баш мөхәррире...

Биш ир малай арасында үскән кыз туган Мәдинә Казан шәһәрендә математика укыта.

Әхмәди абый, оста тегермәнче буларак, башка тегермәннәргә күчкәләп йөри, җәмәгате Фәрзәнә апа Таузарда — икенче улы Раузитларда яши. Кызы Мөзәйнә Арча педучилищесын тәмамлап укытучы була. Кече улы Рәшит районда коммуналь хуҗалыкта эшли. Фәрзәнә апа мәрхүмә булды инде, Таузар зиратына җирләнде — урыны оҗмахта булсын. Фәрзәнә апаны тәрбияләп, соңгы юлга озатучылар улы Раузит белән килене, Таузар кызы Әминә булдылар. Алар — төп нигезне саклаучылар. Шуңа да Әхмәдинекеләр Раузит белән Әминәне хөрмәтләп яшиләр. Раузит махсус курсларда укып, электромонтер буларак, радиоузел эшенә дә булышты. Алдынгы комбайнер буларак, "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнде. Күп еллар йөк машинасында шофер булып эшләде. Хәзерге көндә Әминә дә, Раузит та лаеклы ялда, балалары һәм оныкларының игелеген күреп, матур гына яшиләр.

Академиклар үстергән Таузар иле турында язмамны алга таба да дәвам итмәсәм, авыл халкының төп сыйфатлары ачылып бетмәс кебек.

Сугышка кадәр бу авылның (өч бригада) "Көрәш" колхозында фәкать үз авылы кешеләре генә рәислек итә. "Көрәш" колхозы һәр тармак буенча алдынгы була. Шуңа ул авылның алдынгылары башка колхозларга җитәкче кадрлар итеп җибәрелә. Гомумән, җитәкче кадрлар үстерүе белән дә горурлана ала таузарлылар: Касыймов Таһир — Балтачта райком секретаре һәм Буденный районында район Советы башкарма комитеты рәисе, Яппаров Якуп, Хәкимов Мәгъсүм, Әхмәтов Җәләй, Хәлиуллин Рәис — Арбаш авылы Советы рәисләре, Зыятдинов Гомәр, Гыйльметдинов Фәттах — Карадуганда колхоз рәисе булып эшлиләр. Шәяхмәтов Каюм — Субашта авыл Советы рәисе (әтисе Шәяхмәт бабай сәнәк сугышында һәлак булган комиссарның исән калган улын умарталыкта сыендыручы),

Зәкиев Зәкәрия — Карадуган мебель фабрикасында цех начальнигы һәм соңыннан фабрика директоры була. Яппаров Ягъфәр, Зыятдинов Бакый — мәктәп директорлары һәм икесе дә — "РСФСРның атказанган укытучысы". Сафин Фаяз — мәктәп директоры, райбашкарма комитеты рәисе урынбасары, Ибраһимов Әнәс — Бөгелмә педучилищесында директор, Насруллин Рәшит — Казахстанда совхоз директоры, Гыйззәтуллин Ансар — Казанда танылган җитәкче-финансист, Хәбибуллин Солтангали — Кызыл юл районында колхоз рәисе, Гыйззәтуллин Хәким — сугыштан яраланып кайткач, райсоюз, райпотребсоюз рәисе, "Дружба" артеле рәисе, Калинин исемдәге колхоз рәисе булып эшли, шушы елларда Балтач район комитеты бюросына әгъза булып сайлана, соңгы елларда "Райтоп" директоры булып эшли, район төзелеш оешмасында мастер булып эшләп, лаеклы ялга китә. Хәлиуллина Роза Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлап, проектлаштыру үзәгендә эшләде. Роза безнең як проектларына аеруча игътибарлы иде. Карадуган мәктәбе проектын гамәлгә ашыруда аның ярдәме зур булды. Сугыштан яраланып, инвалид булып кайткан Галимҗанов Шәкүр абый да гомере буе бер урында — промкомбинат системасында бухгалтер булып эшләде, үз эшен гаҗәеп төгәл башкаруы белән аерылып торды. Хәлиуллин Корбангали гомере буе райсоюз системасында товар кайтаруны оештыручы булып эшләде.

Таузарда белем сукмаклары буйлап беренче баручы Хөсәен кызлары Мәчтүрә апа, Сәйдә апа, Маһикамал апа авыл яшьләре өчен җанлы үрнәк булалар. Өстәвенә, күренекле укытучы Якупов Хәсән абый, озын толымнарын зифа гәүдәсенә килешле итеп үреп салган гүзәл кыз Галия апа, Габделхак абый һәм хатыны Гарифә апаларның (Таузар башлангыч мәктәбендә укытучыларның) матур эш нәтиҗәседер дип уйланам — яшьләр белемгә омтылалар. Таузарның үз яшьләре укытучылык һөнәрен сайлап, уңышлы гына эшләделәр һәм эшлиләр. Алар алтмышлап була: Хөсәенова Сәйдә, Хөсәенова Мәчтүрә, Хөсәенова Маһикамал, Исмәгыйлева Розалина, Исмәгыйлев Идрис, Гыйззәтуллин Габделхак, Хәбибуллина Зөлхибә, Зәкиева Манзүма, Шакирова Әфтаф, Шакирова Тайфә, Хаҗиев Нурхамәт, Галиәхмәтова Факия (Шәяхмәт бабай оныгы), Насруллин Әсхәдулла, Сафина Мәсрүрә, Яппаров Ягъфәр, Галиәхмәтов Әхмәт, Касыймова Фирдәвес, Исмәгыйлев Фарук, Гомәров Вагыйз, Хаҗиева Фәүзия, Хәсбиев Равил, Хөсәенов Ислам, Зыятдинов Бакый, Сафин Фаяз, Ибраһимова Сания,

Фәттахова Мөнирә, Әүхәдиева Мөзәйнә, Гомәров Тәбрик, Хөсәенова Нурания, Зыятдинов Азат, Ибраһимов Илдар, Ибраһимова Алсу, Әхмәтова Фәния, Ибраһимов Әнәс, Йосыпов Рәҗәп, Габдуллина Розалия, Касыймова Розалина, Хәлиуллина Разия, Абдуллина Нурия, Ибраһимова Клара, Зыятдинова Чулпан, Гомәрова Йолдыз, Яппаров Филсур, Усманова Роза, Йосыпова Мәрхәбә, Йосыпова Чулпан, Йосыпова Гөлшат, Йосыпов Рушад, Вильданова Миләүшә, Вильданова Гүзәлия, Габдрахманова Лена, Габдрахманова Альбина, Галимова Розалия, Галиуллина Ильмира, Хафизова Розалия, Бәхтияров Габделбәр, Шәйнурова Гөлнара. Югарыда саналганнардан тыш Гайфуллина Кифая Казан финанс-экономика институтында укыта, фәннәр кандидаты, улы Марат Сафиуллин исә шул ук институтта эшли, икътисад фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Президентының социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча киңәшчесе. Гыйләҗетдинов Рәҗәп шушы ук институтта өлкән укытучы. Әхмәтова Тәнзилә Төмән авыл хуҗалыгы институтында укытты. Бер үк нәсел дәвамчылары — Таузар кызы Раузаның улы Роберт Бикмөхәммәтов һәм Таузар кызы Сафураның олы кызы Флера Мөхәммәтҗанова бүгенге көндә педагогика фәннәре докторлары, икесе дә Казан вузларында студентларга белем бирәләр.

Таузарлыларның белемгә, яктылыкка омтылуында аның муллаларының да йогынтысы булгандыр. Борылыш елларының рәхимле җилләре һәм дә Таузарның белемле яшьләренең икътисадый ярдәме белән матур гына, бик нык нигезле итеп төзелгән яңа мәчете дә имамнарның элекке дәрәҗәсен саклый торган укымышлы заттан муллалы булды. Үзлегеннән укып, үз белемен үзе күтәрә торган, дөньяви белеме дә тирән булган үтә дә тыйнак кеше Ибраһимов Васил халыкка кирәкле хезмәтен күрсәтә, аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешсен.

"Көрәш" колхозының районда алдынгылардан саналуы да юкка түгел, билгеле. Колхозның көндәлек эшләрен башкаручы колхозчылар да намуслы һәм үз эшләренең осталары буларак хөрмәтләнәләр: яшелчәчелектә эшләүче Хәлиуллин Хәсбиулла абый (бригадир), ире репрессиягә эләгеп үлеп калган Зыятдинова Һәдия апа (алдынгы сыер савучы) Мәскәүгә, Авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә кунакка чакырылалар.

Авылның яшелчә үстерүче, сыер савучы һәм уракчы апалары, ындыр табагында эшләүче, сугу машинасы өчен ат куучы малайлары, яшьләрнең эштән кайтуына казан астына утын ягып ашау хәзерләүче — өй җылысы булдыручы, оныклар

тәрбияләүче әби-бабайлар турында бик матур истәлекләр саклана. Абруйлы, туры сүзле, "Мактаулы колхозчы" исемен йөртүче Әминә Гыйззәтуллина, "Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре" булган Әдарәт Габдрахманов, Калинин исемендәге колхоз премиясе лауреаты, тракторчы Камил Абдуллин, авылның элекке җанлы тормышын сакларга тырышучы һәм әтиләре кебек уңган тракторчылар — мәрхүм Камилнең улы Газинур Абдуллин, Әсфән Рөстәм улы Гарипов турында фәкать яхшы фикерләр генә әйтеп була. Хат ташучы, хәбәр-сәлам китерүче Мансура үз эшен таузарлыларга гына хас пөхтәлек белән башкарды. Төзүчеләре агачтан чәчәкләр ясауда, йортлар төзүдә тирә-якта дан тоталар. Күрше авылда, "Дружба" артелендә эшләп, башлангыч күнекмәләр алган осталар авылда гына түгел, шәһәрләргә барып, авылның оста куллы егетләренең данын күтәрделәр — Әлтәф Гыйләҗев пианинолар эшләү фабрикасында эшләде, соңгы елларда тавыш буенча пианиноларны көйләүче булып китте. Сәйдәш Зыятдинов металлургия институтын тәмамлаган белгеч-инженер булса да, агач эшенә гаҗәп оста була, әле лаеклы ялга чыккач та шәһәрдә мәктәп һәм балалар бакчаларының ишек, тәрәзә, шкафларын ремонтлап бирә. Авылның тегермән һәм электр станциясе төзелешендә эшләгән өлкән буын төзүчеләренә алмашка Гыйльван Усманов, Илфир Галиуллин, Илнур Галиуллин, Илнур Хәлиуллин, Тәлгать Галимҗанов, Фаяз Габдуллин һәм улы Мөгазь алтын куллы балта осталары булып үсеп җитә, алмашка яшьләр килә бара. Агач, пыяла һәм тимер эшләренең остасы, "Татарстанның атказанган укытучысы" Йосыпов Рәҗәп абыйлары мәктәптән хезмәтнең һәр төренә өйрәтеп чыгара.

Язмамның башында Таузарның табигый күренешен сурәтләгән идем. Күмәк хуҗалык төзелгәннән соң, сугышка кадәр үк, авылның урта бер урынында ашлык амбары төзелә. Кенә суы килеп керә торган югары очында тегермән, электр станциясе, зират янында атлар өчен торак (конюшня), Шушма елгасына якынрак очында ындыр табагы: анда атлы сугу машинасы һәм ике куллы суыру машинасы куелган. Янәшәсендә терлекчелек фермасы. Халыкка җыелып сөйләшү урыны булып, шушы алда саналган гамәли пунктлар булса, рухын баету өчен алдагы елларда муллалы мәчете бар иде. Мәчет манарасы киселгәч, шул ук догалы мәчет бинасы уку йорты, клуб, мәктәп хезмәтен үти башлады. Колхоз өчен күмәк хезмәтнең бик мөһим вакытларында балалы аналарны да эшкә катнаштыру теләге белән балалар бакчасы да оештырылган. Авылда гар-

мунчы яшьләр катнашында кичке уеннар табигать кочагында (мәктәп яны һәм болында) үткәреләə иде. Мин яшь килен булып авылга — Таузарга килгәндә (1955) сугыштан соңгы елларның авырлыгы, налогларның иләмсез күптөрле булуы һәм зурлыгы (хәтта сыерның эчендәге бозавы да сыер хуҗасыныкы түгел иде) яшәү өчен гаҗәп авырлык тудырса, икенче яктан, һәр яңа көнне яшәү өчен уңайлыклар килер диеп, зур ышаныч белән көтә идек. Яшьләр дәртле, халыкта туасы көннең уңышына өмет бар. Шуңа да яшьләр уены әле кояш баеганчы ук әле бер болында, әле икенчесендә кемдер оештырганны көтмичә үк башланып китә иде. Яшь килен елларымда Бакый, аның энеләре белән кичке уеннарга күп йөрдек. Аерата кызыл даталарга багышланган (революцион) бәйрәмнәр күңелле үтә иде.

Сугыштан соңгы елларны, бигрәк тә 1945—1965 еллар турында уйланам да, Таузар иле апаларына (күбесенең ирләре сугыштан кайта алмады) абыйлары һәм абзыйларына (инде аларның күбесе мәрхүм) карата гел дә олы ихтирамым яши. Шушы хакта уйланам да, сафлык, яктылык, яхшылыкка өндәүче чишмә башын эзлим. Миңа Карадуган Себер тракты музее, аның хезмәткәрләре алып барган тарихи эзләнүләрдән тупланган материаллар ярдәм итә. Гомумән, Таузар халкы иманлы-догалы елларына рәхмәтле.

Мәчет манаралары киселгәч, диннән аерылу шуның белән гамәлгә ашты диеп уйлаучылар ялгыштылар, билгеле. Әби-бабайлардан күңелгә сеңгән догалар совет кешеләрен 70 ел буена исәнлектә саклап йөрттеләр. Төрлечә тикшерү, куркытуянаулар белән дингә каршы көрәш барса да, Бибисара һәм Бибиәсма әбиләр, Фатыйхабану апа, Рабига апа кебек ак әбиләрнең бай рухлы һәм киң күңелле булулары, миһербан-шәфкатькә өндәүләре белән динебезнең иң кирәкле баганалары безнең көннәргәчә сакланды. Таузарда яшәүчеләрнең күбесенә кендек әби булып саналган Рабига апа турында аерым әйтәсе килә. Авылда барлык зур һәм кечкенә кунак өстәле аның катнашыннан башка үтми иде. Аш-су хәзерләү остасы буларак та, үзенең чибәрлеге, өлгерлеге, якты йөзе, тәмле теле белән кунак сыйлау өчен яратылган иде ул Рабига апа. Ире сугышта хәбәрсез югалган. Өч баласын сабый чакта, кызы Разияны буй җиткергәч җирләгән хәсрәтле ана ул. Шөкер, бердәнбер булып калган кызы Мөнирә аны сигез онык белән сөендерде. Ул балаларның сигезе дә туган якларында игелекле хезмәттә. Сугыш елларында һәм аннан соңгы елларда да Рабига апа яшелчәчелектә эшли, бер үк вакытта колхоз буенча юл төзетү бригадиры булып та эшләгәне билгеле. Авылда сугыш елла-

рында бары да уртак була, авылның бердәмлеге һәм халыкның үзара ярдәмчел булуы авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Рабига апа киемнәр тегәргә дә оста, сарык йоны алу, каз йолку, эшләүче яшь гаиләләрнең балаларын карау, дога укып өшкерү, Коръән укып дога кылу кебек эшләрдә дә авылдашларына беренче ярдәм күрсәтүче шәфкатьле җан иде ул. Шуңадыр, олыгайган көнендә Чапшарда укытып, лаеклы ялга чыккан кызы Мөнирә, кияве Гарәфетдин алып китәргә, үзләре тәрбияләргә уйлагач та, авыл халкы Рабига апасыз калуны авыр кичерде. Ул Чапшарда яшәгәндә аның хәлен белергә, аның белән сөйләшергә барып йөрделәр. Рабига апа вафат инде, җәсәде Таузар зиратында, урыны оҗмахта булсын дип телибез.

Таузарда электростанция төзелү йортларны да, кешеләрнең күңелләрен дә яктыртты. Ул еллар өчен гаҗәп хәл бит: суы иң тирән җирендә тездән генә булган инеш авылның һәр йортын яктыртырлык энергия бирә. Якын-тирә авыллардан, Балтач районының барлык мәктәпләреннән төркем-төркем балалар электростанциянең эшен өйрәнергә экскурсия ясыйлар иде. Төп электормонтёр эшләрен Раузит Әүхәдиев, Юныс Әүхәдиев, Рәис Хаҗиев, Әдарәт Габдрахманов кебек, авылның үз ир-егетләре (махсус курсларда укып кайтып) башкардылар, электрга көйләп радиоузел эшләтә башладылар, авыл радиолаштырылды. Радиоузел ярдәмендә колхоз эшләре белән таныштыру, аерым кешеләрнең алдынгы булып китүенең серләрен башкаларга таратуда, бер яктан, зур эш башкарылса, икенче яктан, күңелле дә иде. Чөнки алдынгы булган өчен мактау, туган көннәр белән котлау, кимчелекләрне "уены-чыны белән бергә" тәнкыйтьләү, хөкүмәт карарларын үтәүнең барышы белән таныштыру — массакүләм аңлату эшләре радио аша алып барыла. Шунда ук һәр белдерү һәм тапшыру (шушы авыл кешеләре башкаруындагы) җыр-музыка белән тәмамлана. Ул вакытта пластинка уйнату бар, ә кассеталар турында белми дә идек. Радиоузелны тулысынча корып, эшләтү хәлендә таузарлыларга тапшыручы кеше Балтачтан Салих абый Булатов була. Салих абыйның игелекле эшенә авыл халкы олы рәхмәтле. Соңыннан радиоузелны Таузар егетләре Мазһар Хәсбиев, Юныс Әүхәдиев эшләттеләр.

Уку йортында мөдирлек эшләрен башкаручылар да авыл халкын ихтирам итте, чын мәгънәсендә халыкка хезмәт итүче булдылар. Әле уку йорты өчен урын билгеле булмаган елларда халыкка лекция уку, концерт һәм "театр" куую эшләрен фәкать укытучылар башкара иде. Инде колхозлар берләшеп, колхоз

идарәсенең эш бүлмәсе булган “контора йорты” бушагач, уку йорты итеп шул бинаны бизәделәр. Аны ягып җылыту һәм культура-агарту эшләре колхоз идарәсе карамагында иде, ягъни тагын да шул ук укытучылар эшчәнлегенә калды. Арбашта ясле-бакча ябылгач, аннан бушаган бинаны Таузарга клуб итеп күчереп салдылар. Радиоузел һәм клубны Бөек Ватан сугышы инвалиды Зәкиев Исрафил абый ягып җылытты. “Халыкка әдәби китапларны Арбаш китапханәсендә эшләүче Ибраһимова Тәскирә апа велосипед утыргычына бәйләп алып килеп өләшә һәм яңаларына даими алмаштырып тора иде”, дип, әле дә сагынып сөйлиләр, рухы җәннәтә булсын иде, дип телиләр. Ә клуб мөдирлеге эшен Сания Әгъзамовага тапшыралар.

1970 елларга кадәр Таузар клубында дәүләт штатындагы мәдәният хезмәткәре булмады. Колхозның ярым-йорты штатына эшләп, бинаны үзе ягып җылытучы мөдир булып Бөек Ватан сугышы инвалиды Исрафил абый эшләгәндә дә Таузар клубы гөрләп торды. Укытучылар Марсель Миннебаев, Фәүзия Хәлиуллина, соңгы елларда Рәйсә Дәүләтшина, Фәния Әхмәтова оештыруы белән авыл яшьләре һәр бәйрәм саен концерт-спектакльләр куеп, авыл халкын куандырдылар. Клуб шыгрым тулы була, ә тамашачылар шундый актив. Сәхнәдән ишетелгән һәр фикерне “шулай шул”, “дөрес әйтәсең” дип җөпләп баралар.

Дәүләт штаты белән клуб мөдире булып эшләүче Ибраһимова Әкълимә (ул Таузарга укымышлы һәм иҗади сәләтле Ибраһимовларга килен булып төште) клуб эшен бигрәк тә җанландырды. Әкълимә Таузар халкын үз итте, үзенең оештыру осталыгы белән халыкның ихтирамын казанды.

Колхозның идарә пункты Карадуганда булу халыкның көндәлек йомышларын үтәүне кыенлаштырды. Барысы да Әкълимәгә, алдынгы колхозчы, авыл Советы депутаты Әминә Гыйззәтуллинага баралар иде. Алар икесе дә үтә сабыр, тормышның төрле ягын аңлаучы тәҗрибәле, олы киңәшче булдылар. Әкълимә клуб эшен үз югарылыгына куйды, тематик кичәләр хәзерләп, концерт-спектакльләр өйрәнеп, аларны халыкка күрсәтеп, Таузар клубы башкаларга үрнәк булды. Без Карадуган авылы Советы һәм Шубан авылларында доклад-лекцияләр, концерт-спектакльләр куеп, ата-аналар җыелышы үткәреп йөри идек. Фәрзи абый әйткәнчә, шул биш авылдан Таузарда үткән кичә һәм җыелышлардан рухланып кайта идек. Чөнки анда урамга белдерү кую белән олысы да, кечесе дә лекция-кичәләргә килә иде. Башка авылларда җитмеш яшь-

лекләрнең лекция тыңларга килүен хәтерләмим. Ә Таузарда киләләр, килә генә түгел, алар илнең эчке һәм тышкы хәле белән кызыксыналар, фәнни темаларга да, педагогика темаларына да игътибарлы, сораулар биреп, үз фикерләрен белдереп, актив катнашалар иде.

Менә мин күргән һәм дә килен булып яшәгән Таузар иле шушы инде. Әле мин бу язмамда әлеге авылның асыл егетләренә кияүгә чыгып, шушы авыл кешеләре белән үзләре кебек игелекле булып яшәгән, эшләгән, балалар тәрбияләп үстергән, олыларын ихтирам белән карап, соңгы юлга озата алган итагатьле киленнәр турында язмадым, алар мине кичерерләр дип уйлыйм. Алда саналган төрле тармакларда җитәкчелек иткән, кешеләргә үзе белгәне кадәр яшәү ямен, яшәү өчен кирәкле белемне аңлатырга тырышкан укытучылары турында уйланам; киң күңелле, нечкә хисле, рухи яктан бай кешеләр, алга таба яшәү өчен көрәш алымнарын аңлата алучы көчле рухлылар дип, алар каршында баш иям. Хәзерге яшьләр күз алдына да китерә алмый торган, тагын бер бәяләп бетергесез ныклык, тәртиплелек яши иде авылда. Алар — колхозчы (терлекче һәм игенче), җитәкче, укытучы, колхоз рәисе, бригадир һәм агроном — берсе дә акча өчен, аерым үз байлыгы өчен диеп эшләмәделәр, аларның бары да партия әгъзалары диеп уйласак та ялгыш булыр. Гап-гади — синдәй-миндәй кешеләр, әмма көчле рухлылар иде.

Менә ул Таузар шундый иде дип, узган заманда сөйләргә калды, чөнки хәзер Таузар гөрләми инде. Билгеле, булган балалары тырышалар, әйбәт укыйлар. Авылның бүгенге хәлгә калуына объектив та, субъектив та сәбәпләр бардыр... Кенәләр белән кушылганда, алар: "Колхоз үзәге урталыкта — Таузарда булса гына кушылабыз", — дигәннәр иде. Ләкин читтән килгән рәисләргә алай уңайсыз булды һәм алар колхоз идарәсе йортын Карадуганга күчерделәр. Аннан ул — Таузар иле перспективасыз авыллар исемлегенә керде. Нәтиҗәдә, хәтта берара ферма һәм мәктәп тә бетеп торды, медпункт юк, кибетне авылдан читтәрәк, бушап калган таш бинага күчерделәр. Яшьләр китә башлады. Хәзер мәктәп тә кайтты, медпункт ачылды, йортлар газ белән җылытыла, асфальт юлдан автобуслар йөреп тора, ләкин мәгълүм әйтемдәгечә, "поезд киткән инде..." Әмма тарихта авыр чорлар уңайлары белән аралашканын беләбез. Таузар авылы да кабат яшәрер, гөрләр әле дигән өметтә калыйк.

...Ә Таузардан чыккан кешеләр кайда эшләсәләр дә, туган авылларының йөзенә кызыллык китермиләр, авылда алган матур сыйфатларны үзләре яшәгән урыннарда күрсәтәләр һәм иң мөһиме — үзләренең Таузардан булулары белән горурланалар. Туган җир, эчкән су, күңелле балачак истәлекләре читтәгеләрнең дә күңелләрендә авылдашлары өчен ниндидер игелекле гамәл кылу теләген уятадыр.

Алдарак Гыйззәтуллин Габделхак абыйның сугышка кадәр педучилище тәмамлап, Таузар башлангыч мәктәбендә укытуы турында әйтелгән иде. Аның бертуганы Хәбибелхак абый һәм улы Ансар турында да авылда күңелле хатирәләр саклана. "Хәбибелхак абый сугышка кадәр үк велосипедта бик куәтле йөри иде," — дип сөйлиләр ул чактагы яшүсмер егетләр. "Хәбибелхак абыйның велосипедта барган килеш ике кулын да рульдән ычкындырып, як-якка җәеп баруына исебез китеп, кайда ничек туктар инде бу диеп, биш-алты малай артыннан чабып йөргәнебез хәтердә," — дип искә ала музей директоры Зыятдинов Бакый. Хәбибелхак абый 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнашып, ике мәртәбә яралана, кабат сугышка кереп, "Батырлык өчен медале" тагып авылга исән-имин кайта. Колхозда төзелеш эшләрендә эшли. Олыгайган көнендә, Хәбибрахман абзый вафатыннан соң, авылда имамлык вазифасын тыйнак кына башкарып, авылдашларының олы рәхмәтен ала. Ә улы Ансар үтә дә тырыш булып үсә, Казан финанс-экономия институтында укып, үз эшенең остасы булып өлгерә — банк белән идарә итә. Таузарда мәчет төзүгә дә ярдәм итте. Хәбибелхак абый вафат инде, Ансар әнисенең хәер-догасын алып яши, эшли. Авылыбыз, районыбыз халкын хөрмәт итә. Ансар авыл тарихы белән кызыксына, Карадуган Себер тракты тарихы музеена эзләнүләр алып бару эшенә якыннан ярдәм итә. Димәк, безнең "тарихта эзлебез" диярлек күңелле эшләребез бар. Игелекле яшьләр үсүе куанычлы. Хәбибрахман абзыйларның оныгы Хөсәенов Рубис Илдус улы ярдәме белән Таузар авыл зираты челтәрле тимер койма белән әйләндереп алынды. Билгеле, бу эшләрне башкарып чыгуда Таузар халкы бик теләп, көчләрен җәлләмичә катнашты. Бу саваплы эш өчен Рубиска исәннәр рәхмәт укый, ә мәрхүмнәрнең рухлары шатланадыр.

Шушы урында мин уйларымны туктатыйм да, үзләре турында фәкать матур хатирәләр генә калдырган, бик күп күркәм гамәлләре белән күңелгә гамьнәр салган, күп сыйфатлары белән сокландырган Таузар халкына рәхмәт әйтеп, сүз җебен авторның үзенә тапшырыйм.

Таузарлылар — гомер юлдашларым

Таузарда әти-әнием, туганнарым, үз гаиләбездән тыш минем тормышымда сизелерлек эз калдырган авылдашларымнан беренче итеп Вагыйз абый Гомәровны күрсәтер идем. Минем үземнең бертуган абыем Сәйдәш бәбәй вакытта ук үлгән һәм минем башка бертуган абыем булмаган. Мин һәрвакыт әтинең абыйсы Гомәр (без аны дәү әти дип йөргәнбез) малае Вагыйз абыйны абый дип кенә йөрттем. Гомәр абый репрессиягә эләгеп, төрмәдә вафат булды һәм абыйлар ятим үсте. Безнең балачак та бергә үтте. Зыя бабай да еш кына безне бергә йөртә иде. Балтач каршысындагы пионер лагерена абыйның хәлен белергә бабайның мине алып барганы хәтердә калган. Вагыйз абый белән егет вакытны да бергә үткәрдек. Таузар урамнарын кич белән гармунга җырлап үткәннәр дә хәтердә, кызлар янына барган маршрутларыбыз бергә туры килә иде. Ул һәрвакыт миңа үзенең акыллы киңәшләрен бирде. Абый Карадуган мәктәбен тәмамлаганнан соң, сугыш елларында Арча педагогия училищесын тәмамлады. (Сугыш вакытында педучилище Үрнәк поселогына күчерелгән иде.) Шул училищеда укыганда ул шахмат уены белән танышып, мине дә өйрәткән иде, мин Балтач мәктәбендә сабакташларыма өйрәттем, шахмат минем гомерлек юлдашым булды, хәтта берничә тапкыр район чемпионы да калдым.

Абый башта башлангыч мәктәпләрдә укытты. Соңыннан, читтән торып Казан Дәүләт педагогия институтының география факультетын тәмамлап, пенсиягә киткәнче Яңгул урта мәктәбендә география укытты, районның күренекле укытучыларыннан булды, аны укучылары әле дә бик хөрмәтләп искә алалар. Минем укытучы һөнәрен сайлавымда да аның йогынтысы булмый калмагандыр. Вагыйз абый Рәйсә белән бергә бер ул, ике кыз тәрбияләп үстерделәр, аларга югары бе-

Вагыйз абый хатыны Рәйсә апа белән.

лем бирделәр. Уллары Рөстәм төзүче, кызлары Гөлсинә укытучы, ә Әнисә медицина хезмәткәре. Абый белән уртак сүзләребез күп иде, тик ул мәрхүм инде, Яңгул зиратына җирләнде, авыр туфрагы җиңел булсын.

Балачактан ук дустым Ислам (тулы исеме Шәйхелислам) Хөсәенов белән без, ул мәрхүм булганчы, якыннан аралашып яшәдек. Холыкларыбыз да бик туры килми шикелле: мин кешеләр белән тиз аралашучан, ул киресенчә — бик ачылып китми, авырдан аралаша; мин шау-шулы мәҗлесләрне дә ят итмим, ә ул аларны бер дә яратмый. Бу уңай белән шунысын да әйтим, халык арасында: "Ислам Бакый белән берәр йөз грамм тота да икән", — дигән сүз дә йөргән. Шулай да без эч серләребезне уртаклашып, мөмкин булганда үзара ярдәмләшеп яшәдек. Күрәсең, безнең холыклар бер-берсен тулыландыргандыр. Ислам күпкырлы белемгә ия иде, аны педучилищеда укыганда ук "аяклы энциклопедия" дип йөрткәннәр. Ул Арча педагогия училищесын тәмамлагач, башта башлангыч классларда укытты. Армиядә хезмәт итеп кайткач, партия эшендә эшләде. Соңыннан пенсиягә чыкканчы Балтач урта мәктәбендә физика укытты, физика укытучылары арасында абруе зур иде. Ул ике институт — Казанда педагогия институтының математика бүлеген, Мәскәүдә, читтән торып укып, физика факультетын тәмамлады. Аның кулы бөтен эшкә ябыша иде: ул агач эшен дә булдыра, теләсә нинди приборны да төзәтә, электр эшен дә яхшы белә.

Ислам дустым һәм хатыны Сания ханым.

Алар Сания белән ике ул, ике кыз тәрбияләп үстерделәр, балалары да үзе кебек "башлы" булдылар, барысы да югары белемле. Олы улы Фәиз Балтачта яши, комбикорм заводы директоры. Мине, әтисенең дусты буларак, бик хөрмәт итә. Ислам белән балачакта булган бер хатирә нык истә калган: без язгы ташуда боз киткәнен Таузар күпере өстеннән карый идек. Малайлар агып баручы боз өстенә бауга бәйләнгән сөңге ыргытып,

аны ватарга тырышалар иде. Шулай бервакыт, сөңге ыргыткан-да күпер аратасы ычкынып, Ислам суга агып китте. Без "ах" итеп аны күзәтәбез, ләкин ярдәм итә алмыйбыз. Ә Ислам су ярга бәрелеп борылган җирдә ярга ябышырга өлгереп, исән калды. Без аның исән калуына куанып, ничек булуын сорагач, "...күпер астыннан агып чыкканда уйлап чыктым — су яр кырыена бәрелеп борылыш ясый, димәк, миңа шул уңайга йөзәргә тырышырга кирәк дип, план кордым һәм шулай эшләдем", — дип җавап биреп, безне шундый һәлакәтле хәлдә дә паникага бирелмичә уйлап эш итүе белән шаккатырган иде. Ислам дустым 1991 елда вафат булды һәм Таузар зиратына җирләнде. Урыны оҗмахта булсын.

Минем тагын якыннан аралашып гомер иткән иптәшем Яппаров Ягъфәр булды. Без алар белән күршеләр идек. Ул олырак булса да, малай вакыттан ук мине үзенә ияртеп йөртә иде. Укытучы, директор булып эшләү чорларында да бергә-бергә, бер-беребез белән ярдәмләшеп яшәдек. Ир туганы булмаудандырмы, аларда узган зур мәҗлесләрдә, туйларда безнең урын түр башында була иде. Ягъфәр озак еллар Чепья мәктәбендә директор булып эшләде, ул эшләгән елларда Чепья мәктәбенең даны бөтен республикага таралды. Бигрәк тә үзешчән сәнгатьне үстерүдә, хәрби-патриотик тәрбия бирүдә ул мәктәп күпләргә өлге булды. Бу өлкәдә Чепья мәктәбенең өлкән пионервожатые, искиткеч талант иясе, Татарстанның атказанган укытучысы Гыйльманов Фәртнең хезмәте зур булды. Ул оештырган җыр-бию ансамбле Мәскәү сәхнәләрендә чыгыш ясады. Хәзерге вакытта Чепьядагы районыбыз горурлыгы булган "Халыклар дуслыгы" музее (оештыручысы һәм директоры — Гарифҗан Галиев) да Ягъфәр Якупович директор булып эшләгән елларда барлыкка килде. Музее белән дә мәктәп бөтен республикага дан алды.

Ягъфәр дустым һәм хатыны Рауза ханым.

Ягъфәрнең хезмәте югары бәяләнде, ул "РСФСРның атказанган укытучысы" исеменә лаек булды. Соңыннан Балтач урта мәктәбендә директор булып эшләде һәм шуннан пенсиягә китте. Ватан сугышында офицер буларак катнашкан иде Ягъфәр, аннан яраланып, "Кызыл Йолдыз" ордены алып кайткан иде.

Безнең әти-әниләр дә бик тату яшәделәр. Якуп абый авыл Советы рәисе, әти налог агенты буларак, аларга да бергә эшләргә туры килде. Ягъфәрнең әнисе Хәтимә апа белән безнең әни колхозда иң алдынгылар булып эшләделәр. Ягъфәр Рауза апа белән бергә гомер кичереп, ике ул, ике кыз тәрбияләп үстерделәр. Рауза апа бик күркәм хатын иде. 1945 елда Кенә мәктәбенә институт бетереп килде ул. Үзенең белеме, сәләте, әдәбиятны, сәнгатьне яратуы белән Кенә мәктәбенә хәзинә булды. 1948 елда ул безнең күршегә килен булып төште. Шул елны мин институтка керергә хәзерләнә идем, киңәшләр биргәне әле дә исемдә. Рауза апа мәрхүм инде, ул Таузар зиратына җирләнде, урыны оҗмахта булсын. Ягъфәр 2000 елда Хаҗ кылды, намазын калдырмады. Хәзер ул да гүр иясе инде. Туган авылы Таузарга җирләнде, урыны җәннәттә булсын.

Тагын бер аралашып яшәгән, күңелгә якын булып калган мәрхүм Әлтаф туган турында да әйтеп китәсем килә. Безнең белән янәшә Зыятдин бабайның энесе Гыйләҗетдин яшәде. Аның улы Сөнгатулла сугышта үлгәч, Әнвәр апа биш бала белән тол калды.

Әлтаф туган (сулда) һәм энем Сәйдәш.

Олы улы Әлтаф Гыйләҗетдинов, Карадуган мәктәбен тәмамлагач, Хәсәншәехтагы “Дружба” кустарь артелендә балта остасы-столяр һөнәрләрен өйрәнде. Әниләре Әнвәр апа Каратайның Әхмәтгали кызы, ә Әхмәтгалине 30 нчы елларда кулак дип, Уралга сөрәләр һәм ул өч улы белән Магнитогорск комбинаты — шәһәр төзелешләрендә эшли. Сугыштан соңгы авыр елларда Әлтаф тә Магнитогорскига, бабасы янына барып урнаша һәм соңыннан әнисен, туганнарын шунда алып китә, әбисен (дөресрәге, әбисенең сеңлесе) Гайшәбикәне һәм аның кызы Гөлҗиһан апаны да шунда тарта. Алар хәйран зур йорт салып, башта барысы бергә яшәделәр. Соңыннан, билгеле, һәркайсы үз ояларын корды, ләкин төп йорт итеп һәрвакыт Әлтаф өендә җыелалар иде. Әлтаф башта мебель фабрикасында эшләде, анда пианино ясау цехы ачылгач, пианино җыйнаучы, ә соңыннан аларны тавыш буенча көйләүче булды. Күрәсең, оста көйләүче булгандыр, Чиләбе, Миасс, Карталы шәһәрләренә дә чакырталар иде үзен. Әлтаф туган

ягын бик сагынып яшәде, һәр ел саен диярлек сабан туена кайта иде. Сеңлесе Глара һәм кияве Котдус белән бергәләп, безнең гаиләне дә үз машиналарында Башкортостан, Чиләбе өлкәсе аркылы берничә тапкыр Магнитогорскига алып барып кунак иттеләр, Урал якларының бик күп матур урыннарына сәяхәт кылдырдылар. Алар Мәдинә белән ике ул, бер кыз үстерделәр. Улы Азат, кызы Флера Казанда институтта укып чыктылар. Әлтаф иртә вафат булды. 1992 елда миңа Магнитогорскида аны җирләүдә катнашырга насыйп булды, урыны җәннәттә булсын.

Әнәс дустым — җитмеш һөнәр иясе.

Кешеләрнең рухи якынлыгында аларның яшь аермасы да әһәмиятле түгел икән. Менә шундый дусларның берсе — Әнәс Гариф улы Ибраһимов. Ул минем Илгиз энем белән яшьтәш һәм сабакташ. Мин аны бераз укыттым да, ә иң мөһиме — без аның белән Карадуган мәктәбендә шактый еллар бергә эшләдек. Әнәс бик эрудицияле, үз фәне географияне яхшы белүче генә түгел, рәсем ясарга да оста, минем Азат энемнең туена ясап бүләк иткән Таузар авылы күренешен әле дә кадерләп саклыйбыз. Ул музыканы да яхшы аңлый, үзе баянда бик матур уйный, безне дә җырлата иде. Безне иң якынайтканы, мөгаен, икебезнең дә сәяхәт итәргә яратуыбыз, туган як тарихы һәм табигате белән кызыксынуыбыз булгандыр. Безнең Карадуган мәктәбенә дан китергән Муса Җәлил музеен төзүдә аның хезмәте зур булды. Укучылар белән Муса Җәлилнең туган ягы Оренбург өлкәсенә сәяхәтне ул җитәкләде.

Үзе фотограф, кешеләр белән бик тиз уртак тел таба белә, укучыларны үзенең яратуы, балаларның да аны бик якын күрүе Әнәснең рухи бай булуыннан киләдер. Ул сәяхәттән бик мул материал алып кайтып, музей төзергә мөмкинлек ачты. Әнәс музейны (аның баштагы вариантын) төзүдә дә башлап йөрүче булды.

Икенче елны балалар белән Одессага — Муса Җәлил теплоходында сәяхәте дә музейны әһәмиятле материалларга баетты.

Сәяхәттә тупланган материаллар хәзергәчә күзәтүчеләргә кызыклы һәм тарихи яктан кыйммәтле булулары белән кадерле. Безнең Карадуган мәктәбе укытучылары белән һәр ел саен куйган спектакльләребезнең сәхнәсен һәм музыкаль өлешен бизәүче, төп рольләрнең берсен башкаручы да ул булды.

Билгеле, андый сәләтле кешеләрне гади укытучы итеп озак тотмыйлар. Аны башта мәктәп директоры итеп күрше мәктәпкә күчерделәр. Бу безнең мәктәп өчен зур югалту булды. Соңыннан Әнәс район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләде. Менә 1985 елдан бирле ул Бөгелмә педагогия училищесы директоры, аны иске интернат-мәктәп бинасында оештыра башлап, хәзерге заман таләпләренә туры килә торган итеп җиһазлап, алдынгы уку йортына әверелдерде.

Әнәс авылдаш кызыбыз — Җәләй абый кызы Фәния белән гаилә корып, хәзерге заман өчен рекордлы санда — биш бала үстерделәр. Фәния ханым “Ана даны” медале белән бүләкләнде. Балалары әти-әниләре кебек белемле, итагатьле, тормышта һәрберсе үз урынын тапты. Без Әнәс белән хәзер дә элемтәдә торабыз, бер-беребезнең хәлен белергә, мөмкин булганда очрашырга тырышабыз.

Әүлия кабере

Кабер ташындагы язу:

Бөек Алла әйтте белә алмас
Һичкем кайсы җирдә үләсен
Әйтте Бөек (Алла) һәр җан иясе үләчәктер
*(Вафат булды) Тарих тукыз йөз кырык сикездә**

....

....

(Соңгы ике юл бозылган, укып булмый.)

Укыды: **Әхмәт БУЛАТОВ.**

* *948 ел һиҗри белән. Миладига күчергәндә 1541 ел була.*

Равил ФӘХРЕТДИНОВ фотосурәтләре.

Авылыбызның табигый-тарихи истәлекле урыннары

Әүлия кабере — ул безнең якның борынгы кабере һәм аңа куелган ташта “1541 ел” дигән сан язылган, халыкта бу кабердә Искәндәр Хаҗи күмелгән дигән риваять саклана. Аңа һәрвакыт килеп, дога кылып, садака куеп китәләр.

Иске зират — Таузар авылыннан көньяк-көнчыгышта, Дусай елгасы өстендәге каберлек, 1960 елларга кадәр кабер урыннары ачык беленеп тора иде, соңыннан тракторлар сөреп, тигезләп бетерделәр. Санкт-Петербургтан алдырган XIX гасырга караган карта-планнарда ул мөселман зираты дип күрсәтелгән.

Таузар авылы инеше — (ул “Хотня” яки “Кенә” суы атамасы белән йөртелә) Шушма елгасына коя. Инешнең Шушмага кушылган урыны “Өзек” дип йөртелә. Карадуган тегермәне эшләп торган вакытта Шушма елгасы һәм инешнең суы яр тутырып тора иде. Бала вакытта йөзәргә өйрәнгәндә беренче баскыч шул өзекне йөзеп чыгу, икенче баскыч — Шушманы йөзеп чыгу иде.

Дүче тавы — Шушма елгасының Таузарга каршы Шубан авылы янындагы тау, яшьләрнең чаңгы шуу урыны иде.

Кирәмәт — инешнең сул ягында, Таузардан Кенәгә бара торган юл буйлап сузылган тау, бала-чаганың чана, чаңгы шуу урыны иде. Мари яки удмурт халкының табыну урыны исеменә нисбәт булырга тиеш.

Дусай елгасы — авылның көньягындагы тирән елга.

Коелы чишмә — шул Дусай елгасы тамагындагы җирдән тибеп торучы чишмә, суны җиргә батырып куелган мичкәдән чүмеч белән аласы.

Нарат асты басуы — шул ук Дусай елгасыннан көньяктагы карт нарат агачы үскән басу.

Кенә чишмәсе — Кенәгә бара торган юл өстендәге, Таузар кешеләре су алырга йөри торган мул, тәмле сулы чишмә.

Ком базы — Кирәмәт тавы өстендәге, тирә-як авылларының ком алу урыны.

Мулла болыны — Таузар болынының Хәсәншәех кырыендагы өлеше авыл муллысына бирелгәнлектән, шулай аталган.

Кондыз дугае — Карадуган ягындагы болында Шушма елгасы зур борылыш ясаган урын. Монда кондызлар күп үрчегән.

Бүре елгасы — Хәсәншәех белән ике арадагы, тирәсендә чыршы агачы, артыш үскән тирән елга. Элек анда бүре оясы булган дип сөйлиләр.

Эт шомырты — Хәсәншәех авылы белән ике арадагы юлдан көньяктагы басу уртасында үскән ялгыз агач (эт шомырты агачы).

Нәсел шәҗәрәләре төзү буенча киңәшләр

Бу китаптагы метрика кенәгәсеннән һәм ревизия материаллары күчермәләреннән теләгән кеше үзенең бабаларын эзләү һәм нәсел шәҗәрәсен төзү өчен мөмкинлек табар.

Үземнең күрше, дустым мәрхүм **Яппаров Ягъфәр** мисалында аның бабаларын эзләп табуны күрсәтәм. Ягъфәр үзенең әтисе Якуп абыйның 1901 елда туганын белә. Таузар авылының 1901 елгы метрикасын карасак, анда **Муллаякуп**ның әтисе **Габделҗаббар,** бабасы **Нәҗметдин** икәне күренә. Буыннар арасы уртача утыз яшь чамасы икәнен истә тотсак, Габделҗаббарның 1858 елгы ревизиядән соң туганлыгы күренә, ләкин бабасы бу ревизиядә булырга тиеш. Таузар авылында биш Нәҗметдин бар, без шуның кайсысы Ягъфәр бабасы икәнен белмибез. Бу очракта якынча утыз ел куеп, ягъни 1870 еллар тирәсеннән Габделҗаббарны метрикадан эзлибез һәм Габделҗаббарның 1874 елда туганлыгын табабыз. Анда Габделҗаббарның әтисе Нәҗметдин (Якупның бабасы), ә бабасы **Хәсән** икәне күренә. Теге биш Нәҗметдиннең әтисе Хәсән булганы бер генә, ул да булса 1858 елгы ревизиядә № 1 дип теркәлгән хуҗалык башы Хәсән Әбҗәлилов. Ул гаилә тулысы белән бирелгән, туган еллары, үзара туганлык мөнәсәбәте күрсәтелгән. Шуннан соң 1834 елгы ревизия китабына күчәбез һәм шуннан эзләп (хуҗалык номерлары бер-берсенә якын була), **Әбҗәлил**нең **Әбдерәшит**ов булуы күренә һәм шул ук ревизиядә аның улы Хәсән, оныгы Нәҗметдин икәне дә күренә. Димәк, шушы эзләнүләрдән чыгып, Ягъфәрнең биш бабасы билгеле булды: **Габделҗаббар, Нәҗметдин, Хәсән, Әбҗәлил, Әбдерәшит.** Хәзер безнең кулда 1762 елгы ревизия материаллары бар, алга таба эзләнүне дәвам итәбез. 1834 елгы ревизиядә 1816 елгы ревизиядә исән булган кешеләр һәм аларның яшьләре күрсәтелгән. Мәсәлән, Әбҗәлил Әбдерәшитовка 56 яшь икәне күренә. 1816 — 56 = 1760. Ягъни Әбҗәлил 1760 елда туган. Димәк, 1762 елгы ревизиягә эләккән. Аны эзлибез. Анда Нияз Кузаевның малае Габдерәшит һәм аның уллары Әбҗәлил һәм Әбүбәкер дип язылган. Димәк тагы ике бабай **Нияз** һәм **Кузай** (рус ревизия ясаучылары татар исемен бик нык бозганнар) билгеле булды. Шуннан 1745 елгы ревизиягә күчәбез. Анда Сәфәр Кузаев хуҗалыгы теркәлгән һәм Сәфәрнең туганы Нияз икәне әйтелгән, ләкин монда бабайлар саны артмады әле. Әле шунысы: Сәфәр белән Ниязның бертуган булулары 1716 елгы беренче ревизиядә алар хуҗалыгы кайсысы булуны ачыкларга мөмкинлек бирә. Анда Козейко

Яникеев, аның уллары Сәфәр (Саперко), Нияз (Неяско) дип язылган, димәк тагын бер бабай **Еникәй** табыла.

Шулай итеп, Ягъфәрнең барлыгы сигез бабасы табылды: **Габделҗаббар, Нәҗметдин, Хәсән, Әбҗәлил, Әбдерәшит, Нияз,** һәм **Еникәй.** (Алга таба, Дәүләт архивларында сакланган халык исәбен алу материалларыннан күчермәләрдә, бу исемнәр калын хәрефләр белән аерып күрсәтеләчәк: 115, 119, 124, 127, 137, 156, 175, 193 битләрдә). Монда әле 1678 елгы халык исәбен алу материалларыннан да эзләнү юлы кала, ләкин анда бик аз нәселләр генә ачыкланды. Казанда 1816, 1811, 1795 һәм 1782 елгы ревизияләр сакланмаган, шуңа күрә 1834 елгы ревизиядән 1762 елгы ревизиягә күчкәндә, һәркемнең дә бабасын ачыклау мөмкин түгел. Монда 1816 елгы ревизиядә кешенең олы яшьтә булуы табарга ярдәм итә яки ул исем сирәгрәк очрый торган булса, авылда башка кабатланмаса, бер исем ярдәмендә дә ул кешене ревизия материалыннан ачыкларга була. Безнең районның барлык авылларының да метрика кенәгәләре Казанда саклана. Бабаңның туган елларын чамалап, район загс бүлеге аркылы соратып, белешмә алдырырга мөмкин. Ә элек Казан губернасына кергән авылларның 1858, 1851, 1834 елгы ревизия материаллары шулай ук Казанда, милли архивта саклана, аның дирекциясе һәм уку залы Кави Нәҗми урамына урнашкан, шунда алып укырга һәм күчереп алырга мөмкин. Хат язу өчен адресы:

420111 г. Казань
ул. Кремлевская, 2/6
НА РТ (Национальный архив Республики Татарстан)

Ә элек Вятка губернасына кергән авылларның ревизия материаллары Киров өлкә архивында саклана. Казан губернасыннан аермалы буларак, анда 1795, 1811, 1816, 1834, 1851 һәм 1858 елгы ревизия материаллары тулырак сакланган. Киров архивының адресы:

610027 г. Киров, ул. К.Маркса,142
Государственный архив Кировской области

1716, 1745, 1762 елгы ревизия материалларын Мәскәү архивыннан алдырып була. Аның адресы:

119817, ГСП Москва Г-435
Б. Пироговская, 17 РГАДА (Российский Государственный архив древних актов)

Нәсел шәҗәрәсе төзегәндә авыл Советларындагы (җирле үзидарә) хуҗалык китапларыннан да файдаланырга кирәк, күпчелек авылларның 1940 елдан хуҗалык китаплары сакланган, хәтта 1936 елгылары да очрый.

Дәүләт архивларындагы халык исәбен алу материалларыннан күчермәләр

Российский государственный архив древних актов (РГАДА)

*ф. 1209 (поместный фонд или фонд старых вотчинных дел), опись 1, ч. 2, КН. 6453 (по описи РГАДА: " Переписная книга пригородов Арска, Малмыжа, сел и деревень (дворцовых, помещичных, монастырских, служилых татар и ясачных) по Арской дороге Казанского уезда, переписи стольника М. С. Супонева, **1678** г. лл. 237—1042. подлинник.)*

*(После описания яс. тат. дер..., "что был починок Ал(ь)метевской" — нами локализуется в пределах совр. с. Балтаси. Следующая — дер. Таузарова. — **Р. Галлямов**)*

л. 878 Дер. Таузарово. А в ней:

1 Двор. Саркейка Сабаева. У него дети: Уразмаметко (Уразмөхәммәт), Шабулатко (Ишбулат), да Шалкейко десети (10) лет.

Платит пол-ясака да с меленки оброку и пошлин четыре (4) алтына две деньги. Да ему же велено платить вновь пол-ясака.

2 Двор. Уразмаметко Урасаева. У него дети: Ирейко двунатцати (12) лет, Уразайко ос(ь)ми (8) лет. Платит пол-ясака.

3 Двор. Атенейко Дербышева, сказался Апкенейко. У него приемыш Тоишко Елдашев. Платит пол-ясака.

4 Двор. Янакейко Дербышева. У него дети: Бекбулатко да Однашко двунатцати (12) лет, Айбулатко ос(ь)ми (8) лет. Платит пол-ясака да с меленки оброку и пошлин пять алтын. Да ему же велено платить вновь пол-ясака.

5 Двор. Иришка Борашева. У него дети: Уразайко десяти (10), Уразмаметко пяти (5) лет, Утемышко трех (3) лет. Платит пол-ясака.

6 Двор. Акбулатка Чораева. У него дети: Саркатемейко да Тонмаметко трех (3) лет. Платит пол-ясака.

7 Двор. Крымсарайка Борашева. У него дети: Юнуско семи (7) лет, Ижмаметко пяти (5) лет. Платит пол-ясака.

8 Двор. Тляшка Кусюкова. У него сын Кил(ь)маметко (Килмөхәммәт) трех (3) лет. Платит пол-ясака.

9 Двор. Чемашка Дербышева. У него приемыш Токмаметко Бегашев году (1 год). Платит пол-ясака.

10 Двор. Бичюрки Бакеева. У него дети: Токтамышко пяти (5) лет, Утямышко дву (2) лет. Платит пол-ясака.

11 Двор. Исекейко Четаева. И он умер. Платил пол-ясака. А во дворе ево живут и ясак платят дети ево: Ишмячко да Доска. У Ишмячка дети: Кильмаметко семи (7) лет, Утяганко трех (3) лет.

12 Двор. Иляжбердки Кусюкова. У него дети: Утяганко трех (3) лет, Азаматко дву (2) лет. Платит пол-ясака.

13 Двор. Клекючейка Крымсараева. Платит четверть ясака.

14 Двор. Илбохдин Айболдика, сказался Ижболдин. У него сын: Ишмаметко году (1). Платит четверть () ясака.

15 Двор. Маметко Борашева. У него дети Баймяшко да Маметко четырех (4) лет. Платит пол-ясака. Да ему ж велено платить вновь пол-ясака. Да они ж всею деревнею платят с сенных покосов дер. Крукни Азмаметка Азбулатова оброку рубль четыре (4) алтына, пошлин два алтына.

Всего в дер.Таузарове пятнадцать (15) дворов, людей в них дватцать три (23), недорослей дватцать один (21). Платят семь (7) ясаков, денег четыре (4) рубли два алтына да хлеба семь (7) четверти бес полуос(ь)мины ячмени. Да с сенных покосов рубль шесть (6) алтын, с меленок девят(ь) (9) алтын две (2) денги. Да вновь велено платить полтара (1,5) ясака, денег дватцат(ь) девят(ь) (29) алтын да хлеба четверть с ос(ь)миною ржи, овса тож, ос(ь)мина бес четверика ячмени.

У тое ж дер. Тоузаровы (живут) себе усадом. А в ней:

1 Двор. Бекбулатка Байбахтина. У него дети Реско (?), Гуречко, Юнуско да Кутлуйко двунатцати (12) лет. Платит пол-ясака.

2 Двор. Кусяр(ч-?)ка Уразбахтина. У него дети Минка да Тенмаметко тринатцати (13) лет. Платит пол-ясака. Он же платит з бортного ухожея оброку пол-батмана меду, пошлин шесть (6) денег. Да ему ж велено платить вновь пол-ясака.

3 Двор. Кулмаметка Байбахтина, сказался Ирмячко. У него сын Азмаметко четырех (4) лет. Платит пол-ясака.

4 Двор. Иштуганка Айтуганова. И он бежал в Уфимской уезд. Платил пол-ясака. А во дворе ево живет и ясак платит сего ж

дер. безъясачной татарин Аскачко (Аснаачко-?) Телачев. У него сын Башайко десяти (10) лет.

Всего в дер., что у дер. Тоузаровы четыре (4) двора, людей в них восмь (8), недорослей четыре (4). Платят два (2) ясака, денег рубль пять (5) алтын две ден(ь)ги. Хлеба две (2) четверти ржи, овса тож, ос(ь)мина ячмени да с. вотчины оброку пол-батмана меду, пошлин шест(ь) денег. Да вновь велено платить пол-ясака, денег девять (9) алтын четыре (4) денги, хлеба ос(ь)мина ржи. овса тож, четверть ячмени.

*(далее идет писцовое описание яс. тат. дер., "что была пустош(ь) вотяцкая (удмуртская) по реке Кине" нами идентифицируется с совр. дер. Н. Кня. — **Р. Галлямов**)*

батман (авырлык үлчәү берәмлеге) = 24 кг
1 алтын (акча берәмлеге) = 15 тиен
1 алтын = 15 денга
1 руб = 100 денга

(вслед за писцовым описанием дер., "что была пустош(ь) по речке по Шире" — нами идентифицируется с совр. дер. Арбаш)

"дер. Тоузарова на ключе Крюкне. А в ней:

1 Двор. Бабака Курманаева. У него дети: Беганко да Бегашко семи (7) лет. Платит пол-ясака. Да ему ж велено платить вновь четверть ясака.

2 Двор. Янбулатка Московова. У него брат Тогонайко Досмаметов (Дусмөхәммәтов) да сын Ишмаметко тринадцати (13) лет. Платит пол-ясака.

3 Двор. Девлетбахтейка Уразбахтина. У него сын Бекчюрко. У Бекчюрки дети Янчюрка пяти (5) лет Бекмаметко дву (2) лет. Платит пол-ясака. И для ево старости ясак ево велено платить сыну ево Бекчюрке.

4 Двор. Баймячко Уразгильдеева. У него дети Минка пяти (5) лет, Иштуганко дву (2) лет. Платит пол-ясака да с меленки оброку и пошлин четыре (4) алтына две (2) денги.

5 Двор. Ку(л)тюки (?) Урманова. И он умер. Платил пол-ясака. А во дворе ево живет и ясак платит брат ево Крука (?). Да он же платит с вотчины, что он платил в дер. Ашалшике (Хасаншаихе-?) оброку пол-батмана меду, пошлин шесть (6) денег.

6 Двор. Оз(л-?)ичка Курманаева. У него дети Зигитко да Азичко тринадцати (13) лет, Бимячко десяти (10) лет, Альмамет-

ко шти (6) лет, Юнуско трех (3) лет, Московко дву (2) лет. Платит пол-ясака.

7 Двор. Ишачка Токранова. У него дети Ишкинячка, Альмаметко полугоду (0,5). Платит пол-ясака да с меленки оброку и пошлины четыре (4) алтына две (2) денги.

8 Двор. Тохтарка Курманаева. Платит пол-ясака.

9 Двор. Байбулатка Курманаева. И он умер. Платил пол-ясака. А во двореево живет и ясак платит з бортного ухожея Байгильдина. У него дети Урмаметко двунадцати (12) лет, Тувнкейко осьми (8) лет, Байтерячко пяти (5) лет. Платит пол-ясака да с вотчины оброку шестнатцать (16) алтын, четыре (4) денги, пошлин пять (5) денег да пол-батмана меду. Пошлин шесть (6) денег.

10 Двор. Топашка Яплашева. У него дети Асанко трех (3) лет, Кутлуйко дву (2) лет. Платит пол-ясака.

11 Двор. Икбашка Исенеева. У него сын Токайко да пасынки Аитко семи (7) лет и Урка дву лет. Платит пол-ясака да с меленки три алтына три денги.

12 Двор. Тойгоски Девлеткильдеева. И он умер. Платил пол-ясака. А во дворе ево живет и ясак платит сын Урмянко.

13 Двор. Тойгильдейки Сабанчина. У него дети Бекейко, Рыско да Кадярко осми (8) лет. Платит пол-ясака да с меленки оброку и пошлин четыре алтына полтара (1,5) денги.

14 Двор. Таймаметко Девлеткильдеева. Платит пол-ясака.

15 Двор. Бекбулатка Курманаева. У него дети Козяйко, Бекейко. У Козяйко сын Алмянко трех лет, Исенка году. Платит пол-ясака.

16 Двор. Акобечка Тоузарова. И он умер. Платил пол-ясака. А во дворе ево живет и ясак платит сын ево Кутлубулатко. Да с меленки оброку и пошлин три алтына три денги да четверть батмана меду. Пошлин три денги.

17 Двор. Уразайка Уразгильдина. У него дети Кулмаметко осми лет, Ишимко пяти лет, Альмаметко трех лет. Платит пол-ясака.

18 Двор. Уразайка Тойгозина. У него сын Уразбахтко четырех лет. Платит четверть ясака.

19 Двор Урикейка Чюрекеева. У него дети Бекбулатко семи лет, Полатко пяти лет, Кангильдка году. Платит четь (четверть) ясака.

20 Двор Руска Семенова. У него дети Ирмаметко четырех лет, Досмаметко году. Платит пол-ясака.

21 Двор Янбулатка Янзигитова. И он умер. Платил пол-ясака. А во дворе ево живет и ясак платит сын ево Токмаметко. Да он

же платит с вотчины за батман меду оброку двадцать шесть алтын, полторы денги, пошлин восемь (8) денег.

22 Двор. Янгильдки Тойгильдина. У него дети Болтайко шти (6) лет, Тлеушко четырех лет. Платит четверть ясака.

23 Двор Уркейко Дебкашева. У него дети Юнуско шти (6) лет, Юсупко пяти лет, Сеитко трех лет, Кар(?)мячко году. Платит пол-ясака.

24 Двор. Одногулка Байкеева. Платит четверть ясака.

25 Двор Атяйка Уразбахтеева. У него дети Ботайко семи лет, Мустка пяти лет, Уракайко трех лет, Нурка дву лет. Платит четверть ясака да с меленки оброку и пошлин четыре алтына две денги. Да сей ж дер. Тукмаметко Янбулатов всею дер. платят с сенных покосов оброку дватцать пять алтын, пошлин по семи денги.

26 Двор безясачного Уразмаметко Айбулатова. А велено ему платить вновь четверть ясака. У него дети Ирмаметко десяти лет, Бекмаметко дву лет. Да он же Уразмаметко с товарыщи всею деревнею платят с сенных покосов что он платил в дер. Шикше оброку и пошлин рубль, шесть алтын.

Всего в дер. Тоузарове дватцать пять (25) дворов, людей в них тритцать пять (35), недорослей сорок три (43). Платят двенатцать ясаков без четверти, денег шесть (6) рублев, дватцать семь (27) алтын з деньгою да хлеба двентцать (12) четверти бес полуос(ь)мины ржи, овса тож три (3) четверти бес получетверика ячмени. Да с вотчины дватцать семь (27) алтын Тюменского дватцать семь алтын, пол-четвертик(?) и денги за батман с четвертью меда пошлин два алтына три (две-?) денги. С сенных покосов рубль дватцать два алтына с полуденгою. С меленых дватцать четыре алтына, полтары (1,5) денги.

Двор безъясачного. А в ней один (чел.), недорослей два (2). Платят вновь четверть ясака, денег четыре алтына пять (5) денег. Хлеба пол-ос(ь)мины ржи, овса тож, полчетверика ячмени.

У тое ж дер. живет себе усадом. А в ней:

Двор Баймурски (Байморза) Бекбулатова. У него дети Утекейко десяти лет, Сеитко дву лет, Маметко году. Платит пол-ясака, денег девять алтын, четыре денги, хлеба ос(ь)мина ржи, овса тож, четверик ячмени.

(далее идет описание яс. тат. дер. "что был починок Едигеревской", которая нами идентифицируется с совр. дер. Н. Шубан)

Первая ревизия: 1716 года

(РГАДА. ф. 350, опись 1, дело 146, лл. 1116—1119)

В деревне Таузарово по переписным книгам 710-го и 711-го годов написано двадцать семь дворов, ясашного тягла двенадцать ясаков с полутретью. А по переписным сего 716-го году ныне на лицо жилых дворов:

Во дворе Тоимячко Уркеев тридцати пяти лет, у него после переписи 711-го году жена Бексалтанка Тойкина двадцать пяти лет. После той же переписи ис того двора мать его Тойбичка умерла в 713-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла четь ясака.

Во дворе Мукчейко тридцати пяти лет, Бегашко двадцати трех лет Уразметовы. У них мать Селечка Бекбулатова шестидесяти пяти лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано (1115 л.) на нем тягла полторы чети ясака.

Во дворе Кутейко Тоишев тридцати, у него мать Шарейка Бекбулатова шестидесяти пяти лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла четь ясака.

Во дворе **КОЗЕЙКО ЯНИКЕЕВ** пятидесяти пяти. У него жена Гулейко Сабанаева пятидесяти пяти, дети Саперко двадцати пяти, Неяско семнадцати лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Во дворе Уразметко Преев тридцати пяти, у него жена Тютячка Тлянчеева сорока лет, дочь Бичка семи. Да в особой избе брат его Тюмякейко тридцати, Ишметко двадцати трех лет. У Тюмякейко жена Нейка Баймякова двадцати семи, сын Ишмураска шести лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Во дворе Токмаметко Багавеев сорока лет, у него жена Заврячка Давлеткильдина сорока двух, да Тибичмаметко девятнадцати, Расманкулово шести, дочь Марзянка одиннадцати лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол ясака.

Во дворе Утяганко тридцати пяти, Курманайко тридцати лет Пляшевы. У Утягана жена Минка Ишпулатова сорока лет, сын Утямышко восемнадцати лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Во дворе Сарка Акбулатов шестьдесят пяти, у него жена Батычка (1115 об. л.) (?)анаева пятидесяти, дети Ахтерячко трид-

цати, Бегашко двадцати пяти лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол ясака с полу-четью.

Во дворе Ишмячко тридцати пяти, Ямейко тридцати лет Минкины. У Ишмячко жена Зюмлячка Курмякеева тридцати пяти. После переписи 711-го году дочь Гутарка двух лет, после той же переписи ис того двора сын его Тохтамышко утонул в 714 году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Во дворе Ибрашко Дрюкеев сорока лет, у него жена Бостанка Маметева тридцати пяти. После переписи 711-го году сын Тетышко четырех, дочь Голтюшка двух лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла треть ясака.

Во дворе Утяганко Преев сорока пяти, у него жена Тюгейка Чюрашева сорока пяти, дети Смаганко восемнадцати, Ибрайко шести лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла полтора чети ясака.

Во дворе Бекбулатко Еникеев шестдесять, у него жена Заврячка Сарманаева шестдесять пяти, дети Саипко тридцати, Сипко двадцати пяти лет. У Саипка после переписи 711-го году жена Ашачка Доскеева двадцати двух лет. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол ясака с полу-четью.

Во дворе Бегашко тридцати, Именко двадцати семи Рысовы, у них мать Тотмачка Енекеева семьдесят пяти, сноха Бурнакаейка Сарманаева сорока лет. У нее дочь Саламка осми лет. У Именка после переписи 711-го году жена Женалайка Тилмаметова тридцати, сын Мурайко году. После той же переписи ис того двора брат их Беккулоково Тегашкова жена Занятса померли в 715-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла ясак.

И того в той деревне ныне налицо жилых тринадцать дворов, в них людей мужеска полу от году до пяти — два, от пяти до десяти — три, от пятнацати до двадцати — четыре, от двадцати до тридцати — шесть, от тридцати до сорока — двенадцать, от сорока до пятьдесят — три, от пятьдесят до шестьдесят — один, от шестьдесят до семьдесят — два. Итого: тридцать три человека, а женска полу от году до пяти — два, от пяти до десяти — два, от десяти до пятнадцати — один, от двадцати до тридцати — три, от тридцати до сорока — три, от сорока до пятидесяти — пять, от пятьдесят до шестьдесят — два, от шестьдесят до семьдесят — три, от семьдесят до осемьдесят — одна. Итого: двадцать два человека. Всего обоих полов пятьдесят пять человек.

Тягла по переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на вышеписанных дворах шесть ясаков с полуясаком без малой трети. И в вышеписанных жилых дворов после переписи 710-го и 711-го годов убыло людей мужеска полу: умер — один, утонул — один, итого два человека. Женска полу померли два человека. Всего обоих полов четыре человека.

В той же деревни пустые дворы после переписи 710-го и 711-го годов запустели, а именно:

Двор Ямки Уркеева, он, Ямка з женою Балтайкою, с сыном Ниячейком бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла четь ясака.

Двор Ишпулатко Сяркеева. Он, Ишпулатко, з женою Нюлкою, с сыном Кнышком бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла полтары чети ясака.

Двор Алмаметка Илболдина. Он, Алмаметко, з женою Бакейкою, с сыном Азмаметком, и с пасынком с Рахманкулом, с Иманкулом бежали в 713-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол ясака.

Двор Шайбуланка Яникеева. Он, Шайбуланко, с матерью Тяпелкою, з женою Бязиркою, с сыном Кутлуком, з дочерью Тонячкою бежал в 715-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла полтары чети ясака.

Двор Токейка Айбулатова. Он, Токейко, з женою Гулпанкою, з дочерью Уркуячкою, с племянником с Сеитом, с Нурсенком бежал в 713-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака с полу-четью.

Двор Бакейка Тяишева. Он, Бакейка, з женою Юлхарейкою, з дочерью з Юлейкою бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла полтары чети ясака.

Двор Антка Исенеева. Он, Антко, з женою Гузаперкою, с сыном с Антком, с племянником Алмаметком бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Двор Сулейманка Тлянбердеева. Он, Сулейманко, з женою Гулназыркою, з дочерью Гулешачкою бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла треть ясака.

Двор Саперка Исенеева. Он, Саперко бежал в 713-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла четь ясака.

Двор Ишмаметка Илбахтина. Он, Ишмаметко, з женою Гукунейкою, з дочерьми с Шерянскою, с Шгунсалтанкою бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла треть ясака.

Двор Ермачка Кутлина. Он, Ермачко, з женою Шапкою, з дочерью Минкою бежали в 711-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака.

Двор Антка Рысова. Он, Антко, з женою Батмичкою, з дочерью с Канянкою, з Зюлешкою бежали в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла треть ясака.

Двор Тилмаметко Уразметова. Он, Тилмаметко, з женою Ишпинкою, з дочерью Якашкою бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла четь ясака.

Двор Досайка Тлянчеева. Он, Досайко, з женою Игишкою, з братом Ураском бежал в 712-м году. По переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на нем тягла пол-ясака с полу-четью.

Итово в той деревне пустых четырнадцать дворов и в них люди мужска полу бежали двадцать пять человек, женка полу бежали двадцать четыре человека. Всего обоих полов сорок девять человек. Тягла по переписным книгам 710-го и 711-го годов написано на вышеписанных дворах пять ясаков и полуясаком и с полу-четью.

Вторая ревизия: 1745 года

(РГАДА ф. 350, опись 2, дело 1149, лл. 878—880)

В деревне Тахтарове Таузарово тож ясашные татары написанной прошлой переписи

(Саннар кешенең яшен күрсәтә,
дөреслеге анык булган исемнәр татарчалаштырылды.)

1. **Тотейко Токшеев, 61**
   у него дети после переписи рожденные:
   Биккол, 23
   Имәнкол,15

2. Написанный в прошлой переписи **Томакша Саркеев, 75**

3. Написанный в прошлой переписи **Бигәш Уразмәтов, 50**
у него дети после переписи рожденные:
Ибрай, 12
Мәмәткол, 6
Бакир, 2

4. Написанный в прошлой переписи **Утэмеш Утэгэнов, 45**
у него дети после переписи рожденные:
Әлмәмәт, 15
Гайса, 8

5. Написанный прошлой переписи **Бигаш Рысов, 55**
у него брат в прошлой переписи написанный **Иманкол, 60**
у Бигашка сын после переписи рожденный:
Мосагыйт, 10
у Иманкола дети после переписи рожденные:
Акман, 20
Шарип,14

6. Написанный в прошлой переписи **Утэгэн Бигашев, 28**

7. Написанный в прошлой переписи **Бакый Рысов, 28**

8. Написанный в прошлой переписи **Ярмэч Бикбулатов, 63**
у него дети после переписи рожденные:
Йосып, 18
Гали, 2

9. Написанный в прошлой переписи **Мэсэй Токаев, 29**
у него дети после переписи рожденные:
Акмэр, 6
Рахматулла, 2

10. Написанный в прошлой переписи **Башир Актимиров, 26**

11. Написанный в прошлой переписи **Бигэш Серкеев, 45**

12. Написанный в прошлой переписи **СЭФЭР КУЗАЕВ, 45**
у него брат в прошлой переписи написанный **НИЯСКО, 43**
у Нияза сын после переписи рожденный:
ГАБДРАШИТ, 8

13. Написанный в прошлой переписи **Сэет Бикбулатов, 55**

14. Написанный в прошлой переписи **Морзай Саитов, 28**
у него брат в прошлой переписи написанный **Шарип, 25**

у Морзая сын после переписи рожденный:
Мохамматамин, 3
у Шарипа сын после переписи рожденный:
Башир, 2

15. Написанный в прошлой переписи **Тукмэмэт Бигашев, 85**

16. Написанный в прошлой переписи **Рэхмэт Тукмэмэтов, 30**
у него сын после переписи рожденный:
Рэмкол, 5

17. Написанный в прошлой переписи **Ибрай Утэганов, 29**

18. Написанный в прошлой переписи **Уразмэт Хайриев, 65**
у него братья в прошлой переписи написанные
Тэмэкэч, 55
Ишмэт, 45
у Тэмэкэчэ дети после переписи рожденные:
Байморза, 17
Абдул, 10
у Ишмэтэ сын после переписи рожденный:
Ишмохэммэт, 15

19. Написанный в прошлой переписи **Мохэммэтшэрип Уразмэтов, 26**

20. Написанной в прошлой переписи **Кулабэрде Тэмэчкин, 26**

21. Умершего, написанного в прошлой переписи татарина **Ямэт Мискина** дети после переписи рожденные:
Миннекэй, 22
Ермэк, 8

22. Умершего, написанного в прошлой переписи (?) дети после переписи рожденные:
Ирмэмэт, 24
Абдыкэн, 18
Садык, 15

23. Умершего, написанного в прошлой переписи татарина **Бикмэт Ишакаева** сын после переписи рожденный:
Махмут, 9

24. Умершего, написанного в прошлой переписи татарина **Актирэкэ Саркеева** сын после переписи рожденный:
Назир, 18

25. Умершего, написанного в прошлой переписи татарина **Исмэгыйлэ Утэгэнова** дети после переписи рожденные:
Исхак, 9
Искандер, 2

26. Умершего, написанного в прошлой переписи татарина **Бикэн Тияшева** сын после переписи рожденный:
Ягъфар, 19

27. В прошлой переписи прописано **Ишмэн Азиков, 63**
у него сын после переписи рожденный: **Якуб, 8**

Итого в деревне Тахтарове Таузарове тож: 58 мужского пола.

Третья ревизия: 1762 года

Ревизские сказки
1762 года Казанского уезда
Арской дороги деревни Таузарово.

(РГАДА фонд 350, опись 1, дело 1187, лл. 551—558)

(Беренче сан кешенең 1745 елдагы,
икенче сан — 1762 елдагы яшен күрсәтә.)

1. **Тэтэй Таишев, 61; умер 1752**
у него дети написанные в прошлой ревизии
Биккол, 23; 40
Иманкол, 15; 32
дочь **Миннегуль, 40;** выдана в замужество той деревни за ясашного татарина.
у Биккола жена **Гайша Илмаматова, 42;** взята из дер. Княбаш
у него дети рожденные после ревизии:
Бикмөхәммәт, 8
дочь **Голшахида, 20;** выдана дер. Шашы
девки: **Голбэвэн, 11**
Галимэ, 8
у Иманкола жена **Голниса Бикколова, 24;** из дер. Пошенгерь;
у него дочь **Махитаб, 2**

2. **Такмаш Сэркеев, 75; умер 1750**

3. **Бигэш Уразмэтов, 50; 67**
у него жена **Тэнкэ Бикмохэммэтова, 50**
у него дети написанные в прошлой ревизии:
Ибрай, 12; умер 1750
Мэмэткул, 6; умер 1750
Бакир, 2; умер 1749
родившиеся после ревизии:
Габделгани, холост, 16
дочь **Бустан, 34;** выдана дер. Княбаш
дочь **Сэлимэ, 22**

4. **Утэмеш Утэгэнов, 45; 62**
у него жена **Ишсултан Бикмэмэтова, 50;** из дер. Каратай
у него дети написанные в прошлой ревизии:
Альмэмэт, 15; 32
Гайса, 8; 25
дочь **Зэлифэ, 40;** выдана дер. Янгирь за Эмир Нигмэтова
Бэдэр, 30
Хэлимэ, 20; выдана Верхний Шубан;
у Ахмэмэта жена **Разия Мослимова, 30**
у него дети:
Габделхэсэн, 10
Искей, 2
дочь **Миннебикэ — 4**
у Ай жена **Голнасихэ Ирмэжева, 20 лет** из дер. Арбаш
у него дети:
Габдрахман, 4
Габделсалах, 3 дня

5. **Бигэш Рысов, 65; умер 1750**
у него жена **Гайшэ Ишимова, 80 лет**
у него дети:
Утэгэн, 28; умер 1750
Мосэгыйт, холост, 10; 27
дочь **Биксолтан, 30;** выдана дер. Ахманово
Хоппи, 30; выдана дер. Янгулово за Искэндэра Нэдеркина

6. **Иман Рысов, 60; 77**
у него дети:
Акман, 20; 37
Шэрипжан, 14; 31
у Акмана жена **Голнэзэк Утэгэнова, 35;** из дер. Княбаш

у них дети (дочери):
Рабига, 14
Разия, 12 лет
Рэхимэ, 2 лет
у Шарипа жена **Халима Аитова, 27;** из дер. Яншикова
у них дети:
Бэхир, 1
дочь **Сэлимэ, 8**
дочь **Сажида, 6**

7. **Бакый Рысов, 28; 45**
у него жена **Фазыйла Искәндәрова, 20**
у них дети:
Габделкарим, 2; 12
Габделсахап, 4
